# МЕНТАЛЬ КАРТАЛАР



# ӘДӘБИ НУРЛАР

1
кисәк

Хөрмәтле укытучылар,
укучылар һәм ата-аналар!

Тәкъдим ителгән **менталь карталар** – дәрәҗәләргә бүленгән ике яклы эш карталарының, әдәби анализ өчен кирәкле терәк схемаларның һәм әдәбият теориясенә кагылышлы гамәли карталарның аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Татар әдәбиятыннан беренче тапкыр мондый форматта эшләнгән әлеге кулланма әсбап укучыларның белемен системага салырга һәм мөстәкыйль күнекмәләр булдырырга ярдәм итә.

Биредә тупланган карталар әдәбият дәресләрендә әсәрне анализлаганда яки әдип иҗатын өйрәнгәндә, әдәби чорларны яки теоретик төшенчәләрне үзләштергәндә, шулай ук олимпиадаларга әзерләнгәндә, төп кулланма әсбап булып хезмәт итәчәк.


# 1. Менталь карталар (36 карта)

Хәзерге мәгариф системасының төп максаты – иҗади һәм актив фикерләүгә ия шәхес формалаштыру. Бүгенге укучы мөстәкыйль фикерли, төрле чыганаклар һәм мәгълүмат белән эшли, аларны анализлый һәм гомумиләштерә, мөстәкыйль рәвештә тәнкыйди фикер йөртә белергә, рациональ юлларны эзли һәм таба алырга тиеш. Шушы юлда укытучының бурычы – укучыларны актив иҗади һәм фәнни-аналитик эшчәнлеккә җәлеп итү. Ул укучыларны мәгълүмати системалар базасында әдәби процессларны модельләштерергә, шул юнәлештәге әзер проектларны куллана белергә өйрәтергә тиеш. Мондый заман үзгәрешләре татар әдәбиятын укытканда да яңа педагогик технологияләр куллануны таләп итә.

Фикерләү процессын системага салуда һәм мәгълүматны визуаль формада бирүдә уңайлы инструментларның берсе – менталь карта. Алар фикерләүне визуальләштерергә мөмкинлек бирә. Мондый карталарны китап укыганда яки әсәрне өйрәнгәндә дә, әдип иҗатын тикшергәндә дә кулланып була. Шуны күздә тотып, әлеге кулланмада **беренче тапкыр татар әдәбиятыннан мәктәптә өйрәнелә торган кайбер әдипләрнең тормыш юлына һәм иҗатына, берәр әсәренә кагылышлы менталь карталар** тәкъдим ителә. Әдипләрнең иҗатын өйрәнгәндә, төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларга әзерләнгәндә, дәресләр, конференцияләр өчен презентацияләр эшләгәндә аларны куллану методик яктан отышлы булачак.

Әдәби материалны үзләштерүне бермә-бер җиңеләйтәчәк менталь карталарның бер ягында мәктәп курсында үтелә торган авторларның тормыш юлы һәм иҗаты бирелә, икенче ягында шул әдипнең әдәбият дәресендә мәҗбүри өйрәнелә торган әсәренә бәйле визуаль *схема* урын ала. Моннан тыш һәр карта әдипне шәхес буларак ачкан кызыклы мәгълүмат белән баетып барыла. Бу укучыларга әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты хакындагы мәгълүматны системага салырга, зур әдәби материалны абстракт күзалларга һәм тиз истә калдырырга ярдәм итә, анализ өчен алынган әсәрдәге эчке бәйләнешләрне, аның төп үзенчәлекләрен, беренче карашка кечкенә генә тоелган, әмма идеяне күрсәтүдә мөһим булган детальләрне күз алдына китерергә ярдәм итә.

# Гамь һәм моң илчесе



## Гамил Афзал
1921–2003

### Шигырьләре:

«Дөнья матур, дөнья киң»
«Татарстан таңнары»
«Гөлмәрьям»
«Матурлык эзлим»
«Бу – Ватан» һ. б.

**Татарстанның халык шагыйре (1991), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1977)**

Гамил Афзалов **1921 елның 23 маенда** Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында туа. **1931 елда** гаиләләре Магнитогорск шәһәренә сөрелә. Биредә 35 нче татар мәктәбендә укый, әдәбият түгәрәгенә йөри, Габдулла Тукай, Һади Такташ шигырьләре тәэсирендә үзе дә каләм тибрәтә башлый. **1937 елда** «Магнитогорск» исемле шигыре Баку шәһәрендә чыга торган «Баку эшчесе» газетасында басыла. Троицк педагогика техникумында белем ала, әмма нык авыруы һәм тулаемга акчасы булмау сәбәпле, алга таба укуын туктатырга мәҗбүр була.

**1940–1949 елларда** Магнитогорскидагы металлургия комбинатында эшләсә дә, шигырьләр язуын дәвам итә. **1949 елда,** сәламәтлеге начараю сәбәпле, заводтагы эшеннән китә. **1954 елда** Башкортстанга күченә. Биредә ул ныклап иҗатка кереп китә. Озакламый аның балалар өчен язылган шигырьләр циклы Татарстанда узган конкурста премия ала. Халыкчан юмор белән сугарылган, эчтәлеге белән гаҗәп заманча һәм үзенчәлекле яңгыраган бу шигырьләр укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан татар поэзиясе өчен яңалык буларак кабул ителә. Шуннан соң шагыйрьнең бер-бер артлы шигырь җыентыклары басыла башлый, ул тиз арада халык арасында киң танылa. **1965 елда** ул Татарстан Язучылар берлеге чакыруы белән Әлмәткә күчеп килә.

Гамил Афзал – татар, рус, башкорт телләрендә басылган өч дистәгә якын китап авторы.

Шагыйрь **2003 елның 20 августында** Әлмәт шәһәрендә вафат була.

> **Үз кичерешләре ил, халык язмышы белән бергә кристаллашкан шагыйрьне мин шул зур язмышлардан аера алмый башлыйм. Шунда ул иҗатының иң биек ноктасында басып тора шикелле.**
>
> С. Хәким, шагыйрь

> **XX гасыр татар шигъриятенең горурлыгы.**
>
> Т. Галиуллин, әдәбият галиме

### Моны белү кызыклы...

- Туган көне төгәл билгеле түгел, «Алабута елының җәй башында тудың» дигән хәбәргә таянып, 23 майда дигән төгәл датаны ул үзе уйлап чыгара.
- Аңа ун яшь булганда, гаиләләрен Магнитогорскига сөрәләр.
- Шуннан соң туган ягына бары бер мәртәбә – 1958 елда гына кайта.
- Үзенә карата шаяруны кабул итми.
- Шагыйрьнең «Дөнья матур, дөнья киң», «Татарстан таңнары», «Гөлмәрьям», «Гөлнарым», «Әлли-бәлли», «Очрашу» һәм башка күп шигырьләре, музыкага салынып, профессиональ һәм үзешчән җырчылар тарафыннан даими җырлана.

### Татар әдәбиятында тоткан урыны:

- шигъриятькә үз-үзе белән каршылыкта яшәүче лирик геройны алып килә;
- эзоп теле алымына таянып, җәмгыятькә бәя бирә;
- иҗатында метафора, символ, шартлы образ, алымнар өстенлек итә;
- милли темаларга еш мөрәҗәгать итә;
- авыр язмышы, имгәтелгән тәне, юкка сарыф ителгән яшьлеге, авыруы турында яза;
- туган халкының язмышы, узган олы юлы турында туктаусыз уйлана;
- татар поэзиясендә сатираны үстерә;
- гражданлык лирикасы жанрын үстерүгә зур өлеш кертә.

# «Матурлык эзлим»

**Әдәби төре: лирика**

**Жанры: күңел лирикасы**

*Шигырь Г. Афзалның рухи матурлыкка мөнәсәбәтен, эстетик идеалын ачып бирә,* ***матурлык мотивын*** *үзәккә ала.*

**ХИС**

**Шатлык хисе** → **Соклану хисе**

**ХИСНЕҢ СӘБӘБЕ:**

Шатлык хисе: Рухи матурлыкны матди байлыклардан өстен куеп яши алуы → **Мәрмәр сарай, алтын-көмеш һәм ипи белән катык, табигать матурлыгы, кешеләр арасындагы яхшы мөнәсәбәтләр, эчке матурлык, бала шатлыгы каршы куела**

Соклану хисе: Матурлыкның янәшәдә – туган җирдә, табигатьтә, дуслыкта, балачак гамьсезлегендә булуы → Шәфәкъ алсулыгы, кояш чыгышы һәм батышы, кешеләрнең якты уйлары, уҗым басуларының, болын, тауларның матурлыгы, бала шатлыгы

Шигырь **ике өлешкә** аерыла: лирик геройның матурлыкка бәйле теләге (*миңа кирәк...*) һәм шул матурлыкны табуы (*чәчәкләр җыям...*)

**ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ:**

**Инверсия** – «...Йөрәгемә салып ятлап йөрим
Кешеләрнең якты уйларын» һ. б.

**Метафора** – «...тирән диңгез **сере**...,
**чәчәкләр** җыям..., **ил туе**» һ. б.

**Анафора** – «**Миңа кирәк** шәфәкъ алсулыгы,
Кояш чыгыш, кояш баешы;
**Миңа кирәк** гөлнең иң сылуы,
Тыныч күлнең уйчан камышы...»

**Эпитет** – «Кешеләрнең **якты** уйлары...» һ. б.

**Лирик геройның сыйфатлары:**

- Рухи матурлыкка омтыла, аны матди байлыклардан өстен күрә, җирдә ямь таба
  - ...Миңа ипи белән катык ярый,
    Миңа рәхәт шушы килеш тә...
  - ...Миңа кирәк дусның эчкерсезе,
    Уйнап йөргән бала шатлыгы...
    ...Миңа кирәк гөлнең иң сылуы,
    Тыныч күлнең уйчан камышы...
- Үзенең туган ягын, туган илен, кешеләрдәге эчке матурлыкны ярата
  - Йөрәгемә салып ятлап йөрим
    Кешеләрнең якты уйларын...
    ...Мин чәчәкләр җыям ил туена,
    Мин матурлык эзлим гомергә.

**Идеясе:**


Табигатьтәге, туган җирдәге, яшәештәге матурлыкны күрә белү кешеләр күңелен баета, кешеләр матурлыгы ил матурлыгы булып гомумиләшә
*(«Мин чәчәкләр җыям ил туена,
Мин матурлык эзлим гомергә»)*

**МАТУРЛЫК**

- Рухи, эчке матурлык, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы
- Туган җирнең, табигатьнең матурлыгы
- Лирик геройның күңел матурлыгы
- Матурлыкны таба, күрә белгән кеше генә күңел матурлыгына ия була

И туган тел, и матур тел...

# Мәңгелек шигырь иясе



## Мөдәррис Әгъләм

1946–2006

Татарстанның халык шагыйре (2006), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1992)

Мөдәррис Әгъләмов **1946 елның 13 октябрендә** Татарстанның Зәй районы Бишсубаш авылында колхозчы гаиләсендә туа. **1965 елда** Түбән Биш авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. **1968–1973 елларда** Тукай районының Яңа Гәрдәле урта мәктәбендә тарих укытучысы, аннары Яр Чаллы шәһәрендәге халык театрында режиссёр ярдәмчесе булып эшли. **1974 елдан** Казанда яши һәм профессиональ язучы буларак әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә, вакытлыча «Яшь ленинчы», «Ялкын», «Шәһри Казан» редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли.
**2006 елның 26 ноябрендә** вафат була. Казанның Яңа Бистә зиратына җирләнә.

## Иҗатка килү юлы

Беренче шигырьләре 1959 елда Татарстан һәм Башкортстан пионер газеталарында һәм журналларында басылып чыга. Ә 1968 елда «Казан утлары»нда чыккан «Еракка китеп кара» исемле шигырьләр циклы әдәби җәмәгатьчелектә кызыксыну уята, 1970 елда «Кыңгырау» исемле беренче мөстәкыйль китабы дөнья күрә.

## Иҗади үзенчәлекләре:

- шигъриятенә фикер яңалыгы, тирән мәгънәлелек, халык язмышы темасына өстенлек бирү сыйфатлары хас;
- гражданлык лирикасы һәм күңел лирикасы жанрларына өстенлек бирә;
- баллада һәм поэма жанрларында иҗат итә;
- традиционлыкны авангард алымнар белән бергә үреп яза;
- шигырьләрендә символлар, эзоп теле алымы ярдәмендә җәмгыятькә бәя бирә, фәлсәфи фикерләрен үткәрә;
- халык авыз иҗаты белән бәйләнеше көчле, «туган җир», «туган нигез», «ата-баба җире», «туган туфрак», «ватан», «нәсел-ыру» кебек милли яшәешкә бәйле төшенчәләргә зур игътибар бирә;
- Тукай традицияләрен дәвам итә.

## Без моны беләбезме...

- М. Әгъләмов, әти-әнисен югалтып, бик яшьли ятимлек ачысын татый, ләкин бервакытта да үзен ятимсетми, шигъри әнкәсе бар дип саный.
- Аңа дүрт җәй рәттән көтү көтәргә туры килә.
- Иң якын дусты – шагыйрь Зөлфәт.
- Зөлфәт аңа багышланган шигырендә М. Әгъләмовны «сәях дустым, нәни гигант» дип атый.
- Тормыш иптәше – шагыйрә Нәҗибә Сафина.
- Шагыйрь Аккош күле буенда яшәргә ярата.
- Үзен урманнар, болыннар кешесе дип атый, табигатьне ярата.

> *Мөдәррис Әгъләмов фани дөньяның барлык ваклыкларыннан өстен иде, алардан азат булды. Ул үзе дә мәңгелек шигырь иде, киләчәктә дә үлмәс поэма булып калачак.*
>
> *М. Мирза, шагыйрь*

### Лирикасы

• «Кош» • «Без – курпылар» • «Җил дә җил» • «Матурлык минем белән!» • «Каеннар булсаң иде» • «Учак урыннары» • «Балам, бәгърем, диеп» • «Мин табышмак чишәм» • «Сабантуй» • «Еракка китеп кара» • «Әйтте Тукай» • «Мин әйттем» • «Бүген» һ. б.

### Поэмалары

• «Онытма, Европа!» • «Тукайдан хатлар» • «Акмулла арбасы»

### Балладалары

• «Сугышлыда сугыш беткән көн» • «Бердәнбер» • «Төнге баллада» • «Мәңгелек ут» һ. б.

### Җырлары

• «Серле йөрәк» • «Айлы Казан» • «Яшәү ярый бу дөньяда» • «Тургай» • «Күпме җырлар бүләк иттең миңа» һ. б.

Әдәби нурлар

И туган тел, и матур тел...

# «Матурлык минем белән»

**Әдәби төре: лирика**

**Жанры: гражданлык лирикасы**

*Шигырь М. Әгъләмовның яшәешкә, туган җирендәге һәм туган илендәге матурлыкка мөнәсәбәте турында, лирик геройның эчке һәм тышкы матурлыкка бәйле уйлануларын яктырта, матурлык мотивын үзәккә ала.*

**ХИС** → **Шатлык хисе** → **Соклану һәм горурлык хисләре**

**ХИСНЕҢ СӘБӘБЕ** → Туган җирнең матурлыгы, кешеләрнең бәхетле тормышы → **Күл, болын, уйнаклап йөргән колын, елга сулары, таулар**

Туган илнең матурлыгы → Зур, матур, биек йортлар, якты тәрәзәләр, иркен җир, киң ил, башны имичә яшәү мөмкинлеге

Шигырь **КАБАТЛАУ** алымына таянып язылган

**Тел-сурәтләү чаралары:**

**Инверсия** – «...сикереп төшәм суларга» һ. б.

**Сүз уйнату** – «...сикереп төшәм **суларга**, шундый рәхәт **суларга**!..»

**Синоним** – «... мин дә **тәгәрим, көләм**...»

**Антоним** – «... сикереп **төшәм** суларга», «...тауларга **күтәреләм**»

**Эпитет** – «**зур, матур, биек** йортлар...» һ. б.

**Лирик геройның сыйфатлары:**

Чын күңелдән шатлана, сөенә, туган җирен ярата, матурлыкны күрә, һәр мизгелдән ямь-тәм таба белә → ...Кайда гына барсам да, Матурлык минем белән... ; ...Мин дә тәгәрим, көләм, Чөнки, кайда булсам да, Матурлык минем белән...

Үзенең туган иле, халкы, аның кылган эшләре белән горурлана, ул патриот → ...Горур йөрергә мөмкин, Имичә башны түбән... Чөнки, кайда булсам да, Матурлык минем белән!

## Идеясе:

Туган җирнең, аның табигатенең, туган илнең матурлыгы кешеләр күңелендә матурлык уята, ә бу матурлыкны күрә белү өчен, кешенең үз күңеле матур булырга тиеш. Эчке һәм тышкы матурлык кешене бәхетле итә. Мондый кеше туган иле, туган җире тагын да матуррак, ямьлерәк булсын дип тырыша *(«Матурлык минем белән!»)*

**МАТУРЛЫК**:
- Туган җирнең матурлыгы
- Туган илнең матурлыгы
- Лирик геройның күңел матурлыгы
- Күңеле матур кеше генә матурлыкны күрә, һәр мизгелдән, гади матурлыктан да ямь таба белә

Әдәби нурлар

# Татар әдәбиятының Прометее



## Фатих Әмирхан

1886–1926

**XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле вәкиле, тәнкыйди реализмга нигез салучыларның берсе, прозаик, драматург, сатирик, тәнкыйтьче, публицист**

**1886 елның 1 гыйнварында** Казан шәһәрендә мулла гаиләсендә туа. 8 яшеннән Яңа Бистә мәдрәсәсендә ике ел дәвамында башлангыч белем ала. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә 10 ел укый. Хосусый укытучыга йөреп, рус телен өйрәнергә керешә. **1904 елның** җәендә Самарага барып, рус телен камилләштерә. **1905 елда** «Мөхәммәдия»нең алдынгы шәкертләре белән яшертен рәвештә чыгарган «әл-Ислах» (гарәпчәдән – үзгәртеп кору) газетасының җитәкчесе һәм мөхәррире була.

> ***Классиканың рухи әмир-ханы –***
> ***Аяклары бәйле Прометей...***
>
> ***Х. Туфан,*** *шагыйрь*

### Проза әсәрләре

«Гарәфә кич төшемдә» ■ «Ай өстендә Зөһрә кыз» ■ «Габделбасыйр гыйшкы» ■ «Салихҗан карый» ■ «Сәмигулла абзый» ■ «Фәтхулла хәзрәт» ■ «Татар кызы» ■ «Хәят» ■ «Урталыкта» ■ «Шәфигулла агай» ■ «Нәҗип» ■ «Чәчәкләр китерегез миңа!» ■ «Бер хәрабәдә» һ. б.

### Драмалары

- «Яшьләр»
- «Тигезсезләр»

**Күпсанлы тәнкыйть мәкаләләре бар.**

> ***...Төрки телләрдә, гарәпчә, фарсыча һәм, әлбәттә, русча иркен укучы, киң карашлы, мәгълүматлы, Көнчыгыш мәдәниятенең рухын аңлаган, шуның белән бергә Көнбатыш цивилизациясенә йөз тоткан, аңа кызыккан әдип үзен дә Лондон, Париж дендилары кыяфәтендә күрергә теләгән. Аяксыз булганы хәлдә, европача эшләнә, гамашлы ботинкалар киеп алдырган фотосын карагыз. Тереклекне, гомерне никадәр ярату хисе чагыла бу кыяфәттә... Европа-Көнбатыш мәдәниятенә йөз юнәлткән алдынгы карашлы зыялының идеаль моделе ул.***
>
> ***Б. Урманче,*** *рәссам*

- **1906 елның** көзендә Мәскәүгә китә һәм анда «Тәрбияи әтфаль» журналында да сәркатип булып эшли.
- **1907 елның** язында, ял итәргә дип, Казанга кайта һәм 15 августта аны кинәт паралич суга, ике аягы да йөрмәс була. Гомеренең азагына кадәр инвалид арбасында гына хәрәкәтләнә ала. Шушы елларда беренче әсәрләре дөнья күрә, тәнкыйть мәкаләләре яза. «Әл-Ислах» газетасы рәсми рәвештә чыга башлагач, аның сәркатибе була. «Ялт-йолт», «Аң» журналларын, «Кояш» газетасын чыгаруда катнаша.
- **1923–1924 елларда** татар театр техникумында укыта. Ф. Әмирхан бөтен гомерен татар милләтен агартуга, аның милли матбугатын үстерүгә күп көч куя.
- **1926 елда,** каты авырудан соң, кырык яшендә вафат була.

## Без моны беләбезме...

- *Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле булган данлыклы морза Әмирханнар нәселеннән.*
- *Оста психолог. Балалар психологиясен искиткеч белә. («Нәҗип» хикәясе моңа мисал булып тора.)*
- *Кайбер әсәрләренең исемнәре үзенчәлекле: кеше исемнәре белән атала.*
- *Сатирик прозаның, яңа юнәлештәге әдәбиятның чишмә башында торган әдип.*
- *Яңарыш чоры әдибе, реалист һәм романтик язучы, милли әдәбиятны модернистик агымнарның тасвирлау чаралары белән баеткан сүз остасы.*
- *Ясалма тел турында «Эсперанто теленең кагыйдәләре» дип аталган татарча китап язучы.*
- *Г. Тукайның иң якын дусты.*
- *Иҗатында жанр төрлелегенә ирешкән сүз остасы (фантастик, сатирик, психологик хикәяләр, драма, повесть, роман, нәсер һ. б.)*
- *Казанның Ф. Әмирхан урамында урнашкан 170 нче мәктәптә язучының музее эшли.*

# «Хәят»

**Язылу вакыты:** 1911 ел

**Жанры:** повесть

**Пафосы:** романтик, әсәрнең эмоциональ яңгырашы көчле

**Темасы:** татар хатын-кызларының язмышы

**Идеясе:** хатын-кыз үз бәхете өчен көрәшергә тиеш.

**Эчке каршылык** Хәятның иреккә, үзен теләгәнчә яшәргә омтылышының моның мөмкин түгеллеген аңлавы, ризалашуы, буйсынуы белән чишелә, әмма автор бу адымны хупламый.

**Проблемалары:**

1) хатын-кыз азатлыгы
2) шәхес иреге
3) тәрбиялелек, әхлаклылык
4) мәхәббәт
5) татар һәм рус җәмгыятендә хатын-кызның тоткан урыны

> *Хәят – язучының эстетик идеалы. М. Мәһдиев язганча, Ф. Әмирхан Хәятка «яза башлаганчы ук гашыйк булган һәм гыйшкы аның повесть ахырына таба гел ускән, гел дәрләгән...».*

## Конфликт

Эчке конфликт:
- Хәятның үз эчендәге кичерешләре – хис һәм акыл көрәше

- Рус һәм татар мохите, яшәү үзенчәлеге аермасы
- Хәят һәм аның тирәлеге
- Хәят белән Михаил
- Хәят белән Лиза




### Повестьның сюжет-композициясе:

- **Экспозиция** → Вакыйгаларның повестьта төрле урыннарда бирелүе
- **Төенләнеш** → Лизаның Хәятны дачага кунакка алып китүе
- **Вакыйгалар үстерелеше** → Хәятның дачага килүе, Михаил белән күрешүе, Әминәләргә кунакка баруы, спектакль каравы, күңел газаплары кичерүе
- **Кульминацион нокта** → Әнисенең Хәятка Салих Фатихов фотосын күрсәтүе
- **Чишелеш** → Хәятның Салихка кияүгә чыгарга карар кылуы («Илаһи, мәхәббәт бир! Илаһи, гомерлек мәхәббәт бир инде!»)


## Әдәби образлар

- ***Кеше образлары:*** *Хәят, Лиза, Михаил, Әминә, Рәхимә абыстай, Бөрһан абзый, Рөкыя, Салих һ. б.*
- ***Табигать образлары:*** *язгы табигать, кышкы кич, сандугач, резедалар һ. б.*
- ***Җыелма образлар:*** *дача, Гыймадовлар һәм Рәхимовлар гаиләсе һ. б.*
- ***Әйбер образлары:*** *күлмәклек батист материал, Әминә бүлмәсендәге урман картинасы, догалык һ. б.*

## Әсәрнең сюжет сызыклары:

- Мәхәббәт тарихы
- Рәхимовлар тормышы
- Гыймадовлар тормышы
- Мясниковлар тормышы

# Рухи матурлык җырчысы



## Гомәр Бәширов

1901–1999

**Татарстанның халык язучысы (1986), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1995), СССР Дәүләт премиясе иясе (1951)**

***Татар музыка сәнгатендә «Җидегән чишмә» җыры – классик әсәргә әйләнгән җыр. Г. Бәшировның әлеге шигыренә композитор Сара Садыйкова көй язган.***

Гомәр Бәширов **1901 елның 7 гыйнварында** Татарстанның Арча районы Яңасала авылында крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәдрәсәсендә белем ала. **1919 елда** Урта Бирәзә мәктәбендә балалар укыта. Гражданнар сугышында катнаша. Бу еллар тарихы булып, «Сиваш» повесте (1937) языла. **1924 елдан** башлап Г. Бәширов, махсус белем алганнан соң, халык судьясы булып эшли. **1932 елдан** ул инде әдәбият, иҗат дөньясында – газета, журналларда, китап нәшриятында хезмәт куя.

Бөек Ватан сугышы чорында Г. Бәширов «Совет әдәбияты» журналында җаваплы мөхәррир, Татарстан радиокомитетының баш мөхәррире булып эшли. Сугыш елларында «Намус» романын яза. Күп телләргә тәрҗемә ителгән бу әсәрне укучылар яратып укыйлар. **1953 елдан** әдип Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайлана, җәмәгать эшләре башкара. Гомәр Бәширов – татар әдәбиятының мактанычы, горурлыгы. Бер гасырлык тормыш юлы үткән, бөтен гомерен татар әдәбиятын үстерүгә багышлаган язучыбызның һәр әсәре – укучысы өчен яшәү мәктәбе.

### Әсәрләре

**«Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә», «Намус», «Сарут», «Сиваш», «И язмыш, язмыш», «Гыйбрәт», «Көзге ачы җилләрдә» һ. б.**

### Иҗат үзенчәлекләре:

- әсәрләренең тема һәм жанр ягыннан төрлелеге;
- иҗаты туган ил, аның халкы белән горурлану хисе уята, хезмәткә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли;
- гади кешеләр тормышы аша гомумкешелек дөньясына хас мәсьәләләрне куя, уйландыра. Шуңа да әсәрләре рус, немец, кытай, поляк, венгр, украин, казах, үзбәк телләренә тәрҗемә ителгән;
- «Намус» романы 18 телдә 35 мәртәбә басыла;
- Г. Бәширов – үзенчәлекле характер остасы; геройлары милли йөзе, сыйфатлары белән аерылып тора;
- әсәрләренең теле халыкчан, үткен, образлы;
- портрет, табигать бизәкләре остасы.

> *Гомәр Бәширов – йөзьяшәр ил агасы – тулы бер гасырның алтын баганасы булып кала алды. Ходай биргән саулык-сәламәтлек белән дә, олуг шәхес кималендә дә, акыл иясе буларак та.*
>
> ***Р. Файзуллин**, шагыйрь*

# «Туган ягым – яшел бишек» (1967)

**Жанры:** автобиографик повесть

**Темасы:** татар халкының яшәү рәвеше, рухи байлыгы, әхлакый нигезе

*Дөрес юлны табу өчен, безгә үзебезнең үткәнебезне, халыкның гүзәл йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кирәк. Фәкать алар гына безгә дөрес юлны табарга, халкыбызга нахак бәла ягучыларга дөрес җавап бирергә ярдәм итәчәк.*

***Г. Баширов***

## Төп вакыйгалар

### Балачак хатирәләре

**Әсәр башында:** 6–7 яшьлек кечкенә Гомәрнең хис-кичерешләре

**Әсәр ахырында:** 17 яшьлек Гомәрнең вакыйгаларга үз карашы, уйланулары

*Язучы татар гаиләсендә бала тәрбияләү тәртибен күрсәтә.*

### Халык язмышы

Инкыйлабка кадәрге татар авылы тормышы, көнкүреше, гореф-гадәтләре

Татар авылларында яшәп килгән:
- мәрхәмәтлелек,
- бер-беренә ярдәмләшү,
- өлкәннәргә булган хөрмәт,
- кызларның мөлаемлыгы, эшкә булганлыгы,
- халыкның гореф-гадәтләрне санлавы, саклавы.

## Идеясе:

Һәр буын үз артыннан яшәү мәгънәсен рухи байлыкта күргән, халыкның рухи кыйммәтләрен саклап һәм санлап яши торган дәвамчылар калдырырга тиеш. Йорт салып калдыруы шуңа ишарәли.

## Вакыйгалар бирелеше

- Колын туу
- Сандугач вакыйгасы
- Сабан туе
- Яңача уку
- Кунак кызлары
- Кунак
- Яңа эш
- Китап уку

## «Туган ягым – яшел бишек» атамасы

**Туган як образы** – туып үскән як; татар халкының тамырларын, яшәү рәвешен саклаган, бер төенгә туплаган нигез, башлангыч нокта.

**Яшел** – авылны чорнап алган тирәлек, табигать төсе, яшәеш төсе.
**Бишек** символы күчле позициягә ия. Ул – сабый баланы тирбәтеп йоклата, юата, ана карынын алмаштыра торган урын.
**Туган якны бишек белән тиңләгәндә,** геройны рухи яктан баету, шәхес буларак «бишек»тә тирбәтеп үстерү, күңел күзәнәкләрен туган җиренә мәңгегә беркетү кебек фикерләр җиткерелә.

**«Туган ягым – яшел бишек»** атамасы – кешенең кендек каны тамган, тәпи басып киткән, аның эчке дөньясын, яшәү рәвешен формалаштырган җирлек; татар халкының тарихын, хәтерен саклый торган изге урын.

# *Бу дөньяның мин бер кыйтгасыдыр...*



## Разил Вәлиев

1947–2023

Татарстанның халык шагыйре (2012), язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2007)

Разил Вәлиев **1947 елның 4 гыйнварында** ТАССРның Түбән Кама районы Ташлык авылында туа. Башлангыч белемне – туган авылында, сигезьеллыкны күрше Шәңгәлче авылында ала. **1965 елда** яңа ачылган Түбән Кама урта мәктәбен тәмамлагач, Р. Вәлиев Казанга килә һәм ике ел университетның журналистика факультетында укый. **1972 елда** Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. **1972 елдан 1981 елга** кадәр «Ялкын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип булып эшли. **1981–1984 елларда** – Чаллы язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе. **1984–1985 елларда** – ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. **1986–2000 елларда** – Татарстан Милли китапханәсе директоры, бер үк вакытта, **1990 елдан 2019 елга** кадәр, Татарстан Республикасы парламенты депутаты, аның президиум әгъзасы, Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе (соңрак – комитеты) җитәкчесе.
**2023 елның 20 октябрендә** Казанда вафат була.

> *Ни генә булмасын, аңа халкыбыз күз уңында заманыбызның мәртәбәле шәхесе, әдибе булып яшәү һәм яшьнәү бәхете бирелгән.*
> ***М. Галиев**, шагыйрь*

## Без моны беләбезме...

- Разил Вәлиев һәм Алмаз Хәмзин бер сыйныфта укыйлар, бер парта артында утыралар.
- Бабасыннан балта тотарга, тегермән тартырга өйрәнә, җәйге каникулда комбайнчы ярдәмчесе булып эшли, олылар белән бергә печән чаба.
- Казан университетына укырга керергә дип, Мөдәррис Әгъләмов белән бергә юлга чыгалар, пароходта киләләр.
- Университет тулай торагында шагыйрь Зөлфәт белән бер бүлмәдә яшиләр: «Детский мир» кибетеннән сатып алып, пардан яшел бишмәт киеп йөриләр.
- «Дулкын» дип аталган беренче җыры Илһам Шакиров соравы буенча язылган. Җырчы шагыйрьне Мәскәүдә үзе эзләп таба.
- 21 яшендә беренче повесте – «Эт кояшы»н яза. Ләкин әсәр егерме ике елдан соң гына басыла.
- 1985 елда Әфганстанга «сугышка командировкага» барган бердәнбер татар шагыйре.
- Кызы тугач, Разил Вәлиев аңа Сөембикә исемен куша.
- Әдәбият институтында киләчәк иҗатына юнәлеш бирүче кешеләрнең берсе – атаклы шагыйрь Лев Ошанин була.

> *Разил Вәлиев шигърияте, гомумән, көчле идея-фәлсәфи егәргә ия, кешегә яшәү, дөнья көтү өчен кыйммәтле гыйбрәтләргә бай, җырлап торган тезек, камил ритмлы, аһәңле рифмаларга корылган зур сәнгати дөнья ул...*
> ***Н. Хисамов**, әдәбият галиме*

### Прозаик

• «Эт кояшы» • «Яшисе килә!» • «Иске сәгать дөрес йөри» • «Мирас» һ. б.

### Публицист

• «Күкләр биек» (1983) җыентыгы һ. б.

### Шагыйрь

• «...Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә...» • «Кеше» • «Саубуллашу» • «Ватаным» • «Сагынам» • «Бәхетем башкаласы» • «Саумы, Казан!» һ. б.

### Җырлар авторы

• «Ватаным» • «Сагынам» • «Нигә, әни, нигә картаясың?» • «Бер алманы бишкә бүләек» • «Яшьлек ядкяре» • «Зинһар өчен, кермә төшләремә» һ. б.
Ф. Әхмәтов, Р. Яхин, М. Яруллин, Р. Абдуллин, Л. Батыр-Болгари, Р. Ахиярова, Ш. Тимербулатов һәм башка композиторлар белән берлектә иҗат ителгән ике йөзгә якын җыры бар.

### Драматург

Р. Вәлиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк!» (1989), «И машина, машина, җитте минем башыма» (1990), «Куркыныч уен» (1989), «Мәңгелек иман» һ. б. пьесалары язылып, күбесе К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры, шулай ук республиканың башка театрлары сәхнәләрендә куела.

# «Ватаным өчен» (1969)

**Әдәби төре:** лирика
**Жанры:** гражданлык лирикасы
**Мотивы:** горурлык

**Әлеге шигырьгә Рәшит Абдуллин көй язган, ул җыр тексты буларак та билгеле.**

## Ватанның сыйфатлары:

- гасырлар дәвамында яуларда, сугышларда җиңеп чыккан;
- горурланырлык кешеләре бар;
- Ватаным дип, утларга-суларга керерлек батырлары бар;
- кешеләрне күтәрә;
- таң булып атарлык эшләре һәм даны, якты киләчәге бар.

## Лирик герой:

- Үз Ватанының олылыгын, бөеклеген таный;
- туган иленең батырлары белән горурлана белә;
- Ватанын чын күңелдән ярата;
- үзен Ватанының бер кисәге итеп тоя;
- якты киләчәккә ышана;
- матурлыкны, яхшылыкны күрә белә һ. б.

**Лирик геройның хисе:**

- соклану
- горурлык

**Хисенең сәбәбе:**

- туган илнең яуларда җиңеп чыгуы;
- Ватанның батырлары, горурланырлык эшләре булу

Мәгънәне көчәйтү өчен кулланылган **стилистик фигуралар:**

- **Анафора –** «***Батырлар*** *исемен атадым.* ***Батырлар*** *утларга кердeләр...*»
- **Инверсия –** *«Мин күрдем, төннәрне таратып, Дөньяда алсу таң атканын...»*
- **Градация –** ***«Яктыра, аллана*** *җир йөзе...»*

**Троплар:**

- **Метафора –** *«Батырлар* ***утларга*** *кердeләр...»*
- **Чагыштыру –** ***«Таң булып нур сибә*** *Ватаным...»*

## Темасы:

Ватанга мәхәббәт, туган илне ярату, кешеләренең батырлыгы белән горурлану

## Идеясе:

**кешеләр үз гамәлләре белән Ватанны бөек итә, Ватан кешеләрне олылый.**
(Кешеләр күтәрде Ватанны, Кешене күтәрде Ватаным.)

# Күңелләрнең моңлы тургае



## Ибраһим Гази

1907–1971

Татар әдәбиятының күренекле вәкиле, язучы, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1969)

Ибраһим Мингазиев **1907 елның 4 февралендә** хәзерге Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы Иске (Олы) Карамалы авылында крестьян гаиләсендә туа. Бик яшьли ятим калып, төрле михнәтләр, мохтаҗлыклар күреп үсә. **1919–1924 елларда** ул Тәтештәге балалар йортында тәрбияләнә, шунда урта белем ала, актив җәмәгать эшчәнлеген башлый.

**1924–1926 елларда** Казандагы өлкә партия мәктәбендә укый. Комсомол секретаре, Татарстан өлкә комитетында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире булып эшли. Бер үк вакытта ул Казанда чыга торган «Авыл яшьләре» журналында һәм «Кызыл яшьләр» газетасында мөхәррирлек вазифаларын башкара.

**1931–1942 еллар** арасында Ибраһим Гази махсус курслар тәмамлый, озак еллар нәшриятта мөхәррир һәм тәрҗемәче булып эшли. «Совет әдәбияты» журналының җаваплы мөхәррире вазифасын башкара. Бу елларда ул рус һәм дөнья әдәбиятының аерым үрнәкләрен татар укучысына җиткерү буенча да нәтиҗәле эшли. Антон Чехов, Максим Горький, Михаил Салтыков-Щедрин, Мопассан, Золя кебек классик язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итеп, Ибраһим Гази үзен оста, иҗади тәрҗемәче итеп таныта.

**1943 елдан** башлап, Җиңү көненә кадәр Ибраһим Гази хәрәкәттәге армия сафында, фронтта татар телендә чыга торган «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

Ибраһим Гази иҗатының иң югары ноктасы сугыштан соңгы чорга – узган гасырның илленче һәм алтмышынчы елларына туры килә. Әлеге чорның кырыс шартларында кешеләрнең тыныч хезмәттәге фидакярлеген яктырткан әсәрләр яза.

Язучылык хезмәте һәм иҗтимагый тормышта актив эшчәнлеге өчен ул Хезмәт Кызыл Байрагы һәм ике тапкыр «Почёт билгесе» орденнары белән бүләкләнә.

Ибраһим Гази **1971 елның 21 февралендә** Казанда вафат була.

> *Һәр хикәям нинди дә булса бер вакыйга нигезендә туган. Алар һәммәсе дә үз заманының кыйпылчыгы. Барысына да заманнең кайнар сулышы сеңеп калган. Һәркайсының тарихы бар... Кайвакыт, хикәя тусын өчен, әһәмиятле бер буяуның табылуы да җитә. Калганын язучының хыялы үзе эшләп җиткерә...*
>
> ***И. Гази***

## Проза әсәрләре

• «Тургай картаямы икән?» • «Өч Мәхмүт» • «Алмагачлар чәчәк ата» • «Балконлы йортта» • «Малай чак» • «Икмәк, винтовка һәм мәхәббәт» • «Канатланыр чак» һ. б.

**«Онытылмас еллар» трилогиясе**
**(әчтәлеге белән ул татар халкы тормышындагы зур бер тарихи чорны яктырткан трилогия)**

**Беренче кисәк**

Инкыйлабка кадәрге татар авылы тормышы, крестьяннарның көнкүреше, җирсезлектән һәм социаль гаделсезлекләрдән бөлгенлеккә төшүләре тасвирлана.

**Икенче кисәк**

1917 елгы инкыйлаб вакыйгалары һәм Гражданнар сугышы күренешләре, гыйбрәтле язмышлар сурәтләнә.

**Өченче кисәк**

Әсәрнең төп герое Хәлимнең тормышы, авылда күмәкләштерү елларында аның яңа тормыш өчен башкарган эш-гамәлләре, сөйгән кызы Кафия белән булган саф мәхәббәт хисләре, күңел кичерешләре бирелә.

«Онытылмас еллар» трилогиясе өчен Ибраһим Гази Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1988–1989 елларда, әлеге әсәргә нигезләнеп, Татарстан телевидениесендә күп серияле телевизион фильм төшерелә.

# «Кояш артыннан киткән тургай»

**Жанры:** хикәя
**Темасы:** туган җиргә мәхәббәт һәм күңел матурлыгы

**Төп герой** – туган ягын сагынып, читтән кайткан ир кеше (чөнки «малай чакта ат саклаган» тезмәсе бар). Хикәяләүче герой туган ягын ихлас күңелдән ярата, аның һәр почмагыннан матурлык эзли. Шул матурлык белән илһамланып яши. Балачак эзләреннән йөри, сагыну хисе көчле.

## Әдәби катламнар

- Вакыйгалар катламы
- Метафорик катлам (табигать күренешләре)
- Хис-кичереш катламы

## Тел-сурәтләү чаралары:

**Чагыштыру** («кар тауларыдай өелеп торган болыт», «таш кебек атылып» һ. б.)
**Эпитет** («күккә чәчрәгән соңгы кояш нуры» һ. б.)
**Метафора** («болытлар ялкынланып яналар», «болытларга ут капты» һ. б.)
**Гипербола** («кояш гүя эрегән, ...минем башка тамачак» һ. б.)
**Сынландыру** («бакалар кешнәшә», «җир тургайга каршы сикерде», «егылып төшеп килә» һ. б.)

**Тургай** – очкан вакытта да сайрый торган, әмма күзгә чалынмый торган кош. Аны күрер өчен югарыга, күккә карарга кирәк. Хикәядә тургай образы символик мәгънәгә ия. Ул кешене биеклеккә өнди, матурлыкны күрергә чакыра. Әсәрдә кеше рухының бөеклеген аңлата.

## Ретроспекция алымы

**Балачакның иң якты хатирәсен** искә төшерү өчен матур көнне сәфәр чыга

**Олы күлгә сәяхәт**
- махсус бер көн билгели;
- иң матур көн;

| | |
|---|---|
| «көн сүрелеп бетмәгән иде әле» | Хикәяләүченең хисләр кайнарлыгын аңлата |
| «тузан кайнарлыгы» | Янып яшәп **узган** гомер |
| «кояш гүя эрегән», «кояш кызуы», «кояш әкрен генә иңә» | Кеше гомеренең үтүе |
| «сары кош» | Хикәяләүче үзе |
| «тургай җыры» | Балачакның матур истәлекләре, кешенең яшәү җыры |
| «күк йөзе зәп-зәңгәр, ял-якты» | Авторның уйлары, хыяллары якты, ачык |
| «болытлар ялкынланып яналар» | Авторның уйлары, хыяллары якты, ачык |
| «бакалар кешнәшә» | Кеше өлкәнәйсә дә, күңеле белән барыбер сабый булып кала |
| тургай образы | Кеше |
| тургайның «әнисе кояштыр», «җирдә инде кояш юк», «югарыда кояш бар әле» | Кояш – җирдәге һәр тереклекнең, җан иясенең яшәү чыганагы, көч, илһам бирүче «әнисе». Автор КОЯШ образында ӘНИне күрә. Кеше өчен иң кадерле илаһи зат ул. Ана рухының олылыгы турында сөйли. |

И туган тел, и матур тел...

# Илһамым – мәхәббәтем



## Шәүкәт Галиев

1928–2011

Татарстанның халык шагыйре (1995), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1972), Ганс Христиан Андерсен исемендәге халыкара диплом иясе (1982), А. П. Гайдар билгесенә (1984) һәм А. Алиш исемендәге әдәби бүләккә (1996) ия балалар шагыйре.

Шәүкәт Һидиятуллин **1928 елның 20 ноябрендә** Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында дөньяга килә. Туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, районда төрле вазифалар башкара. «Колхоз бригадасы» төбәк газетасында җаваплы сәркатип, мөхәррир була. Беренче шигырьләрен ул 5 нче сыйныфта ук яза башлый, аларны җыр дәфтәренә теркәп бара. Ә төгәл вакыты билгеле булган беренче шигыре «Моң» исемле. Тәүге шигырьләре матбугатта **1948 елда** күренә башлый. **1953 елда** Казанга күченә, «Чаян» журналында эшли. Кичке урта мәктәпне һәм Мәскәүдә Югары әдәби курсларны тәмамлый. Шигъри талантының һәм иҗатының зур өлеше балалар әдәбияты белән бәйле. Татарстан китап нәшриятының нәфис әдәбият редакциясенә җитәкчелек итә. Озак еллар «Сабантуй» («Яшь ленинчы») газетасында хезмәт куя.

> Шагыйрь татар әдәбиятының алтын хәзинәсен үзенең күп санлы шигъри җәүһәрләре белән генә баетып калмады, балалар поэзиясендә үзенең шигъри мәктәбен дә тудырды.
>
> **Р. Миңнуллин**, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе

### Прозаик

• «Әз-мәз мәзәк» (1979) • «Илһамым – мәхәббәтем» (1986) • «Минем беренче гомерем» (1997)

### Балалар шагыйре

• «Шәвәли» • «Тәмле йорт» • «Котбетдин мәргән» • «Көлке бүлмәсе» • «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр» • «Пәрәмәч» • «Телевизор булды баш»

### Җырлар авторы

- «Кыңгыраулы мәктәп еллары» (Р. Хәсәнов, Х. Вәлиуллин)
- «Утыр әле яннарыма» (И. Хисамов)
- «Тамчылап тамар чаклар» (Ф. Әхмәтов)
- «Күпме күзләр күреп онытылган» (М. Яруллин, Р. Гомәров)
- «Шомырт чәчәкләре ак кына» (Х. Вәлиуллин)
- «Сөенечкә дисәм...» (И. Шакиров)

> **Берәү матурлыкны тудырып рәхәт таба, берәү әзеренә соклана. Миңа матурлыкны иҗат итү кызыклы.**
>
> **Ш. Галиев**

### Без моны беләбезме...

- Ш. Галиевнең якын иҗади дуслары – шагыйрь Илдар Юзеев һәм Хәсән Туфан.
- 1958 елда командировка вакытында 5 көн эчендә 14 җыр яза. Бу җырлар барысы да хит булып китә, хәзер дә халык күңелендә яши.
- Шагыйрь гомер буе көндәлек алып бара. Язуы искиткеч матур һәм пөхтә була.
- Роберт Миңнуллин Ш. Галиевне үзенең әдәби остазы дип санаган.
- Туган ягы Апас районы Олы Бакырчы авылында һәм Казан шәһәренең 17 нче татар гимназиясендә шагыйрьнең музейлары эшләп килә.
- 2019 елда «Көмеш кыңгырау» газетасы редакциясе һәм Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан Ш. Галиев исемендәге әдәби-иҗтимагый премия булдырыла.

### Афоризмнар остасы

- Әдип гомере – халыкта.
- Хак сүз – хакыйкать илчесе.
- Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел.
- Милләтнең киләчәге – мәктәп.

> Шәүкәтнең балалар әдәбиятындагы иҗаты гүзәл бер вакыйга булып тора... Бу иҗат – буыннан буынга, гомердән гомергә күчеп, еракка, киләчәккә барырлык иҗат.
>
> **Х. Туфан**, шагыйрь




# «Мин – Шәвәли, шук малай...»

**1961 елда** Ш. Галиев Шәвәли турында шигырь яза. Аны «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы сәркатибе Марс Шабаев күреп ала: сурәтен ясата, кереш сүз яза: «Бүгеннән башлап Шәвәли газета битләрендә яши башлаячак. Аңа хәерле юл теләгез!»

## Мин

Мин –
Шәвәли,
Шук малай,
Үткен малай,
Ут малай!
Мин –
Бик уңган,
Өлгер
Мин,
Юк-бар белән
Көлдермим!
Бик тапкыр
Мин,
Җыйнак
Мин.
Мин,
Мин,
Мин бик
Тыйнак мин!

Шигырьнең формасы тəз басып торучы бала сынын хəтерләтә.

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без – «Туган тел»дән туганнар,
Без – Тукай оныклары!



Шәвәли рәсемен **рәссам Юрий Денисов** уйлап таба: пионер галстугы «бәйләтә», башына яшел кәләпүш «киертә».

**Шәвәли – гомерлеккә балалыкта калган герой. Ул берьюлы биш-унбиш яшьләр арасында яши. Чаян йолдызлыгы астында туган.**

**Шәвәли турында тулы бер цикл шигырьләр иҗат ителәә:** «Шәвәли сәгате», «Шәвәли хәйләсе», «Шәвәли ничә яшьтә?», «Таныш шофёр», «Серен белдем соңыннан», «Шәвәли һәм аю», «Юмартлык».

**Шәвәли** – балалар әдәбиятында үз урынын тапкан әдәби герой.
Җор телле, үткен һәм тапкыр. Тормыштагы көтелмәгән хәлләрдә юмор хисен саклап кала. Игътибарлы, тирә-юньдәге бер генә әйберне дә күз уңыннан ычкындырмый.

**Төп йорты** – «Сабантуй» (элеккеге «Яшь ленинчы») газетасы. «Прописка»га **1963 елда** теркәлгән.

Үлемсез әдәби герой **бүгенгәчә балалар дөньясында яши**.

**Шәвәлинең прототибы** – Шәвәли Кәлимуллин, шагыйрьнең балачак дусты. Җор телле, тапкыр сүзле Шәвәли ага гомере буе Апас районы Олы Бакырчы авылында гомер итә. Балта остасы була. Тырыш һәм намуслы булуы белән авылдашларының ихтирамын казанып яши.

# Киң колачлы талант иясе



## Аяз Гыйләҗев

1928–2002

**Татарстанның халык язучысы (1993), драматург, публицист, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1983), РСФСРның А. М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе иясе (1987), Г. Исхакый премиясе лауреаты (1995)**

Чаллы дәүләт драма театры А. Гыйләҗев исемен йөртә.

## Әсәрләре

### Проза әсәрләре

• «Өч аршын җир» • «Язгы кәрваннар» • «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» • «Җомга көн, кич белән...» • «Әтәч менгән читәнгә» • «Балта кем кулында?» • «Яра» һ.б.

### Драмалары

• «Көзге ачы җилләрдә» • «Җиз кыңгырау» • «Кар астында кайнар чишмә» • «Әгәр бик сагынсаң» • «Дус кызым кияүгә чыга» • «Эңгер-меңгер» • «Сары чәчәк ата көнбагыш» һ.б.

## Моны белү кызыклы...

1. Иң беренче хикәясе аңа егерме яшь булганда басылып чыга. «Ян, учагым, ян!» исемле лирик хикәя була.
2. «Йөгез, бер дога!» роман-хатирәсе язучының шәхси тормышына – сәяси тоткынлыкта үткәргән биш ел гомеренә багышлана.
3. «Җомга көн, кич белән» әсәренә нигезләнеп, «Бибинур» фильмы төшерелә.
4. Ирекккә чыккач та, озак еллар кимсетүле карашлар тоеп яши, язмаларын беркайда бастырмыйлар. Чарасызлыктан язучының кайбер хикәяләре хатыны Нәкыя Гыймадиева исеме белән дөнья күрә.
5. Язучының уллары – драматург Мансур Гыйләҗев, галим Искәндәр Гыйләҗев.
6. Язганнары арасыннан үзенә иң якын әсәре «Яра» повесте була.
7. Аяз Гыйләҗев гомер буе көндәлекләр алып бара.

**1928 елның 17 гыйнварында** хәзерге Татарстан Республикасының Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Бала чагы һәм мәктәп еллары күршедәге Зәй районының Югары Баграж исемле керәшен татарлары авылында уза. Шул авыл мәктәбенең тугыз сыйныфын һәм Сарман урта мәктәбендә унынчыны тәмамлаганнан соң **(1945 ел)**, берникадәр вакыт колхозда эшли, аннары ике елга якын комсомолның Зәй район комитетында бүлек мөдире хезмәтендә була. **1948 елда** Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. **1950 елда** «советларга каршы пропаганда өчен» хөкем ителә. Иреккә чыкканнан соң **(1955 ел)**, университетта укуын дәвам итә.
**1957–1961 елларда** «Чаян», «Азат хатын» журналларында әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» журналының проза бүлегендә мөхәррир булып эшли. **1963 елда** Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый.
А. Гыйләҗев таланты бигрәк тә проза жанрында ачыла. Ул шәхес характерын билгеләүдә әхлак принципларына өстенлек бирә. Бу – язучы иҗатында төп тема.

> *Аяз Гыйләҗев – әдәбиятыбызның төрле тармакларында ут уйнаткан кеше. Ул – күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, үткен каләмле публицист һәм очеркист, ниһаять, усал телле тәнкыйтьче.*
> ***Ф. Миңнуллин**, тәнкыйтьче*

XX гасырның 60–70 нче елларында театр коллективларына «Өч аршын җир» әсәрен сәхнәдә кую тыела. Бары Актаныш халык театры режиссёры Ф. Ибраһимов кына аны 1980 елда сәхнәләштерергә батырчылык итә. Хәзерге көндә әсәр сәхнәдә куела. Повесть төрле телләргә тәрҗемә ителеп, басылып чыккан.

# «Өч аршын җир» (1962)

**Әдәби төре:** проза

**Жанры:** повесть

**Темасы:** кылган гамәлең өчен ил, халык алдында, туган җир каршында җаваплылык

## Проблемалары:

1) ялгыз кеше язмышы;
2) шәхес иреге;
3) тәрбия, әхлак;
4) рухи кыерсытылу;
5) иҗтимагый тормыш;
6) сыйнфый каршылык һ. б.

**Тышкы конфликт**

- **Шәхси вакыйгалар** (гаиләсе, авылдашлары белән бәйле вакыйгалар) → Тормышының кискен бер мизгелендә хата кылган һәм шул ялгышы өчен гомерлек газапка дучар ителгән Мирвәлинең **үз эчендәге кичерешләре** – үч алу, хаталану һәм **үз-үзен гафу итә алмау хисе**
- **Иҗтимагый вакыйгалар** (җәмгыятьнең гадел булмавы, шәхеснең рухын сындыру белән бәйле вакыйгалар)

**Эчке конфликт** → Тормышының кискен бер мизгелендә хата кылган һәм шул ялгышы өчен гомерлек газапка дучар ителгән Мирвәлинең үз эчендәге кичерешләре

**Әдәби образлар**

- **Кеше образлары:** Мирвәли, Шәмсегаян, Шәйхразый, Адаш, Таифә, фельдшер кыз, Хәйдәр, Шәрифҗан, Газизҗан
- **Табигать образлары:** төнге урман, тау кыры, авыл табигате, инеш
- **Җыелма образлар:** авылдашлар, поезддагы пассажирлар
- **Символик образ-детальләр:** нигез, өч кое, зират, тугыз тирәк, 58 чакрым юл, васыять, җыр, ут, өч аршын җир, наратка сыенып үскән каен образы, шәл, больницадагы тәрәзә пәрдәсе (метафора), Шәмсегаян чиккән сөлге, туган як туфрагы, әрем, урман, миләүшә һ.б.

**Символик саннар һәм исем поэтикасын бирүдә үлчәм алымы:** 3 аршын җир, 18 нче поездның 4 нче вагоны, больницага кадәрге 8 чакрым юл, ул авылдан Карачурага кадәр 58 чакрым, икесенә дә 58 яшь, авылдан чыгып киткәнгә 30 ел үткән, торган җирдән туган авылларына 3 тәүлек кайтасы, 3 кое, 9 тирәк.

**Идеясе:** һәркемнең тормышы үлем белән чикләнә, тормыш нинди генә авырлыклар алдына куйса да, кешелегеңне җуймау, өч аршын җиргә дә лаеклы була алу, туган якның кечкенә генә бер кисәгенә дә ирешә алу кирәк, кеше гомере буе шуңа омтылып, тугрылыклы калып яшәргә бурычлы, чөнки туган җир – изге җир ул!

*Автор аны Шәмсегаян авызыннан әйттерә: «Туган җиреңнән олы булмассың...»*

## Сюжет элементлары:

- **Экспозиция** → Ерак Көнчыгыштан поездда туган якларына кайтып баручы Мирвәли хатыны Шәмсегаянның авырып китүе
- **Төенләнеш** → Шәмсегаянның поезддан төшеп калуы, иренә васыяте, больницада вафат булуы
- **Вакыйгалар үстерелеше** → Мирвәлинең туган авылына ат арбасында кайтканда узган гомерен искә төшерүе, күңеленнән хатынының рухы белән сөйләшүе
- **Кульминацион нокта** → Мирвәлинең кайчандыр каргап чыгып киткән туган авылына кайтуы. Авылдашларыннан үлгәннән соң, авыл зиратына җирләүләрен үтенеп соравы.
- **Чишелеш** → авылдашларының Мирвәлине кичерүе

## Хронотоп:

| | |
|---|---|
| 1 көн | Мирвәлигә 58 яшь |
| Туган авылга юл – 58 чакрым | 58 еллык гомерне искә төшерә |

# «Җилкәнен киргән кораб...»



## Дәрдемәнд
1859–1921

### Шагыйрь

- «Кораб»
- «Каләмгә хитаб»
- «Без»
- «Видагъ»
- «Бүзләрем маналмадым»
- «Бәллү»
- «Хәят» һ. б.

**XX гасыр башы татар шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, иганәче, алтын приискалары хуҗасы, сәнәгатьче**

Мөхәммәтзакир Рәмиев **1859 елның 23 ноябрендә** Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязендәге (хәзерге Башкортстанның Мәләвез районы) Җиргән авылында туа. **1862 елның** җәендә әтисе, гаиләсен алып, Орск өязенең Юлык авылына күчеп китә. Закирны һәм аның абыйсын башта өйдә укыталар. Аннары Муллакай авылындагы мәдрәсәгә бирәләр. Закир **1880–1881 елларда** Истанбулда яши, төрек телен, әдәбиятын өйрәнә. Ул Орск шәһәре сәүдәгәре Закир Борнаевның Мәһүбә исемле кызына өйләнә һәм Оренбургка күчә. Октябрь инкыйлабыннан соң типографиясен, алтын приискаларын яңа хакимияткә тапшыра. З. Рәмиевнең шәхси китапханәсен әрәм итеп, яндырып бетерәләр.

**1921 елгы** ачлык вакытында халыкка ярдәм итү эшен оештыруга керешә, ләкин авырып китә һәм **шул елның 9 октябрендә** тиф авыруыннан вафат була.

> *Дәрдемәнд шигырьне бастыру, сатып акча табу, кешедән макталу өчен язмый... Ул шигырьгә югары бер нәфис сәнгать дип карый, шуннан тәм таба, шуңа күрә вакыт-вакыт аның белән шөгыльләнә иде.*
>
> ***Ф. Кәрими**, язучы*

### Иҗади үзенчәлекләре:

- XX гасыр башы татар шигъриятен яңа баскычка күтәрүче, Яңарыш чоры милли әдәбиятына нигез салучы.
- Романтик поэзия вәкиле, фәлсәфи романтизмга өстенлек бирә.
- Дәрдемәнд шигъриятенә фикер тирәнлеге, фәлсәфәнең киңлеге хас.
- Әсәрләрен символизм агымында яза, күпмәгънәле символларга таяна.
- Үзенең шигырьләре белән XX йөз башында формалашып килгән татар шигъриятенең яңа үсеш юлын билгели.
- Шигъриятенең төп мотивлары – яшәү һәм үлем, тәкъдир, язмыш, гомер агышы, вакыт, кеше, яшәү фанилыгы.
- Киная остасы.

### Без моны беләбезме...

**1.** Дәрдемәнд – Закир Рәмиевнең псевдонимы. Ул «сагышлы, кайгылы, моңлы, зарлы» дигәнне аңлата.
**2.** Дәрдемәнд 5 тел белгән: татар, рус, гарәп, фарсы, төрек.
**3.** Иң танылган әсәре – «Кораб».
**4.** Иң еш кабатланган шигъри юллары – «Сөт калыр, Ватан китәр!».
**5.** Тормыш иптәше белән 9 бала тәрбияләп үстерә. Улы – Искәндәр Рәмиев репрессиягә эләгә һәм атып үтерелә. Закир Рәмиевнең оныгы Бәшир Рәмиев – техник фәннәр докторы, ул Россиядә ЭВМны беренче уйлап табучы дип санала.
**6.** Аларны Россиянең «алтын корольләре» дип йөртәләр.
**7.** Шагыйрьнең әнисе атаклы морза Дашковлар нәселеннән була.

### Матбагачы (нашир)

1905 елдан Шакир белән Закир Рәмиевләр Оренбургта газета-журналлар бастыру эшенә керешәләр. 1906 елда «Вакыт» газетасын чыгара башлыйлар. Газета башта атнасына өч тапкыр, аннары көн саен басыла. Баш мөхәррире – Фатих Кәрими.
1908 елдан «Шура» журналын чыгара башлыйлар. Мөхәррире – Риза Фәхретдин. Бу ике басма да 1918 елда ябыла.

### Сәнәгатьче

1890–1900 елларда бертуган Шакир белән Закирга аталарыннан Орск өязендәге алтын ятмалары күчә. 20 дән артык алтын приискаларында 1917 елга кадәр барлыгы 5 тонна алтын табыла. Приискаларда барлыгы 850 эшче көч куя.

### Иганәче

- Алынган табышка татар әдипләренең китапларын бастыралар;
- авылда хастаханә төзиләр;
- ел саен татар, башкорт балаларын танылган уку йортларында укытып кайтаралар;
- бернича мәчет, мәдрәсә салалар;
- Дәрдемәнд XX йөз башы әдәби һәм мәдәни күтәрелешен матди яктан тәэмин итә.

> *Бер тәлинкәсендә — Дәрдемәнд,*
> *икенчесендә — Закир Рәмиев алтыннары...*
> *Кайсы баса? Шигырьләре баса...*
> ***С. Хәким***

# «Кораб» (1908)

Тарих стихиясен гәүдәләндерә. Бу чорда ил зур үзгәрешләр кичерә. Шушы кичерешләр дулкынында ил һәм халык язмышы кай якка үзгәрер? Автор шул хакта уйлана.

## Символик образлар:

- **Кораб**
  - *ИЛ язмышы*
  - *КЕШЕЛӘР язмышы*
  - *МИЛЛӘТ язмышы*
- **Диңгез** — Тормыш, яшәеш. Шаулавы – вакыт агышы
- **Җил** — Илдәге иҗтимагый-социаль үзгәрешләр
- **Дулкын** — Язмышны үзгәртердәй көч
- **– ят ил**
  **– юл**
  **– упкын**
  **- җан**
  образлары

- Шигырьнең үзәгендә язмышның билгесезлегеннән туган борчу, хәсрәт ята.
- Шигырьнең бөтен эчтәлеге символ тирәсенә тупланган.
- Символизм агымы кысаларында иҗат ителгән.
- Фәлсәфи яктан күпмәгънәле шигырь.

## Шагыйрь КОРАБ язмышын өч төрле заман агышында тасвирлый:

### үткән

*Шаулый диңгез…*
*Җил өрәдер…*
*Җилкәнен киргән кораб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөрәдер:*
*Юл бара ят ил карап…*

*– шаулы диңгез картинасы күзаллана*
*– күп юллар үтеп килгән кораб җилкәнен киергән*
*– ят илләр белән таныша*
*– әйтеп бетерелмәгән фикер күп нокталар ярдәмендә бирелә*

### хәзерге

*Чыкты җилләр,*
*Купты дулкын –*
*Ил корабын җил сөрә!..*

*– җил чыгу, дулкын кузгалу картинасы тудырыла*
*– ил корабы образы*
*– өндәү һәм күп нокталар аша шул чордагы авыр халәт тергезелә*

### киләчәк

*Кайсы юллар,*
*Нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?!*

*– билгесезлек төсмере тагын да көчәя. Автор тарафыннан упкын образы тудырыла*
*– җан сорау, фида кылу аркылы халык / милләт, кешелек язмышының киләчәге билгесезлек алдына куела*
*– сорау һәм өндәү билгеләре уйланырга чакыра*

## Темасы:

ил, аның халкының, татар милләтенең авыр һәм катлаулы язмышы

## Идеясе:

иҗтимагый-социаль авырлыклар ил, халык, дәүләт язмышына көчле тәэсир ясый, язмышларын билгесезлек алдына куя

**Инверсия күренеше:** «шаулый диңгез», «чыкты җилләр», «купты дулкын».

*Татар халкы әлеге шигырьне көйгә салып та башкара.*

# Әдәби мирасны тәрбия максатларында куллану

МЕНТАЛЬ КАРТАЛАР  ӘДӘБИ НУРЛАР.



## Нәҗип Думави
1881–1933

### Шагыйрь
«Мәхбүс»
«Син – Кеше!»
«Яз»
«Татар»
«Үтә яшьлек» һ. б.

### Прозаик
«Яшь ана»
«Су кызы»
«Кем гаепле?»
«Ике мәхәббәт» һ. б.

## XX гасыр башы татар шагыйре һәм язучысы

Нәҗип Тахтамышев Аксубай районындагы Яңа Дума авылында **1883 елның 19 маенда** туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. Унбер яшендә Кизләү мәдрәсәсенә илтәләр. Анда бер кышны укып чыккач, Казандагы Габдулла Апанаев мәдрәсәсенә керә. Аны бирედә һади Максуди да укыта. Нәҗип Думави татар балалары өчен ачылган рус мәктәбендә дә укый.
Акча юнәтү теләге белән казах далаларына китә. Чистайда, Кизелдә, Иж-Бубый мәдрәсәсендә, Рязань губернасының Вәрәки авылында һәм Үзбәкстанда Сәмәрканд педагогика институтында укыта.
**1911 елның** башында жандармерия Иж-Бубый мәдрәсәсен тар-мар китерә, мөгаллимнәрне кулга ала, шәкертләрне тарата. Н. Думави да кулга алына һәм Сарапул төрмәсендә тугыз айдан артыграк утырып чыга.
Ул **1904–1905 елгы** япон һәм **1914 елгы** империалистик сугышларга алына, полк писаре вазифаларын башкарганлыктан, турыдан-туры сугыш хәрәкәтләрендә катнашмый.
**1921–1925 елларда** туган авылында мулла вазифасын үти.
**1933 елның 5 маенда** Сәмәркандта вафат була.

## Моны белү кызыклы...

- Язучы үзенә әдәби тәхәллүс итеп туган авылы исемен ала.
- Күп укый, табигать фәннәре, фәлсәфә белән кызыксына.
- Туган ягында мәктәпкә Н. Думави исеме бирелгән.
- Татарстанның Нурлат шәһәрендә язучы исемен йөрткән урам бар.

> Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиевләрдән кала, бу дәвернең көчле шагыйрьләреннән берсе шул иде.
>
> **Г. Сәгъди**, әдәбият галиме

## Иҗади үзенчәлекләре:

башлангыч чор иҗаты **мәгърифәтчелек идеяләре** белән сугарылган. Алга таба иҗатында **тәнкыйди реализм** мотивлары өстенлек ала. Соңга таба модернистик агым – **экспрессионизм йогынтысы** сизелә;

– **шигъриятендә төп темалар:** милләт, аның язмышы, киләчәге, көрәнекле шәхесләре, кеше, аның яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи уйланулар, «мәхбүс», «тоткын», «сугыш» мотивлары;

– **прозада төп темалар:** сугыш фаҗигасе, ятимлек, фәкыйрь һәм физик яктан гарип балалар тормышының сурәтләнеше, хатын-кыз мәсьәләләре;

– **тарихи риваять, хикәя-легендаларга** нигезләнеп иҗат итү: мистик, мифологик, романтик, символик образлар тудыру һ. б.



И туган тел, и матур тел...

# «Яшь ана» (1914)

**Әдәби төре:** проза (эпик төр)

**Жанры:** хикәя

*Хикәя Зәһидәнең күңел кичерешләре, яшь ана белән мөнәсәбәтләре турында*

**Хронотоп** – әсәрдә чагылган урын һәм вакыт бөтенлеге.
**Ишегалды** – таныш җир. Зәһидәгә якын булган үткән тормыш. Ул үзен анда хуҗа итеп тота, теләгәнен эшли.
**Бакча** – таныш түгел, киләчәк тормыш. Ул Зәһидәне куркыта. Кызчык бик сак эш йөртә, һәрнәрсәгә шикләнеп карый, әнисе турындагы авыр уйларга бирелә.

## Образлар системасы

**Җыелма образ:** гаилә

**Табигать образлары:** ишегалды, бакча, кош-кортлар

**Кеше образлары:** Зәһидә, Хәмид, әнисе, яшь ана, доктор, асраулар

**Символик образлар:** тарак, чәчкә

Ретроспекция алымы (үткәнне искә төшерү)

**Табигать образлары** Зәһидә образын ачарга ярдәм итә. Кызыксынучан, шук Зәһидә бакчадагы чәчкәләр кебек нәзакәтле, нәфис, пакь, гөнаһсыз.

**Төп герой – Зәһидә.** Ул – зәңгәр күзле, сары чәчле, саф күңелле, кызыксынучан, хәрәкәтчән, биш яше дә тулмаган самими кызчык. Әнисе үлгәнен белми, аны кайтыр дип, бик сагынып көтә. Әнисе үлгәннән соң, асрауларның үзенә мөнәсәбәте үзгәргәнен сизеп: «Әй, әнкәй, ник соң инде тизрәк кайтмыйсың?» – дип кабатлый. Тарак тапкач, бик сөенә. Зәһидә – буын дәвамчысы, үткәнне һәм киләчәкне бәйләп торучы образ.

**Ярдәмче герой** – Хәмид агай. Ул кызын бик ярата. Хатынын юксыну аны да сагышка сала. Кызының күзендә хатынын күргән төсле була.

**Аталучы геройлар** – асраулар, үз әнисе, доктор. Асраулар кырын карыйлар, көн саен юындырмыйлар, каты тоталар.

**Тарак** – үткән белән бүгенгене тоташтыра торган хәтер, олы мәхәббәт хатирәсе. Хәмид агайның тәүге мәхәббәт хатирәсе, истәлек билгесе. Үткәнне онытып, яңа тормыш башлаган Хәмид абый бер нәрсәне аңлый: үткәнне онытып булмаячак, бала үткән белән бүгенгене бәйли. Зәһидә – әнисенең дәвамчысы.

Психологизм алымы (күңел халәтен ачу)

**Катнашучы (эпизодик) герой** – яшь ана. Ул мәрхәмәтле, нечкә күңелле, олы йөрәкле. Яшь ана мәхәббәте Зәһидәнең әниле булу өметен сүндерми. Хикәянең соңгы җөмләләре кызның бала чагы җылы кочакта үтәр дигән ышаныч уята.

Тарак образы аша ЯШЬ АНА образы **көчле позициягә** чыгарыла.


**Һәр образ Зәһидәнең сагышын, фаҗигасен күрсәтә.**

Хикәяләүче Зәһидәгә бары яхшы теләктә генә. Аның фәрештә күңеле төсле сафлыгына, балалыгына соклана; кайгы-хәсрәтенә борчыла, яшь бала күңеленең сызлануын, сыкрануын тоеп сагышлана.

## Сюжет элементлары:

**Экспозиция** – Зәһидә белән танышу, «кунакка киткән» әнисен көтеп, бакчада йөрүе
**Төенләнеш** – бакчадан әнисенең тарагын табып алуы
**Вакыйгалар үстерелеше** – Хәмид абыйның яшь хатын алып кайтуы, Зәһидә белән таныштырырга теләве
**Кульминацион нокта** – кызчыкның әтисенә таракны бирүе
**Чишелеш** – яшь ананың Зәһидәне үз әниседәй кочып алуы; «Мин кайттым, кызым» дигән сүзләре

# Рухи матурлык җырчысы



## Әмирхан Еники

1909–2020

**Татар әдәбиятының горурлыгы, күренекле әдип, тәрҗемәче. Татарстанның халык язучысы (1989), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984), Гаяз Исхакый премиясе лауреаты (1993)**

*Татар әдәбиятының морзасы.*
*Т. Миңнуллин,* *драматург*

### Әсәрләре

**Сугыш шартларында кешенең рухи чыдамлыгын тасвирлау**

«Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Кем җырлады?» (1956) һ. б.

**Кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, әхлакый проблемаларны яктырту**

«Саз чәчәге» (1955), «Туган туфрак» (1959), «Рәшә» (1962), «Матурлык» (1964), «Без дә солдат идек» (1971), «Әйтелмәгән васыять» (1965) һ. б.

Әмирхан Еникиев **1909 елның 2 мартында** Башкортстан Республикасы Благовар районы Яңа Каргалы авылында туа. **1910 елның** көзендә гаиләләре Дәүләкәнгә күченә. Бала чагы Дәүләкән авылында уза. Беренче укытучысы – әтисе. **1925 елда** Казанга килә һәм китап кибетенә курьер булып урнаша. **1926 елда** Казан дәүләт университеты каршындагы рабфакка укырга керә, язучылык эше белән кызыксына башлый, тәүге хикәяләре дөнья күрә. **1941–1945 елларда** Бөек Ватан сугышында катнаша. Бөтен гомерен әдәбиятка багышлый. Тәрҗемә эше белән шөгыльләнә.

*Иҗат эше минем өчен башта ук шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйле көчле һәм намус эше иде.*

*Халык күңеленә юл салу ансат эш түгел: язучыдан саф вөҗдан, чын гаделлек, искиткеч зур тырышлык һәм батырлык сорый.*

*Ә. Еники*

**Психологизм остасы.** Әсәрләрендә геройларның кичерешләрен, дөньяны үзләренчә аңлауларын үзенчәлекле сурәтләү чаралары аша тапшыра алган **талант иясе**.



### Без моны беләбезме...

- Ә. Еники – морзалар нәселеннән.
- Аңардан алда туган 9 бала да үлеп китә, гаиләдә 10 бала булып Әмирхан туа.
- «Кем җырлады?» хикәясендәге Таһирә белән әдип сугышта таныша, Таһирә укытучы була.
- Еники – язучының тәхәллүсе.
- Әмирхан Еники белән рус язучысы Александр Куприн арасында туганлык җепләре бар.
- Яраткан песие – Аппак.

*Ә. Еники – матур сүз остасы... Ул – проза белән яза торган шагыйрь.*
*Н. Нәҗми,* *шагыйрь*

# «Әйтелмәгән васыять» (1965)

## Образлар системасы

**Төп герой** – Акъәби
**Ярдәмче геройлар** – Суфиян, Гөлбикә, Сәхип, Мария Васильевна, Миңлебай карт, шагыйрь, Геннадий, Гүзәл
**Эпизодик геройлар** – Гарифә, Сәетгали, авылдашлар, Татьяна, Светлана, Рита, Борис, Равил, докторлар, асрау кыз, әбинең оныклары
**Аталучы геройлар** – Миңлегәрәй, Миңлегали, Гыйльман агай, Казахстандагы улы, кызы Сөембикә, дворник хатыны Сәрбиҗамал апа, кунаклар, морг эшчеләре
**Характер** – Акъәби, Миңлебай карт, шагыйрь
**Җыелма образлар** – өлкән буын, урта һәм яшь буын
**Әйбер образлары** – сандык h. б.
**Ясалма образлар** – учак, кылганнар, васыять, камчы символлары

## Әсәрнең сюжеты

*Акъәби һәм аның балалары, оныклары арасында аңлашылмаучылык тарихы*

### Төп тышкы конфликт (каршылык):
*Акъәби һәм аның балалары арасында*

- Балалар → Акъәби
- Гөлбикә → курка, рухи тамырларын оныткан
- Килен, Гөлбикә балалары, Суфиян балалары → тел белми
- Кияү → битараф

### Конфликтның сәбәбе:
*карашлар төрлелеге, рухи каршылык*

### Темасы:
*буыннар арасында рухи бәйләнешләр өзелү*

### Идеясе: *буыннар арасында рухи бәйләнеш өзелмәскә, кыйммәтләр югалмаска тиеш!*
«Учагында уты сүнмәсен» (Миңлебай карт сүзләре)

### Символ

**КЫЛГАННАР ОБРАЗЫ**
- *йөгерәләр (селкенеп, кыштырдап, тырышып, кабаланып);*
- *йөгерә кебек, ләкин бер урында тора;*
- *җил уңаена бөгеләләр.*

**АКЪӘБИНЕҢ БАЛАЛАРЫ**
- *заманны, тормышны тизләтеп алып барабыз дип уйлыйлар, ә чынлыкта алар тик торалар;*
- *заман кайсы якка бөксә, шул якка бөгеләләр. Алар, җил уңаена бөгелгән кылганнар кебек, иманнарын югалтканнар, туган туфрактан аерылганнар. Алар – тормыш уңаена яраклашучылар.*

## Сюжет элементлары

**Экспозиция** – Акъәбинең тормышны, туган нигезен яратуын тасвирлау өлеше

**Төенләнеш** – Акъәбинең шәһәргә киткәндә кәфенлеген онытып калдыру турында әйткән сүзләре

**Вакыйгалар үстерелеше** – әбинең шәһәргә китүе, балаларына васыятен әйтергә омтылып каравы, табибка күренүе, шагыйрь белән сөйләшүе, балаларының әбине хастаханәгә салулары

**Кульминацион нокта** – әбинең үлеме

**Чишелеш** – сандык килү; аннан (өлкән буын хәзинәсеннән) явызлык символы булган камчыны алып калу

**Эпилог** – Миңлебай картның Гарифәгә учакны сүндермәү турында әйткән сүзләре

# Җырга әйләнгән гомер



## Муса Җәлил

1906–1944

### Ә сез моны беләсезме?

- **1956 елның 2 февралендә** сугышта күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен **Советлар Союзы Герое** исеме бирелә.
- «Моабит дәфтәрләре» циклы **Ленин премиясенә** лаек була.
- Бу ике югары бүләкне берьюлы алган бердәнбер әдип.
- Шигырьләре дөньяның **56 теленә** тәрҗемә ителгән.

---

- **Муса Җәлилов 1906 елның 15 февралендә** Оренбург өлкәсе Шарлык районы Мостафа авылында дөньяга килә.
- 10–11 яшендә шигырьләр яза башлый.
- **1919 елда** тәүге шигыре «Бәхет» газетасында басылып чыга. Башта авыл мәктәбендә, аннан «Хөсәения» мәдрәсәсендә, соңрак хәрби мәктәптә, ә **1925 елда** Казанда рабфакта, Мәскәү университетының әдәби бүлегендә укый. Илебез башкаласында «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» исемле балалар журналларын оештыра.
- **1935 елда** Мәскәүдә татар опера студиясен оештыруда катнаша.
- **1941 елда** үзе теләп сугышка китә.
- Сугышта Волхов фронтындагы «Отвага» газетасы хезмәткәре.
- **1942 елның 26 июнендә,** каты яраланып, әсирлеккә эләгә, Германиягә озатыла. Немецлар, төрки-татар әсирләреннән легион төзеп, аны фронтка җибәрергә әзерләнәләр.

  Лагерьда фашистларга каршы яшерен оешма төзелә, М. Җәлил шушы оешма эшендә катнаша, җитәкчеләренең берсе була.
- Дошманнар оешманың эзенә төшә. **1944 елның 25 августында** Плётцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең һәм аның 10 көрәштәшенең башы киселә.
- Шагыйрь тоткынлыкта 791 көн була.

> *Дөньяда шулай итеп яшәргә кирәк:*
> *үлгәннән соң да үлмәслек булсын...*
>
> ***М. Җәлил***

### 1920–1930 нчы еллар иҗаты (1919–1941)

«Карак песи», «Сәгать», «Маэмай», «Парашютсыз курчак», «Әтәч», «Чишмә», «Хат ташучы», «Алтынчәч» һ. б.

### Сугыш чоры иҗаты (1941–1944)

**Фронт лирикасы (1941–1942)**

«Чулпанга», «Хуш, акыллым», «Тупчы анты», «Окоптан хат», «Әйдә, җырым» һ. б.

**Тоткынлык чоры иҗаты («Моабит дәфтәрләре», 1942–1944)**

«Кичер, илем», «Дуска», «Ышанма», «Җырларым», «Чәчәкләр», «Вәхшәт», «Бүреләр», «Катыйльгә», «Хөкем алдыннан», «Кошчык» һ. б.

---

- «Моабит дәфтәрләре» – шартлы исем. Аны шагыйрь үзе куймый, шигырьләрне, Моабит төрмәсендә теркәлүенә, төрмәдә иҗат ителүенә бәйле рәвештә_, туган илдә шулай атап йөртә башлыйлар.
- Франциядәге Ле-Пюи лагерендагы татар әсирләре кулына килеп кергән беренче дәфтәрне туган илгә **1946 елда** әсир Нигъмәт Терегулов алып кайта.
- **1947 елда** Бельгиядәге Брюссель шәһәрендә урнашкан Совет илчелеге Казанга Мусаның тагын бер дәфтәрен җибәрә. Аны илчелеккә бельгияле, Моабит төрмәсендә Җәлил белән бер камерада утырган, дәфтәрне шагыйрь гозере буенча алып чыккан Андре Тиммерманс тапшыра.

### Моны белү кызыклы...

- Җәлил шахмат уйнарга яраткан, җиңгән очракларда бала кебек куанган, ә җиңелгәндә үзенә грошмейстер дип әйтә торган булган.
- Шагыйрь, язудан тыш, музыканы да яраткан, аның хәтта үз мандолинасы булган, ул пианино алу турында хыялланган.
- Матур җырлаган.
- Шәп чаңгычы булган.
- Беренче басылган шигырендә үзен «кечкенә Җәлил» дип куйган.
- Муса Җәлил исемен йөрткән кече планета бар. 3092 нче санлы әлеге планета – «Җәлил» астероиды – Кырымдагы астрофизик обсерваториядә астроном Т. Смирнов тарафыннан 1972 елда ачыла. Аның Кояштан ераклыгы – 2,4–2,8 астрономик берәмлек. Кояш тирәли 4,1 ел эчендә әйләнеп чыга.

# «Җырларым» (1943)

**Әдәби төре:** ЛИРИКА

**Жанры:** ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫ

**Мотивы:** туган илгә тугрылыкны раслау

**Лирик геройның хис-кичерешләре:** сагыш һәм горурлык

**Җыр образы** → **Җыр символы**

Гомеренең керсез матурлыгын ачып бирә торган **метафора:**

*Гомерем минем моңлы бер җыр иде,*
*Үлемем дә яңгырар җыр булып...*

- **Илгә тугрылыкны раслау, антның эчтәлеген ачу чарасы:**

  *Үлгәндә дә йөрәк туры калыр*
  *Шигъремдәге изге антына...*

- **Батырлыкны раслау символы:**


  *Бар җырымны илгә багышладым,*
  *Гомремне дә бирәм халкыма.*

*Җырларым, сез шытып йөрәгемдә*
*Ил кырында чәчәк* ***атыгыз!***
*Күпме булса сездә көч һәм ялкын,*
*Шулкадәрле җирдә* ***хаккыгыз!***

**тезмә** · **строфа** · **рифма**

**Идеясе:** Шигырьдә яшәүнең, үлемнең, иҗатның ил өчен булырга тиешлеге әйтелә. Илгә багышланган җырлар һәм илне яклап үлү үлемсезлек китерә дигән фикер раслана.

# Тылсымлы сүз остасы



## Зөлфәт
1947–2007

**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1992), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2000)**

*Зөлфәт давыл булып яшәде һәм мәңге сүнми торган поэзия калдырды.*
***Ф. Садриев**, язучы*

Зөлфәт Маликов **1947 елның 3 гыйнварында** Татарстанның Мөслим районы Яңа Сәет авылында колхозчы гаиләсендә туа. Үз районындагы Уразмәт авылы урта мәктәбен тәмамлагач, **1965–1969 елларда** Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. **1969 елның апреленнән** ул журналистлык хезмәтендә: алты ел – «Чаян» журналы редакциясендә, аннары, **1977 елны,** Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») республика балалар газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. **1983 елның** көзеннән яңадан «Чаян»га күчеп, журнал редакциясенең әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли.
Зөлфәт **2007 елның 15 маенда** Казанда вафат була, Казанның Яңа Бистә зиратына җирләнә.

## Иҗатка килү юлы

**Беренче шигъри тәҗрибәләре матбугатта студент елларында күренә башлый. 1968 елда егермеләп шигыре «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкка керә. 1971 елда нәшер ителгән «Язмышлар ярында» исемле беренче мөстәкыйль җыентыгы исә әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан татар шигъриятенә үзенчәлекле бер шагыйрь килүен раслаган вакыйга буларак кабул ителә.**

## Без моны беләбезме...

- Зөлфәт белән М. Әгъләмов дуслыгы – легендар дуслык.
- Әтисе тимер остасы була, тимердән ни тели, шуны ясый белә.
- Зөлфәтне мәктәптә әдәбияттан Рәдиф Гаташ укыта, ул аны шигърияткә кертеп җибәрә.
- Шагыйрьне җирләгәндә гаҗәеп хәл була. Май ае, зиратта сандугачлар сайрап тора, җәсәден ләхеткә төшергәндә сандугачлар кинәт туктап кала.
- Казан шәһәре Татарстан урамында Зөлфәт яшәгән 7 нче йортка истәлек тактасы куелган.

### Лирикасы

● «Дүрт җыр» ● «Кем әле син?» ● «Ай сонатасы» ● «Нигез» ● «Туган тел хакында» ● «Тыным бетте...» ● «Язмышлар ярында» ● «Тылсым» ● «Кичер» ● «Җилләр чиртә сары камылларга...» ● «Әни!» ● «Ялгызлык» ● «Шулай икән...» һ. б.

### Поэмалары

● «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» ● «Иске Казан карлыгачы» ● «Җирдән кайтышлый» һ. б.

### Балладалары

● «Тимерче турында баллада» ● «Ике ат турында баллада» ● «Гармунчы турында баллада» ● «Кара күбәләк» һ. б.

### Җырлары

● «Һаман яратам» ● «Төнге утлар» ● «Кара толым» ● «Сагынуга дәва юк» һ. б.

### Либреттосы

«Мәкерле песи» (Л. Хәйретдинова муз.)

### Пьесалары

● «Җен кызы» ● «Гасырдан озын бер көн» ● «Ат ереккән бер төн» ● «Сагынуга дәва юк» һ. б.

### Тәрҗемәләре

● «Юлбасарлар» (Ф. Шиллер драмасы) ● «Йөгәнсезгә авызлык» (У. Шекспир) ● «Биюче» (Лопе де Вега)

## Иҗади үзенчәлекләре:

- лирикасы романтизмга йөз тотып үсә;
- шигъри сөйләмдә традиционлыкка, сүз сәнгатенең халык җыры, бәет-дастаннардан үстерелә килгән романтик традицияләренә өстенлек бирә;
- гражданлык лирикасы, күңел лирикасы һәм фәлсәфи лирика жанрларында эшли;
- үзәктә – вазгыятьне аңлаган, аны башкаларга да җиткерү өмете белән янган, үз тавышын ишеттерү максатын куйган актив лирик герой;
- баллада һәм поэма жанрларында иҗат итә, либретто жанрында эшли, тәрҗемә эше белән шөгыльләнә;
- шигырьләрендә символлар, эзоп теле алымы ярдәмендә җәмгыятькә бәя бирә, фәлсәфи фикерләр үткәрә, шулар аша укучыга йогынты ясау максатын куя, экспрессия алымына таяна;
- сүз уйнату остасы («йөрәген былбыл чакты» һәм «өздереп елан сайрады»).

# «Дүрт җыр» (1970)

**Әдәби төре:** ЛИРИКА

**Жанры:** КҮҢЕЛ ЛИРИКАСЫ

**Мотивы:** иҗат һәм яшәү мәгънәсе

**Җыр образы** → **Җыр символы**

Җыр образы: Үз иҗатының, шигъриятенең төп тематик юнәлешләрен һәм яшәү маякларын ачып биргән **образ**

Җыр символы:
- туган ил, халык язмышы;
- мәхәббәт;
- туган як, әниләр;
- хакыйкать

*Икенче җыр... әни турында ул,*
*Ун мең еллык моңлы **көйдер ул;***
*Бу җиһанда җанны җылытучы*
*Бердәнбер вөй, изге **өйдер ул**.*


тезмә • строфа • рифма

## Тел-сурәтләү чаралары:

- **Эпифора –** «Тирбәлешеп торган кырдыр ул... әни турында ул, ...моңлы көйдер ул» һ. б.
- **Инверсия –** «Чыдар микән йөрәк ахыргача Җырлаганчы шуның барын да?» һ. б.
- **Метафора –** «...Сөю турындадыр – Мең яңарган иске моңдыр ул»
- **Чагыштыру –** «Йөрәк кадәр чәчәк бөреләре»
- **Эпитет –** «көмеш җырлар» һ. б.

**Идеясе:** Шигырьдә лирик герой иҗат хакыйкатен җиткерә. Иҗатның туган ил, мәхәббәт, туган як, әни һәм мәңгелек хакында булырга тиешлеген искәртә. Шушы төшенчәләрнең кешенең яшәү мәгънәсе булырга тиешлеге турында сөйли.

# Күпкырлы талант иясе



## Галимҗан Ибраһимов

1887–1938

Татар әдәбиятының классигы, энциклопедист-галим, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Герое, XX йөз башы татар дөньясында әһәмиятле урын тоткан, әдәбият һәм мәдәният тарихында тирән эз калдырган олпат шәхес.

**1887 елның 12 мартында** Башкортстан Республикасы Авыргазы районы Солтанморат авылында мулла гаиләсендә туа. Әти-әнисеннән укырга-язарга өйрәнә, авыл мәдрәсәсендә, башлангыч мәктәптә, Оренбург, Уфа мәдрәсәләрендә белем ала. Беренче хикәяләре дөнья күрә.
**1909 елда** Казанга килә, әдәби иҗатка чума. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укытучы булып эшләгәндә татар теле, әдәбияты буенча дәреслекләр, фәнни мәкаләләр яза, әсәрләр иҗат итә.
Иҗат белән янәшәдә фәнни эшчәнлек һәм җәмәгать эшләре белән шөгыльләнә.
Каты авыру сәбәпле, гомеренең соңгы елларын Кырымда – Ялтада уздыра.
Халык дошманы дип гаепләнеп, кулга алына. **1938 елда** Казанда төрмә хастаханәсендә гомере өзелә.

> **...Халкым алдында да минем гаебем юк. Тарих аны үзе тикшерер, раслар, дөрес бәһа бирер.**
>
> **Г. Ибраһимов**

## Кыска гына әйткәндә...

- Әдипнең туганнары Башкортстанда, Татарстанда, Үзбәкстанда яши.
- Улы Рөстәмнең үлемен бик авыр кичерә.
- Хатыны Гөлсем Мөхәммәдова әдип турында «Зур тормыш» (1968), «Яшьлек көннәре» (1975), «Эзләнүләр» (1987), «Олы юл» (1994) исемле документаль китаплар яза.

## Ә сез моны беләсезме?

Г. Ибраһимов әсәрләре рус, украин, азәрбайҗан, башкорт, казах, кыргыз, таҗик, төрекмән, үзбәк, чуваш һ. б. телләргә тәрҗемә ителгән.

## Беренче чор иҗаты (1907–1917)

«Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Диңгездә», «Татар хатыны ниләр күрми», «Көтүчеләр», «Карт ялчы» һ. б.

## Икенче чор иҗаты (1917–1938)

«Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Адәмнәр» һ. б.

## Ә сез моны беләсезме?

Казанда Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Г. Ибраһимов исемен йөртә. Шулай ук Казанда аның исемен йөрткән зур урам – проспект, татар гимназиясе бар. Әлеге гимназиядә әдипнең музее урнашкан. Туган ягы Солтанморатта да музее эшли.

# «Алмачуар» («Бер мәхәббәт тарихы») (1922)

XX йөз башы татар авылы тормышын, аның гүзәл табигатен, хезмәт сөючән кешеләрен, гореф-гадәтләрен, өмет-хыялларын чагылдырган классик әсәр




**Жанры:** хикәя

**Идеясе:** һәркем ярату хисен, аны сөйгән җан иясен сакларга, кайгыртып торырга тиеш, гаделсезлек шуны эшләгән кешегә бәхетсезлек китерә, башкаларга да зыян сала, үзе турында гына уйлаган кеше һәрвакыт җәзасын ала.

Г. Ибраһимов атлар яраткан һәм болай дип язган:

> **Атлар ярату миңа әтидән күчкән булса кирәк. «Алмачуар» дигән хикәям дә үз тормышымнан алып язылган дисәм дә, ялгыш булмас...**

**Әсәр Закирның үз-үзен ярату һәм атны ярату-югалту тарихын тергезә**

## Төп вакыйгалар:

1. Әлемгол Озын Хафизга бия бүләк итә
2. Колын туу шатлыгы
3. Алмачуарның яралануы
4. Закирның колынны сабанга җиктерүгә каршы төшүе
5. Алмачуарны чабышка әзерләү
6. Ат чабышында катнашу
7. Гаделсезлек
8. Алмачуарның үлеме

| Гаделсезлек вакыйгалары | Гаепне тану-танымау | Нәтиҗә | Җәзаның йогынтысы |
|---|---|---|---|
| Хафизның улын кара бай нахакка утырта. | Кара бай гаебен танымый, гафу үтенми. | Кара бай үлә. | Хафизның улы 20 елга төрмәгә эләгә. |
| Әлемгол керәштә Хафизны хәрәмләп ега һәм җиңә. | Әлемгол авырый, гаебен таный. | Нәзерен үти. | Хафиз имгәнә, керәшкә башка чыкмый. |
| Староста Закирга беренчелекне бирми. | Староста гафу үтенә. | Закирны беренчелеккә чыгара, акча бирә. | Старостаның бите яралана. |
| Закир старостаның битенә камчы белән суга. | Хатасын соң таный, гафу үтенми, үен эчендә генә калдыра. | Аты үлә. | Закирга иң зур җәза бирелә: дөньяны ярату хасиятен югалта. Яшәү яме тапмау – кеше хәсрәтләренең иң зурысы. |

# Милләт хадиме



## Гаяз Исхакый

1878–1954

**XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле язучысы, драматург, яңа реалистик әдәбиятка нигез салучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе**

*Ул фәкать идеал өчен тартыша торган иң саф бер фидакяр иде.*

***Й. Акчура,***
*галим, җәмәгать эшлеклесе*

Мөхәммәтгаяз Исхакый **1878 елның 22 февралендә** Казан губернасы Чистай өязе Яуширмә авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. 5 яшеннән укырга-язарга өйрәнә. Башлангыч белемне туган авылында ала, аннан Чистай мәдрәсәсендә, Казанның Күл буе мәдрәсәсендә укый.

Әдәбиятка Гаяз шактый иртә килә. «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле беренче әсәрен 17 яшендә яза. Казан татар укытучылар мәктәбендә белем ала, Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсендә балалар укыта. Туган ягында мулла була. Соңрак революцион хәрәкәткә кушылып китә. Чистайдан сайланган мөселман делегаты буларак Петербургка бара. Әдипнең тормышында шактый күп эзәрлекләү, кулга алыну, азат ителү, качып йөрүләр була. Тоткынлыктан котылу өчен, ул Финляндия, Төркиядә яши, әмма иҗаттан аерылмый, төрле жанрларда яза. **1913 елда** Мәскәүдә «Ил», «Сүз», «Безнең ил» газеталарын чыгара. Мәскәү мөселман комитеты рәисе итеп сайлана. Яңа хөкүмәтнең сәясәте белән килешмичә, **1919 елда** Ерак Көнчыгыш аркылы чит илгә китә. Мөһаҗирлектә дә милләт яшәеше һәм язмышы турында кайгыртуын дәвам итә. **1928 елда** Варшавада «Идел-Урал» комитетын төзүдә катнаша. Чит илдә яшәгәндә дә, ул татар милли матбугатын чыгаруга зур әһәмият бирә. Аның катнашында **1928–1930 елларда** «Милли юл» журналы дөнья күрә. Алга таба ул «Яңа милли юл» исеме белән Берлин шәһәрендә нәшер ителә. Моннан тыш, әдип **1935–1945 елларда** Кытайның Мукден шәһәрендә чыгарылган «Милли байрак» газетасын оештыруда актив катнаша.

**1954 елның 22 июлендә** Төркиядә Гаяз Исхакыйның йөрәге тибүдән туктый. Үзенең васыяте буенча, аны Истанбулдагы Әдернәкапы зиратында җирлиләр.

### Мәгърифәтчелек чоры (1898–1904)

**«Тәгаллемдә сәгадәт»**
**«Кәләпүшче кыз»**
**«Өч хатын белән тормыш»**
**«Бай углы»**
**«Ике йөз елдан соң инкыйраз»**

### «Таңчы»лык чоры (1905–1911)

**«Зиндан»**
**«Теләнче кызы»**
**«Сөннәтче бабай»**
**«Тормышмы бу?»**
**«Алдым-бирдем»**
**«Тартышу»**
һ. б.

### Милләтчелек чоры (1912–1918)

**«Зөләйха»**
**«Мулла бабай»**
**«Ул әле өйләнмәгән иде»**
**«Остазбикә»**
**«Мөгаллимә»**
**«Кәҗүл читек»** һ. б.

### Мөһаҗирлек чоры (1919–1954)

**«Көз»**
**«Дулкын эчендә»**
**«Өйгә таба»**
**«Олуг Мөхәммәд»**
**«Җан Баевич»**
һ. б.

## Моны белү кызыклы

- Г. Исхакый, Варшавада яшәп, Берлинда «Милли юл» журналын (соңрак – «Яңа милли юл») чыгара.
- «Чыңгыз», «Чура батыр», «Иделбай», «Илтөзәр» – язучының тәхәллусләре (псевдонимнары).
- Язучы рәсем сәнгате белән кызыксынган. Парижда Луврда бик озак итеп йөрергә яраткан.
- Кызы Сәгадәт Чагатай – галимә, профессор. Төркиядә яшәгән.
- 1991 елда Татарстан Республикасында Гаяз Исхакый исемендәге премия булдырыла.
- Туган ягы – Чистай районы Яуширмә авылында әдипнең музее эшли.

**Әдәби төре:** проза

**Жанры:** повесть

**Темасы:** татар халкында яшәп килгән традиция – ир баланы сөннәткә утырту йоласы аша дини-милли йолаларга тугрылык, буыннар бәйләнеше

**Проблемалары:**

- гореф-гадәтләрнең, сөннәтчелек кәсебенең юкка чыгуы;
- чисталык, пөхтәлек;
- буыннар арасында бәйләнеш өзелү;
- үзара мөнәсәбәт, ихтирам, хөрмәт, мәхәббәт мәсьәләләре.

**Идеясе:** татар халкының яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, сөннәтчелек эше сакланырга тиеш, гомумән, милләт яшәешен укымышлы кешеләр тәэмин итәргә тиеш.

## Сәнгатьчә эшләнеше һәм яңалыгы:

- сюжет-композициясенең төзеклеге;
- образ-характерларның сәнгатьчә эшләнеше камил булу;
- лиризм белән трагизмның үрелеп баруы;
- геройларның рухи дөньясын ачуда психологизм алымнарына мөрәҗәгать итү;
- моңарчы беркем дә сурәтләмәгән сөннәтчелек белән шөгыльләнүче кеше образын тудыру;
- әдипнең үз геройларын җиңелчә юмор белән яратып сурәтләве.

# «Сөннәтче бабай» (1911)

## Хикәянең сюжет-композициясе:

- **Экспозиция** → Сөннәтче бабайның нәселе, яшәү рәвеше, яраткан шөгыле һәм Гөлйөзем әби белән матур гына гомер кичерүе
- **Төенләнеш** → Гөлйөзем әбинең үлеме
- **Вакыйгалар үстерелеше** →
  – бабайның ялгыз яшәве;
  – икенче хатынга өйләнүе;
  – тормышыннан уңмавы, бабайның эчке каршылыгы.
- **Кульминацион нокта** → Икенче хатынның сөннәт пәкесе белән бәрәңге әрчүе
- **Чишелеш** → Сөннәтче бабайның икенче хатынына талак әйтүе һәм икенче көнне үлүе

*Сөннәтче бабайның Гөлйөзем әби белән яшәгән чоры* ⟷ *Сөннәтче бабайның икенче хатыны белән тормышы*

Йорттагы тормыш иң югары дәрәҗәдәге ислам дине канунннары, әхлагы белән сугарылган. Бабайның яшәү рәвеше эчкерсез, саф; тәне һәрвакыт ару-таза, күңеле пакь. Әби белән гомер бакый килешеп яши.

**Каршылык**

- **Эчке каршылык:** *Сөннәтче бабайның күңел каршылыгы*
- **Тышкы каршылык:** *Сөннәтче бабай* ⟷ *Икенче хатыны*

И туган тел, и матур тел...

# Татар драматургиясенең атасы



## Галиәсгар Камал
1879–1933


### Әсәрләре:

«Бәхетсез егет»
«Беренче театр»
«Бүләк өчен»
«Банкрот»
«Уйнаш»
«Безнең шәһәрнең серләре» һ. б.

## Татар драматургиясе классигы, тәрҗемәче, театр эшлеклесе

**Галиәсгар Камалетдинов 1879 елның 6 гыйнварында** Казанда туа. Бала чагын Арча районы Түбән Масрада бабалары тәрбиясендә уздыра. Алты яшькә җиткәч, шунда мәктәпкә йөри башлый, аннары, Казанга кайтып, укуын иске тәртиптәге «Касыймия», «Госмания» һәм «Халидия», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә дәвам итә. Өч классы рус мәктәбендә башлангыч белем ала. Әдәбият һәм театр сәнгате белән кызыксына башлый: рус театрында барган спектакльләргә яратып йөри. **1898 елда** ул үзенең беренче драмасы – «Бәхетсез егет»не (I варианты) яза. Күп тә үтми, икенчесе дә языла («Өч бәдбәхет»). Бу ике әсәр һәм шул чорда Г. Камал тарафыннан тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» драмасы (төрек язучысы Намык Кәмал әсәре) **1900 елда** Казанда аерым китаплар булып басылып чыга. Каллиграф булып эшли. «Мәгариф көтебханәсе» дип аталган китап бастыру һәм сату ширкәте оештыра. **1905 елның октябрендә** Казанда беренче татар газетасы – «Казан мөхбире»н, соңрак «Азат», «Азат халык» газеталарын, «Яшен» сатирик журналын чыгаруга зур өлеш кертә. Н. Гоголь, А. Островский, М. Горький, Мольер әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

**1906 елның 5 маенда** Казанда беренче рәсми спектакль уйнала. Г. Камал тәрҗемә иткән «Кызганыч бала» драмасы һәм Габдрахман Кәрам тәрҗемәсендә «Гыйшык бәласе» комедиясе куела. Шул көннәрдән башлап Галиәсгар Камал үзенең төп игътибарын татар театрын үстерүгә бирә. Драматург **1933 елда** вафат була.





Татар дәүләт академия театры 1939 елдан бирле Галиәсгар Камал исемен йөртә.

> *Татар театры, татар драматургиясе дигәч тә, күңелдә иң элек Галиәсгар Камал образы җанлана. Без аны реалистик драматургия һәм театр бинасын салырга керешкән беренче ташчы дип беләбез.*
> ***И. Нуруллин**, әдәбият галиме*

### Камаллар нәселендә татар театр сәнгате тарихында тирән эз калдырган шәхесләр:

1) **Галиәсгар Галиәкбәр улы** Камал, драматург.
2) **Габдулла Галиәкбәр улы** (Камал I) драма актёры, режиссёр. Галиәсгар Камалның энесе.
3) **Габдрахман Галиәкбәр улы** (Камал II), драма актёры, Галиәсгар һәм Галиәкбәр Камалның энесе.
4) **Зәйнәп Галиәкбәр кызы** Камалова, драма актрисасы, Татарстанның атказанган артисты. Галиәсгар, Габдулла һәм Габдрахман Камалларның сеңлесе.
5) **Фатыйма Хәйрулла кызы** Камалова, драма актрисасы, Габдулла Камалның хатыны.
6) **Әнәс Галиәсгар улы** Камал, драматург, Галиәсгар Камалның улы.
7) **Гәүһәр Габдулла кызы** Камалова, драма актрисасы, Габдулла һәм Фатыйма Камаллар кызы.

### Моны белү кызыклы...

- Аны «татарның Островские» дип йөртәләр.
- Казанның 4 мәдрәсәсендә белем ала.
- Тукай белән якын дуслар була.
- Беренче татар афишаларын иҗат итә.
- Белгечләр аны «комедиограф» дип атый.
- «Йолдыз» газетасы хәбәрчесе буларак Истанбулда була.
- 5 малай һәм 1 кыз тәрбияләп үстерә.
- Г. Тукай әсәрләренә беренче иллюстрацияләрне ясый.
- Мәкәрҗә ярминкәсендә җырчы буларак таныла.
- Драматург яшәгән йорт бүгенге көннәргә кадәр сакланган.
- Көчле тәрҗемәче. Төрекчә, русча пьесаларны татарчага тәрҗемә итә.
- Оста каллиграф һәм рәссам. 30 дан артык хәреф язу төрен уйлап таба.
- Прозаик («Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт», «Күгәргән алтыннар» хикәяләре билгеле).

# «Беренче театр» (1908)

**Әдәби төре:** драматургия
**Жанры:** комедия
**Темасы:** беренче театр куелу, татар дөньясына яңалыкның үтеп керүе
**Төп конфликт:** искелек белән яңалык көрәше
**Идеясе:** яңалык, нинди генә киртәләргә очрамасын, барыбер җиңеп чыга

## Драманың сюжет-композициясе:

| | |
|---|---|
| **Экспозиция** | Беренче тапкыр татарча театр буласын белеп, Хәмзә байның балалары, якыннары театрга барырга әзерләнәләр, ә Хәмзә бай үзе театрны булдырмаска тырышып йөри. |
| **Төенләнеш** | Хәмзә байның балалары, якыннары театрга китәләр. |
| **Хәрәкәт үстерелеше** | асрау кыз Биби аларның театрга китүләрен Хәмзә байга әйтергә әзерләнә. |
| **Кульминацион нокта** | Хәмзә бай кайтып керә, һәм Биби барысының да театрга китүләрен әйтеп бирә. |
| **Чишелеш** | Хәмзә бай нәрсә эшләргә белми, ачулана, көлкегә кала. Яңалык җиңеп чыга. |

## Төп тышкы каршылык

**Хәмзә бай.** Иске карашлы Казан бае, ләкин зәвыклы. Өйдә үзен хуҗа итеп тота. Туктаусыз сукрана, орыша.

↔

**Балалары.** Яңалыкка омтылучан буын. Кияү-килене үткен, үз дигәннәренә ирешә торганнар.

## Ярдәмче тышкы каршылыклар

Вәли – Гафифә

Хәбибрахман – Факиһә

Биби → Вәли, Факиһә, Фатих, Хәмзә бай

## Эчке каршылык

**Гафифә**

*Театрга барасы килә, ләкин курка.*

***Вәли җиңә:** «бармак башы кадәр генә булса да, революция булды». Алдынгы карашлы. Укыган. Дөнья яңалыклары белән хәбәрдар Вәли җиңә.*

**Хәбибрахман**

*«Минем үземнең дә бик күрәсе килә-килүен театр дигән нәрсәне, ләкин әти ни әйтер».*

***Факиһә җиңә.** Үз сүзен әйтергә курыкмый. Кыю. Яңалыкларны белеп бара. Кешедән калышырга теләми.*

**Хәмзә бай**

*Театр куйдырмаска тырыша.*

*Күпме генә карышса да, **театр була.** Үзе дә балалары артыннан театрга китеп бара. Көлкегә кала.*

### Сәнгатьчә эшләнеше:

- *сюжет-композиция төзеклеге;*
- *образ-характерларның гаять уңышлы эшләнеше;*
- *вакыйга-күренешләрнең үзара тыгыз бәйләнештә төп идеяне ачуга хезмәт итүе;*
- *юмор-сатира, сүз уйнату алымнарының гаять уңышлы кулланылуы.*

*Хәмзә байның прототибы – Г. Камалның кайнатасы (хатынының әтисе) була.*
*Хәмзә бай ролен беренче тапкыр сәхнәдә Г. Кариев башкара.*

# *Иң садә хисләр җырчысы...*



## Шәриф Камал

1884–1942

> **Акчарлаклар иле пәйгамбәре.**
>
> **Ф. Бәшир,** әдәбият галиме

### Проза әсәрләре

«Уяну»
«Буранда»
«Бәхет эзләгәндә»
«Чит илдә»
«Сулган гөл»
«Акчарлаклар
«Таң атканда» һ. б.

### Драмалары

«Хаҗи әфәнде өйләнә»
«Ут»
«Таулар»
«Томан арты»
«Козгыннар оясында» һ. б.

### Татар әдәбиятының классик язучысы, драматург, тәрҗемәче

Шәриф Байгилдиев **1884 елның 27 февралендә** Пенза губернасы Инсар өязе Пешлә авылында (хәзерге Мордовия Республикасы) мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне үз авылларында ала, Ләбәжә мәдрәсәсендә укый. Шәкерт чагыннан ук үз көнен үзе күрә: кара эшләрдә эшли. Бәхет эзләп, Төркия, Мисыр якларына барып чыга. Каһирәдә «Җамигы-ләзәр» пансионында укый. Россиягә кайткач, күмер шахталарында, Каспий диңгезендә балык промыселында көч куя. Петербургта татар мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. «Нур» газетасында эшли: беренче шигырьләре, мәкаләләре языла, тәрҗемә белән шөгыльләнә.
**1906 елда** беренче шигырьләр җыентыгы «Сада» («Аваз») басылып чыга. **1907–1910 елларда** үз авылында балалар укыта. Шунда, «Уяну» хикәясен язып, танылу ала. Урта Азия якларына сәфәр кыла. Оренбургта «Шура», «Вакыт» редакцияләрендә хисапчы булып эшли. «Юл» һәм «Сабан» газеталарында редколлегия әгъзасы була, аннары җаваплы мөхәррир вазифасын үти.
Гомеренең калган өлеше Казан белән бәйле. Биредә «Таң атканда», «Матур туганда» романнары языла, драмалары басыла.
**1942 елда** Казанда вафат була.



Казанда Ш. Камалның музей-фатиры



### Моны белү кызыклы...

1. Шәриф Камалның чын исем-фамилиясе – Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев; рәсми документларда ул һәрвакыт тугандагы фамилиясе белән атала, балалары һәм оныклары да Байгилдиевләр булып кала.
2. Әтисе Камалетдин аны мулла итәргә тели. Улының муллалыктан баш тартуы әтисенең ачуын китерә. Шуның аркасында Шәриф җәйге каникул вакытларында, туган авылына кайтмыйча, берәр җирдә эшләргә мәҗбүр була.
3. Беренче татар газетасы – «Нур»ның тәүге саннарында Шәриф Камалның шигырьләре басыла. Соңыннан ул шигырьләр беркайчан да кабатлап бастырылмый, җыентыкларга да кертелми.
4. Татар язучыларыннан беренче булып Ленин орденына ия.
5. Язучы Казанның Островский урамында урнашкан 15 нче йортта яшәгән. Биредә аның музее эшли. Әлеге музей – республикада татар язучысына ачылган беренче музей (1944). Музейның беренче фәнни хезмәткәре – язучының кызы Зәйнәп Байгилдиева.
6. 2019 елда Ш. Камалның мемориаль фатирында Татар китабы йорты ачыла.
7. Ш. Камалның «Коммунарлар маршы» шигыренә композитор Салих Сәйдәшев көй яза.

# «Буранда» (1909)

**Әдәби төре:** проза
**Жанры:** хикәя
**Темасы:** тормыш юлында адашкан ялгыз кешенең бәхетсезлеге
**Проблемалары:**
1) анага мөнәсәбәт;
2) гаилә;
3) тәрбия, әхлак;
4) мәрхәмәтсезлек;
5) бәхетсезлек.

**Идеясе:** әниләрне рәнҗетергә ярамый, ул бәхетсезлеккә һәм гомерлек үкенечкә, сызлануга китерә, бу бәхетсезлектә беркем дә ярдәм итә алмый.

Әсәр **импрессионизм алымы** (әсәрнең эчке катламын музыка аша бирү, ягъни тойгыны төсләр, тавышлар ярдәмендә җиткерү) белән язылган.

## Әдәби образлар

**Төп герой** – Мостафа

- **Ярдәмче геройлар:** Мостафаның әнисе, сеңлесе Фатыйма
- **Катнашучы геройлар:** Хөсәен, Гайшә, шомланучы хатын, карт
- **Аталучы геройлар:** капкадан чыгучы, әтисе, керүче хатын, чыгучы хатын
- **Табигать образлары:** каргалар кычкыру, эт өрү – кайгы-хәсрәт; хуҗасының хәлен аңлаучы эт

## Сызлану фәлсәфәсе

- Мостафаның анасына карата ялгышлык эшләп сызлануы күрсәтелә.
- Бу сызлану елаулар, буран дулавы, ананың үлем газаплары, Мостафаның үкенүе аша җиткерелә.
- Мостафа хатасын да төзәтергә җитешми: бу исә аны чарасыз итә. Кеше язмыш алдында бик кечкенә. Тормышның мәгънәсезлеге рухи сызлануга китерә.

## Символлар

**Буран** – Мостафа күңелендәге газаплар
**Таң ату** – Мостафаның авыр хисләреннән арынуы, хатасын аңлавы
**Диңгез салкынлыгы** – теге дөньяга күчүнең авырлыгы
**Юл** – тормыш

## Метафора

Бала елау вакыйгасы. Шушы вакыйга нәтиҗәсендә Мостафа әнисен искә төшерә, шушы төн аны үзгәртә.

Табигать образы → Буран
Әдәби деталь → Буран
Символ → Буран
Көчле позиция → Буран
Сюжет нигезе → Буран

## Архетипик образлар:

**Ана архетибы** – Мостафаның әнисе (мәрхәмәтле, кичерүче, яратучы)
**Карт архетибы** – кучер бабай, әниләр турында яхшы сүзләр әйтә, буран булуга карамастан, ана хакына юлга чыга
**Бала архетибы** – ана яхшылыгын тулысынча аңлап бетермәүче, ана алдында мәңге бурычлы

## Әдәби алымнар:

**Кабатлау:** буран, җил, карга тавышы; әсәрнең башында да, ахырында да бала елавы кабатлана (ахырда Мостафа елый)
**Каршы кую алымы:** әнинең бала өчен җан атуы / баланың мәрхәмәтсезлеге; әсәрнең башында баланы әнисе юата / ахырда Мостафаны беркем дә юатмый – әнисе инде юк

# Гражданин, солдат, шагыйрь



## Фатих Кәрим

1909–1945

Фатих Кәримов Башкортстан Республикасы хәзерге Бишбүләк районы Ает авылында Әхмәтвәли мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган ягында ала. 13 яшьлек Фатихны абыйсы – шагыйрь Ярлы Кәрим Бәләбәй педагогика техникумының әзерлек курсларына урнаштыра. Ф. Кәрим 15 яшендә Казанга килә, җир төзү техникумына укырга керә, беренче шигырьләрен бастыра. 25 яшендә Язучылар берлегенә кабул ителә. **1937 елның 29 декабреннән 1941 елның 3 декабренә** кадәр, нахакка гаепләнеп, Архангельск, Печора лагерьларында яшьлек елларын үткәрә. Ун елга хөкем ителгән шагыйрьне дүрт елдан соң, гаепсез икәнлеген танып, тулысынча аклап иреккә чыгаралар. Аннан соң ул Бөек Ватан сугышына китә. **1945 елның 19 февралендә** һәлак була. Фронтовик шагыйрь Калининград өлкәсендә җирләнә.

### Без моны беләбезме...

- Ф. Кәрим – Сталин төрмәләрендә, ГУЛАГ лагерьларында җәфа чиккән, Төньяк диңгездә «Үлем баржасы»на махсус ут төртеп батырганда да, могҗиза белән исән калган кеше.
- Ф. Кәрим шигъриятендә гармун образы зур урын алып тора.
- А. Твардовский рус солдаты Василий Тёркин турында, ә Ф. Кәрим татар сугышчысы Фазыл турында яза. Сугыштан соң Ф. Кәримне «татар Твардовские» дип атый башлыйлар.
- **1941–1945 елларда** 9 поэма, 2 повесть («Разведчик язмалары» һәм «Язгы төндә»), 1 пьеса («Шакир Шигаев»), 100 дән артык шигырь һәм җырлар яза.
- Батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.
- Гади солдаттан взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелә.
- Шагыйрьнең сугышта кигән шинеле, итеге һәм куен дәфтәре Казандагы музейда саклана.
- Бәләбәй педагогика училищесы бинасына һәм Казандагы Ф. Кәрим урамына истәлек тактасы урнаштырылган.
- Ает авылында шагыйрьнең музее бар, мәктәп аның исемен йөртә.
- Багратионовск шәһәрендә Ф. Кәрим каберенә һәйкәл-обелиск куелган.
- Ф. Кәрим исемендәге премия булдырылган.
- 2025 елда Казанда Ф. Кәримгә һәйкәл куелды.

### 1920–1930 нчы еллар иҗаты

- «Кемгә сөйлим серләремне»
- «Җиденче мич»
- «Тавышлы таң»
- «Пулемётчы»
- «Аникин» һ. б.

### Тоткынлык чоры иҗаты (1938–1941)

- «Кыр казы»
- «Сагынып кайтам сине»
- «Сүз белән яратам димә»
- «Күбәләк» (кызы Адага)
- «...Син кызганма йөрәгеңне» һ. б.

### Сугыш чоры иҗаты (1941–1945)

- «Ант»
- «Ватаным өчен»
- «Бездә яздыр»
- «Сөйләр сүзләр бик күп алар...»
- «Кыңгыраулы яшел гармун»
- «Үлем уены»
- «Пионерка Гөлчәчәккә хат» һ. б.

И туган тел, и матур тел...

# «Ант» (1941)

**Әдәби төре:** ЛИРИКА

**Жанры:** ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫ

**Ант** – тугрылыкны саклауга бөтен халык, ил алдында бирелгән иң ышанычлы гарантия. Шигырьдә ант рәсми булмаган мәгънәдә бирелә, ягъни сәнгати образ буларак ачыла. Лирик геройның Ватанны сакларга иң югары дәрәҗәдәге вәгъдәсе, ышанычлы ант бирүе турында сөйләнә. Ул тынычлык сагына баскан миллионлаган солдат исеменнән әйтелгән уртак ант булып яңгырый.

**Мотивы:** туган илне саклау хакында ант бирү

Мәгънәне көчәйтү өчен кулланылган **стилистик фигуралар:**

- **Кабатлау –** *«Шушы балам өчен, синең өчен, Нәселем өчен, туган ил өчен»*
- **Инверсия:** *«Ватан сугышына мин китәм»*
- **Градация:** *«Синең өчен → балам өчен → нәсел өчен → туган ил өчен»*

**Троплар:**

- **Эпитет:** «...алсу ирендә»
- **Гипербола:** *«Мылтык тотып баскан җиремнән Бер адым да артка чигенмәм»*

**Лирик герой** – туган илен дошманнардан яклау өчен сугышка китүче солдат.

- Ватан алдында җитди сынау торганлыгын аңлый;
- җаваплылык хисен тоя;
- җиңүгә ышана;
- туган җирнең бер карышын да дошманга бирмәячәген ассызыклый;
- иң газиз кешеләре белән ант итә.

**Антның эчтәлеген көчәйтү өчен шагыйрь сөйгәненә мөрәҗәгать итә, риторик эндәш алымыннан файдалана, баласы белән ант итә**

### Лирик геройның хисе

- дошманга нәфрәт
- сагыш
- әрну

### Хиснең сәбәбе

- туган илгә дошман басып керү
- гаиләдән, баладан аерылу

### Хиснең дәрәҗәсе

- «Мылтык тотып баскан җиремнән Бер адым да артка чигенмәм»

### Юану

ант итә, бирешмәскә сүз бирә

### Идея

совет солдаты антына тугры калырга, батыр булырга тиеш; туган илне дошман кулына бирергә ярамый

ӘДӘБИ НУРЛАР

# Солдат һәм шәхес



## Гадел Кутуй
1903–1945

Шагыйрь, прозаик, драматург, хәрби корреспондент

**Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде...**

**Г. Кутуй**

### Прозаик
«Сагыну»
«Тапшырылмаган хатлар»
«Рөстәм маҗаралары»
«Солтанның бер көне»
«Рәссам» һ. б.

### Шагыйрь
«Туган ил»
«Озату»
«Иртәнге уйлар» һ. б.

### Драматург
«Шатлык җыры»
«Балдызкай» һ. б.

Гаделша Кутуев **1903 елның 28 ноябрендә** Сарытау губернасының Кузнецк өязе Татар Кынадысы (хәзерге Пенза өлкәсе) авылында туа. Башлангыч белемне туган авылындагы мәктәптә ала. Гаиләләре күченеп киткәч, башта Самара губернасы Алексеевка авылы мәктәбендә укый, аннан – Самара шәһәре мәктәбендә. Рус язучысы Александр Неверов оештырган әдәби түгәрәккә йөри, рус телендә беренче өйрәнчек шигырьләрен яза. **1920 елда** Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетында укый. Казан Татар-башкорт хәрби мәктәбендә әдәбият укытучысы булып эшли. Бу чорда аның иҗат эшчәнлеге активлаша. Казан Шәрыкъ педагогика институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында фәнни сәркатип, мәктәпләрдә һәм Казан авиация техникумында әдәбият укытучысы булып эшли. **1942 елның июнендә** Г. Кутуй фронтка китә, иҗат эшен ташламый, фронт газеталары өчен мәкаләләр, хәбәрләр яза, төрле әдәби монтажлар төзи, әсәрләр иҗат итә. **1944 елда** исә ул Казанга иҗади ялга кайта һәм «Рөстәм маҗаралары» дигән фантастик повестен яза. Сугыш бетәр алдыннан, **1945 елның** язында Гадел Кутуйның сәламәтлеге начарлана, ул хәрби госпитальгә ята. **1945 елның 15 июнендә** Польшаның Згеж шәһәрендә вафат була һәм шул шәһәр зиратында җирләнә.

### Без моны беләбезме...

- Гадел Кутуй, Хәсән Туфан, Һади Такташ якын дуслар була.
- Казанга ялга кайткан арада «Рөстәм маҗаралары» исемле фантастик повесть иҗат итә. Ул улына багышланган.
- «Рөстәм маҗаралары» повесте – татар балалар әдәбиятындагы беренче фантастик әсәр.
- Г. Кутуйның улы Рөстәм Кутуй – язучы һәм тәрҗемәче.
- Г. Кутуйның яшь чагында иң яраткан шагыйре Владимир Маяковский була, хәтта аңа охшатып, футуристик стильдә шигырьләр дә иҗат итә.
- «Тапшырылмаган хатлар» повесте күп телләргә тәрҗемә ителә, аерым китап булып чыгарылган кырыктан артык басмасы бар. Ул рус, кытай, инглиз, гарәп, француз, чех, вьетнам, монгол, тува, албан, корея һәм үзбәк телләрендә дә басыла.
- «Тапшырылмаган хатлар» повесте – Җир шарында иң күп таралган дүрт татар китабының берсе.
- Г. Кутуйның тормыш иптәше Галимә Кутуева истәлекләренә караганда, әсәр гаилә истәлекләренә таянып язылган.
- 2017 елда, «Тапшырылмаган хатлар» повестена нигезләнеп, заманча нәфис фильм төшерелде. 2024 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында спектакле куелды. Бу әсәр буенча опера язылган (Җ. Фәйзи музыкасы).
- Г. Кутуйның туган авылы хәзерге вакытта Пенза өлкәсенә керә. Туган авылында туган йортының нигезе сакланмаган, әмма йорт каршындагы коелары әле дә тора.
- Казанда Г. Кутуй исемен йөрткән урам бар, ул яшәгән йортка мемориаль такта куелган.

И туган тел, и матур тел...

# «Тапшырылмаган хатлар» (1935)

**Әдәби төре:** проза

**Жанры:** повесть

**Жанр формасы:** эпистоляр повесть

**Темасы:** мәхәббәт, гаиләдә җаваплылык, ир белән хатын мөнәсәбәтләре

**Идеясе:** мәхәббәтне намус, сафлык, җаваплылык белән бәйләп караган кеше генә бәхетле була

Вакыйга-күренешләрнең бирелеше

- Галиянең үткәненә бәйле хис-кичерешләрен яңартуы
- Төп мәсьәләгә катнашы булмаган мәгълүматлар, хәбәрләр: А. П. Мойкина, Ольга Делевская, Д. Любарская хатлары, Мәрфуганың җыелыш үткәрүе һ. б.

## Хатларның эчтәлеге

**Беренче хат** – **Мәхәббәт тарихы**

Яшьләрнең танышулары, мәхәббәтләре; Галиянең үткәне белән бүгенгесе контраст буларак бирелә; әледән-әле киләчәк тормыш мактала; язучы мәхәббәт, гаилә, ир белән хатын мөнәсәбәтләре турында өстәмә вакыйгалар, лирик чигенешләр бирә.

**Икенче хат** – **Гаилә тарихы**

Искәндәр белән Галиянең өйләнешүе, гаиләдәге беренче каршылыклар; бәхетле, ныклы гаилә турында автор уйланулары; Искәндәр Галияне ташлап китә, ә Галия ике баласы белән Әдрәс авылына күчә.

**Өченче хат** – **Хезмәт юлы тарихы**

Галиянең Әдрәстәге тормышы тасвирлана; ул табиб буларак танылa; шәхси сыйфатлары тулырак ачыла; Галия – Вәли сызыгы килеп керә.

**Дүртенче хат** – **Бәхетле булырга теләү тарихы**

Галия Вәли белән очраша, хатларны Вәлигә бирә.

## ПРОБЛЕМАЛАР:

1) җавапсызлык;
2) гаилә тәрбиясе, әхлак;
3) ир белән хатынның гаиләдәге урыны;
4) эгоистлык;
5) хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны.

## СЮЖЕТ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ:

**Экспозиция** – Галия белән Искәндәрнең танышып, яратышып йөрүләренә бәйле вакыйгалар

**Төенләнеш** – ир белән хатынның гаиләдәге урынына бәйле туган каршылык

**Хәрәкәт үстерелеше** – Галия белән Искәндәрнең биш ел бергә яшәү вакытында булган вакыйгалар, Галиянең авылдагы тормышы

**Кульминация** – Галиянең Вәли белән очрашуы (Галиянең Искәндәргә булган җылы хисләрен Вәли тулысынча сүндерә)


**Чишелеш** – Искәндәр, гаебен аңлап, Галиягә сагынып хат яза, Галия күңелендә Искәндәр тулысынча юкка чыга, ул Вәли белән гаилә кора

**Сюжеттан тыш элемент** – эпилог өлешендә авторның әсәр язарга җирлекне кайдан алуы бәян ителә

## ПОВЕСТЬНЫҢ СӘНГАТЬЧӘ ЭШЛӘНЕШЕ:

- повесть хатлар рәвешендә язылган, ә хатта кешенең иң яшерен, серле һәм эчкерсез хисләре чагыла. Хатлар, аерылышып сигез ел үткәннән соң, Искәндәргә җавап итеп язылганнар;
- Галия образы – авторның табышы;
- әсәр идея-тематик яктан аңлаешлы, ачык, композициясе җыйнак;
- вакыйгалар мәхәббәт тарихына бәйле рәвештә үстерелә.

# Авыл пәйгамбәре



## Мөхәммәт Мәһдиев

1930–1995

*М. Мәһдиев мирасы – иҗатчы белән аның каләменнән төшкән каһарманнар арасындагы якынлыкның югары үрнәге. Кояшлы иҗат.*

***Т. Галиуллин,*** *әдәбият галиме, тәнкыйтьче*

### *Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, галим, әдәби тәнкыйтьче*

Мөхәммәт Мәһдиев **1930 елның 1 декабрендә** Татарстанның Арча районы Гөберчәк авылында дөньяга килә. **1944 елда** Сикертән авылындагы җидееллык мәктәпне һәм **1947 елда** Арча педагогика училищесын тәмамлый. Шул ук районның Сеҗе урта мәктәбендә бер ел – өлкән пионервожатый, Саба районының Керәнле җидееллык мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли. **1950–1954 елларда** Балтыйк хәрби флотында хезмәт итә. Флоттан кайткач, читтән торып укып, Казан дәүләт педагогика институтының тарих бүлеген тәмамлый. Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурада белем ала.

Язучы-прозаик буларак, М. Мәһдиевнең исеме матбугатта **1960 нчы еллар** ахырыннан күренә башлый. **1967 елны** «Казан утлары»ында «Этюдлар» дигән гомуми башисем белән аның беренче кыска әсәрләре – әдәби парчалары басылып чыга, ә тагын бер елдан шул ук журнал битләрендә «Без – кырык беренче ел балалары» исемле тәүге повесте дөнья күрә.

Авыл тормышы, сугыш алды, сугыш вакыты һәм сугыштан соңгы чордагы күмәк хуҗалык чынбарлыгы, аның кешеләре үзәккә куелган, шул заманга хас күп төрле иҗтимагый, әхлакый-фәлсәфи проблемалар анализланган, актуаль яңгырашлы, халыкчан рухлы «Фронтовиклар» (1972), «Каз канатлары» (1975) романнары, «Кеше китә – җыры кала» (1978), «Торналар төшкән җирдә» (1978), «Ут чәчәге» (1980), «Исәнме, Кәшфи абый!» (1982) кебек повестьлары белән М. Мәһдиев татар әдәбиятының алгы сафына баса.

Мөхәммәт Мәһдиев **1995 елда** вафат була. Туган авылы Гөберчәк зиратына җирләнә.

### Әсәрләре

- **«Без – кырык беренче ел балалары»**
- **«Фронтовиклар»**
- **«Бәхилләшү»**
- **«Кеше китә – җыры кала»**
- **«Торналар төшкән җирдә»**
- **«Исәнме, Кәшфи абый!»** һ. б.

*Мөхәммәт прозасын укып туеп булмый. Авыл кешесенең холкын, җанын, акылын, мутлыгын, хәйләкәрлеген Мөхәммәттәй тасвирлый алган язучылар бик сирәк.*

***Т. Миңнуллин,*** *драматург*

### Моны белү кызыклы...

- М. Мәһдиев белгечлеге буенча – тарихчы, университетта студентларга әдәбият укыта.
- Мәзәкләр сөйләргә ярата, тәртмә телле була.
- Әдәбиятка соң килә: «Без – кырык беренче ел балалары» әсәре 38 яшендә языла.
- Гомер буе авыл тормышын, яшәешен үз итә.
- Көндәлек алып бара.
- Язучының әтисе мулла, соңрак укытучы була. Әтисе нахакка гаепләнеп, халык дошманы дигән яла ягылганга, М. Мәһдиевкә шактый авырлык күрергә туры килә.
- Язучының туган көне, елы төгәл билгеле түгел, төрле даталар белән йөртелә.





М. Мәһдиевнең Арча районы Гөберчәк авылындагы музей-йорты

# «Без – кырык беренче ел балалары» (1968)

**Жанры:** повесть

**Темасы:** Бөек Ватан сугышы елларындагы тылдагы яшүсмерләр тормышы

## Повестьның үзенчәлекләре:

- геройларның, чорның уртак максатын, урын-вакыт берлеген күздә тотып, тартмалы композициягә корылган;
- төгәл сюжет сызыгы юк;
- күренешләр чәчелгән;
- эпилог өлеше бар: геройларның киләчәктә кем булуын хәбәр итә;
- ретроспекция, каршы кую, кабатлау, янәшәлек кебек әдәби алымнар кулланылган;
- тел-сурәтләү чараларына, җырларга бик бай һ. б.

*Әлеге әсәрне 2012 елда К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективы сәхнәләштерә, ә 2021 елда язучының туган ягында фильм төшерелә.*



## Образлар системасы

**Хикәяләүче** ← Вакыйгаларны күзәтүче, бәяләүче, катнашучы герой, автор образы

**Әсәр башында:** Арча педучилищесында белем алырга килгән авыл малае

**Әсәр ахырында:** Яшьлеген сагынучы герой

**Әсәр геройлары**

*Баязитова*
*Нина Комиссарова*
*Хәлил Фәтхиевич*
*Сабир абзый*
*Иван Георгиевич*
*Исмәгыйль агай*

**Гыйззәтуллин**, **Зарифуллин** → рус теле укытучылары булып эшлиләр

**Әркәшә Пермяков** → мәктәп директоры

**Әлтафи Хәлимов** → райпотребсоюз председателе

## Әсәр композициясе

**Эпиграф**

Халык җырыннан өзек китерелә: *«Атадан бала яшь кала, Бик күп эшләр башкара»*

*Әсәрнең төп геройлары сугыш еллары балалары булуын ассызыклый. Җыр сүзләренең мәгънәсе, эчтәлеге көчле позициягә чыгарылган.*

**Төп өлеш**

*Һәр бүлекнең үз исеме бар. Вакыйгалар 1 октябрь көнне, колхоз басуыннан аерылып, педучилищега укырга килгән малайларның көндәлек тормышын сурәтләү белән башлана. Геройларның тормышы «чәчеп бирелә».*

**Эпилог**

*Хикәяләүче геройның өлкән кеше, узганны (яшьлекне) сагынучы кеше булып җитүе сурәтләнә. 20 ел узганнан соң геройларның кем булуы тасвирлана.*

***Метафора:*** *«каеннарның корыган төпләре» – өлкән буын; «яшь наратлар» – үсеп килүче яшь буын.*

# Татар драматургиясенең Әлмәндәре

**Татарстанның халык язучысы, күренекле драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе**

«Үзебез сайлаган язмыш» пьесасы өчен **ТАССР комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе** (1974), «Ай булмаса, йолдыз бар» исемле мелодрамасы өчен **Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе** (1979),«Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре өчен **РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе** (1979) тапшырыла.



## Туфан Миңнуллин

1935–2012

**1935 елның 25 августында** Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң районда һәм Казахстанның Кустанай өлкәсендә эшли. **1956-1961 елларда** Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге театр училищесында укый. Берникадәр вакыт Минзәлә драма театрында, аннары Казанда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актёр хезмәтендә була. **1975–1977 елларда** Т. Миңнуллин Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый.

**1960 нчы елларда** аның драмалары Татарстан театрларында куела башлый. Узган гасырның **70 нче елларында** ул инде күренекле драматург булып таныла.

Т. Миңнуллин – җәмәгать эшлеклесе. Татарстан Язучылар берлеген җитәкли. Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге рәисе вазифаларын башкара. Татарстан Дәүләт Советы депутаты була.

Драматург **2012 елның 2 маенда** вафат була.

### Драматург

- **«Моңлы бер җыр»** • **«Илгизәр + Вера»**
- **«Без китәбез, сез каласыз»** • **«Монда тудык, монда үстек»** • **«Әлдермештән Әлмәндәр»**
- **«Әниләр һәм бәбиләр»** • **«Шәҗәрә»** • **«Ай булмаса, йолдыз бар»** • **«Кырларым-тугайларым»** •
- **«Диләфрүзгә дүрт кияү»** • **«Дуслар җыелган җирдә»**
- **«Хушыгыз»** • **«Төш»** һ. б.

### Татар балалар драматургиясе үсешенә зур өлеш кертә

- **«Гафият турында әкият»** • **«Авыл эте Акбай»**
- **«Акбай һәм Сарык малае»** • **«Акбай һәм Кыш бабай»**
- **«Акбай нигә күңелсез?»** һ. б.

### Истәлекләр һәм публицистик язмалары

- **«Утырып уйлар уйладым»**
- **«Татарның бер баласы»** һ. б.

### Сез моны беләсезме...

- Драматург «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрен Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укыган вакытта 12 көн эчендә яза.
- Мәктәпне тәмамлагач, бухгалтерлык курсларында укый.
- Әтисе Габдулла абзый Хәсән Туфан хөрмәтенә улына Туфан исеме куйдырта.
- Хатыны – актриса Нәҗибә Ихсанова.
- Үтә дә тапкыр, җор телле кеше була.
- Иң якын иҗатташ дусты – режиссёр Марсель Сәлимҗанов.
- Үз вакытында аның беренче әсәрләрен яратып, түземлелек белән тыңлаучы кеше дә, беренче тәнкыйтьче дә Фирдәвес Әхтәмова була.

### Иҗади үзенчәлекләре:

- пьесаларының жанр төрлелеге (сатирик комедия, җитди комедия, лирик комедия, шаян комедия, моңсу комедия, социаль драма, интеллектуаль драма, әкият-пьеса);
- тематик төрлелеге (тарихи шәхесләр, авыл темасы, мәгариф, буыннар бәйләнеше, зыялылар тормышы);
- сәхнә закончалыкларын яхшы аңлап язу;
- чын милли характерлар тудыру;
- әсәр нигезенә тирән әхлакый-фәлсәфи фикерләр салу;
- композицион яктан әсәрләренең төгәл эшләнүе (теле җанлы, кискен конфликт, тормыш материалы җитди, тирән мәгънәле).

Татар драматургиясен һәм театрын үстерүгә куйган зур хезмәтләре өчен, аның исемен мәңгеләштерү максатында, Түбән Кама шәһәренең татар драма театрына, Казан урамнарының берсенә Туфан Миңнуллин исеме бирелә. Драматургның туган ягы Кама Тамагында һәм Казан шәһәренең 12 нче кызлар гимназиясендә әдипнең музее ачыла.



Әдипнең туган ягындагы музей-йорты

# «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976)

> *Күп йөргән, күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган, ләкин күңел көрлеген югалтмаган авылым картларына багышлыйм.*
> *Т. Миңнуллин*

**Жанры:** драма (автор үзе моңсу комедия дип билгели)

**Темасы:** буыннар бәйләнеше, әдәп-әхлак кануннарына тугрылык, яшәү матурлыгы

## Әсәрнең төп тышкы каршылыгы

**Әлмәндәр карт (Яшәү)** ⟷ **Әҗәл (Үлем)**

**Әсәр башында:**
- Әлмәндәр карт: Дөньяда яшисе килә. Әсәр ахырына кадәр шуның өчен көрәшә.
- Әҗәл: Бу дөньядан картны алып китәсе килә.

**Ике теләк каршылыгы**

**Әсәр ахырында:**
- Әҗәлдән кәгазьне үзе сорап ала, үз теләге белән үлем кәгазенә кул куя.
- Әҗәл Әлмәндәрнең тормышка булган мәхәббәтенә каршы тора алмый – җиңелә. Картны алып китәсе килми башлый. Шулай да үлем котылгысыз.

Әлмәндәр кебек кешеләр үлемне дә җиңәләр, алар үлемсез. Халык күңелендә яшиләр.

## Сюжет-композиция үзенчәлекләре

**Пролог** – Газраилнең, үзе янына Әҗәлне чакыртып, аны Әлдермешкә командировкага җибәрәчәге турында хәбәр итүе
**Экспозиция** – Әлдермеш авылында 91 яшьлек Әлмәндәр карт белән танышу
**Төенләнеш** – Әлмәндәр карт янына Әҗәлнең килүе
**Вакыйгалар үстерелеше** – Әлмәндәр картның башлаган эшләрен төгәлләргә ашыгуы, Антоновка авылына дусты Евстигней белән хушлашырга баруы; бер төн эчендә иң якыннары белән хушлашып чыгуы
**Кульминацион нокта** – Әлмәндәр картның Әҗәл янына барып, повесткага кул куюы
**Чишелеш** – Әлмәндәрнең үлеме
**Эпилог** – Әлмәндәрнең теге дөньяда да шаян булып калуы

## Образлар системасы

**Әлмәндәр** → Өммия, Искәндәр, Гөлфирә, Мансур, Әҗәл, Йөзембикә, Хәмдебану, Евстигней, Илсур

## Эчке каршылык – Әҗәл күңелендә

**Әлмәндәр картның яшәү фәлсәфәсе**

- **Үткәннәргә мөнәсәбәте** → Үткәннәр кеше күңелендә якты хатирә һәм сагыш булып яши, кеше үз артыннан якты исем, якты эзләр калдырып китәрлек итеп яшәргә тиеш дип саный.
- **Яшәү мәгънәсе** → Әлмәндәрнең яшәү максаты – тирә-юньдәге кешеләр: күршеләр, туганнар, дуслар белән һәрдаим бәйләнештә яшәү. Кешенең тормыш мәгънәсен башкалар күңелендә матурлык уятып, үз яшәеше белән матурлык тудырып гомер итүдә, рух байлыгында, күңел көрлегендә таба. Хәйләкәр, зирәк, акыллы, җор телле булуы белән авырлыкларны җиңә алган Әлмәндәр татар укучысы күңелендә тормышның асылын аңлаган герой булып яши.
- **Киләчәккә мөнәсәбәте** → Һәр буын үз артыннан тормыш мәгънәсен рухи байлыкта күргән, халыкның рухи кыйммәтләрен саклап һәм санлап яши торган дәвамчылар калдырырга тиеш дип саный. Йорт салып калдыруы шуңа ишарәли.

# Куркырлы талант иясе



## Каюм Насыйри

1825–1902

### Танылган татар мәгърифәтчесе, тел галиме, тарихчы-этнограф, тәрҗемәче, язучы, фольклорчы

Габделкаюм Насыйров **1825 елның 2 февралендә** Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. **1841 елда** Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга керә. Бу мәдрәсәдә ул унбиш ел – **1855 елга** кадәр укый. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Аннан соң Руханилар училищесында, соңрак шул училищеның дәвамы булган Руханилар семинариясендә татар теле укыта. Семинариядә ул 15 ел эшли. Соңыннан Казан университетына ирекле тыңлаучы булып керә. **1879 елдан** башлап К. Насыйри рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итми. Бар гомерен язучылык эшенә, фәнгә багышлый. **1885 елда** Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана. К. Насыйри **1902 елның 20 августында** 77 яшендә вафат була, Казанның Яңа бистә зиратына җирләнә.

**Әдәби әсәрләре:**

«Әбүгалисина»
«Кырык бакча»
«Буш вакыт»
«Кырык вәзир кыйссасы» һ. б.



К. Насыйриның Казандагы әдәби музее



Туган ягында К. Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексы

*Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул.*
*К. Насыйри*

### Моны белү кызыклы...

- Ул – татарның Ломоносовы.
- Китап төпләү, күзге ясау, крахмал, лак, электр ярдәмендә әйберләр көмешләү эшләрен белә. Моннан тыш слесарь һөнәренә дә өйрәнә.
- Халык медицинасын үз итә, төрле үләннәр үстерә һәм алар белән дәвалый.
- Фольклор материалларын яратып җыя.
- Математика, география дәреслекләре яза.
- Тарих, тел, әдәбият, кулинария, педагогика һәм методика буенча хезмәтләре бар.
- Үзенең 40 еллык иҗади эшчәнлеге чорында 37 әсәр яза, 24 календарь төзи.
- 1871 елда ул өстәл календарен эшли.
- Хыялы «Таң йолдызы» дигән газета чыгару була.
- Рус теле укытканга, Урыс Каюм дип йөрткәннәр.
- Туган ягы Шырданда үзе казыган кое саклана. Халык аны Каюм коесы дип йөртә. Кое янында 300 еллык тирәк агачы үсүе дә уникаль.
- Габдулла Тукай да аның хезмәтләренә таяна: Шүрәле, Су анасы кебек әкият геройларын Каюм Насыйри үз эшләрендә инде күрсәткән була.
- Татар телен укытуда аның үзенчәлекле методикасы була. Телне ул халык авыз иҗаты, татар әкиятләреннән мисаллар китереп өйрәтә.
- Гомер көзендә күренекле галимне паралич суга. Чорына күрә шактый тәвәккәл адым ясый: үз-үзен электр белән дәвалый.
- Кайбер балаларны үз акчасына укыта. Татар балаларының белемле, зирәк булуын, заманча фикерли белүен кайгырта.
- 2014 елдан Казан федераль университетында «Каюм Насыйри институты» Белем бирү-мәдәни үзәге ачыла, аның төрле шәһәрләрдә һәм илләрдә 14 үзәге эшли.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә 1995 елдан педагогик коллективларга, белем бирү учреждениеләренә конкурс нигезендә Каюм Насыйри исемендәге премия бирелә.

# «Әбүгалисина» (1872)

**Жанры:** повесть
**Идеясе:** белем кешелек дөньясында яхшылык эшләү һәм ярдәм итү максатыннан файдаланылырга тиеш

Әбүгалисина турында халык арасында бик күп риваятьләр яши. Шуларны туплап, Төркия дәрвише Хәсән Мәдхи китап бастыра. Язучы Зыятдин Сәед Яхъя «Кәнҗини хикмәт» әсәрен иҗат итә. Ул 1864–1865 елларда Казанда да нәшер ителә. К. Насыйри аны әдәби яктан эшкәртә, тәрҗемә итә. Нәтиҗәдә 1872 елда «Әбүгалисина кыйссасы» дөнья күрә.

## Проблемалар:

● гаделлек ● туганлык мөнәсәбәтләре
● әхлаксызлык ● эгоистлык һ. б.

*Әбүгалисинаның прототибы – XI йөз башында (980–1037) Урта Азиядә яшәгән фәлсәфәче, шагыйрь, юрист һәм табиб, Ибне Сина исеме белән билгеле мәшһүр галим. Тулы исеме – Әбу Гали әл-Хөсәен ибн Габдулла ибн Сина.*

## Сюжет элементлары:

**Экспозиция:** Әбүгалисина һәм Әбелхарис белән танышу; мәгарәдә белем эстәү

**Төенләнеш:** Әбүгалисина белән Әбелхарисның юллары аерылу

**Вакыйгалар үстерелеше:**
1) Әбүгалисина – Хәлвәфрүш вакыйгалары;
2) Хәлвәфрүшнең патша кызы белән бәйле вакыйгалары;
3) Әбелхарис – патша вакыйгалары һ. б.

**Кульминацион нокта:** Әбүгалисинаның патша сараена агулы гөл тотып керүе

**Чишелеш:** Әбелхариснең үлеме, Әбүгалисинаның үкенүе; патша кызының Хәлвәфрүш белән гаилә коруы

Зирәк, акыллы, тырыш булуы белән аерылып торган.

## Гипербола алымы:

*«12 яшенә җиткәндә, бик күпне белүче галим булып өлгерә»; «Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз көрәштерерлек кеше калмый» һ. б.*

## Әбүгалисина — Әбелхарис

### Охшаш яклары:

Бертуганнар бергә үсәләр, бер үк тәрбия алалар, бер мәдрәсәдә укыйлар, Фисагурис (Пифагор) исемле галимнең хезмәтләре тупланган мәгарәгә керер өчен, икесе дә **тырышлык** күрсәтәләр, анда белем эстиләр. Үлемнән котылу өчен икесе дә **белемнәренә, зирәклекләренә** таяна.

### Аермалы яклары:

Эчке дөньялары, рухи сыйфатлары төрле. Алган белемнәреннән, зирәклек һәм тырышлыкларыннан төрле максатта файдаланалар.

**Әбүгалисина:** Үз көче белән көн күрүче, ярдәмгә мохтаҗ Хәлвәфрүшкә булыша → **гаделлек**

**Әбелхарис:** Патшага ярдәм итә, байлыкка кызыга → **явызлык**

**гаделлек** ↔ **явызлык**

# Таң җырчысы



## Сәгыйть Рәмиев

1880–1926

> *Шагыйрь үзендә бер-берсе белән алышынып тора торган «караңгы-яктылы» ике халәт, ике төрле настроение күрсәтә. Берсе аның «мин»ен күрми яки аның сүзен ишетә алмый торган чагы – «үлгән» вакыты, икенчесе – «мин»ен күреп шатланган, күтәрелгән моменты.*
>
> ***Г. Сәгъди**, әдәбият галиме*

> **Сүз көчле ул,**
> **Мәгънәле ул...**
> **С. Рәмиев**

### Шагыйрь

«Таң вакыты», «Син», «Мин», «Ул», «Дөньяга», «Алданган», «Авыл» һ. б.

### Язучы

«Нәҗметдин агай бәйрәме», «Галәветдин хаҗи корбаны – Җаек Хәдичә», «Ул исерек түгел иде» һ. б.

### Драматург

«Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», «Низамлы мәдрәсә» һ. б.

**XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле шагыйре, прозаик һәм драматург, публицист һәм тәнкыйтьче, журналист, җәмәгать эшлеклесе**

**1880 елның 24 февралендә** Оренбург өлкәсе Акман авылында туа. Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Өч сыйныфлы рус мәктәбен тәмамлый. Үзе укыган «Хөсәения»дә мөгаллим була. **1906 ел** башында Казанга килә һәм «Таң йолдызы» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Газета ябылгач, «Таң мәҗмугасы» исемле журнал чыгару эшенә керешә. Реакция елларында «Бәянел-хак» газетасы редакциясендә эшли. **1910 елда** Әстерханга китеп, «Идел» газетасында сәркатип, соңрак мөхәррир була. **1914 елда** хатынының туган ягы Уфага күченеп кайталар. Монда рус телендә чыга торган «Авыл көнкүреше журналы»на эшкә урнаша – аның татарча тәрҗемәсен чыгара.
Гражданнар сугышы елларында Урал өязенең Ваһапов посёлогында ревком сәркатибе итеп билгеләнә. Магнитка станциясендә мәгариф эшләренә җитәкчелек итә. Верхнеуральск шәһәрендә партия комитетының мөселманнар секциясендә хезмәт итә, Чиләбедә «Кызыл Урал» газетасында да эшли, педагогика техникумында татар әдәбияты да укыта. **1922 ел** ахырында Уфага кайта, Җир эшләре халык комиссариатында нәшрият эшләре җитәкчесе була. Ләкин сәламәтлеге начарая башлый. Ул **1926 елның 17 мартында** үпкә авыруыннан вафат була.

### Моны белү кызыклы...

- С. Рәмиев биш тел белә: татарча, русча, гарәпчә, фарсыча, төрекчә.
- 1911 ел башында Г. Тукайның үпкә авыруы көчәеп китә. Кымыз белән дәвалау һәм дусты – доктор Нәримановка күрсәтү өчен, С. Рәмиев аны Әстерханга китерә.
- Замандашлары аның бик зәвыклы кеше булуы турында сөйли.
- Энциклопедик белемгә ия шагыйрь була, рус, Көнчыгыш, Көнбатыш әдәбиятларын бик яхшы белә.
- Шагыйрь буйлы-буйлы, төсле чапан киеп, нәкъ Шәрык мәдәниятенә хас булганча, кулларын күкрәгенә куеп, сәлам биреп йөрергә ярата.

### Әдәбият тарихында тоткан урыны:

- С. Рәмиев XX йөз башында татар шигъриятен яңа баскычка күтәрә, Яңарыш чоры милли әдәбиятын нигезләүдә катнаша.
- Гыйсъянчылык романтизмы вәкиле.
- Иҗатында экспрессионизм, экзистенциализм агымнарына мөрәҗәгать итә.
- Яңа заман герое тудыра.
- Яшәеш кануннарына каршы чыккан, үзе риза булмаган дөньяны үзгәртүне, шәхес азатлыгын максат итеп куйган бунтарь, гыйсьянчы геройны алып килә.
- Татар театрын булдыру өчен күп көч куя.
- Татар матбугаты тарихында тирән эз калдыра.

# «Таң вакыты» (1908)

**Жанры:** гражданлык лирикасы; «мөсәҗҗәгъ нәсер» – рифмалы нәсер яки «рифмалы, ритмлы лирик проза»

Бу әсәрен шагыйрь беренче тапкыр 1908 елның 2 гыйнварында Казандагы Шәрык клубында укый. Шигырьгә тирән иҗтимагый, милли, фәлсәфи мәгънә салынган. Ул көчле бәхәсләр тудыра, тиз арада русчага тәрҗемә ителә. Аны милләте буенча поляк, Казанда сөргенлектә яшәүче студент Альберт Панкевич тәрҗемә итә. Шәкертләр бу шигырьне җыр дәфтәрләренә күчереп ятлап йөриләр.

Шигырьдә ритм, яңгыраш тудыруның төп чарасы – **ялгау.**

## Идеясе:

Тормышны аң-белем, мәгърифәт, тырышлык юлы белән генә яхшыга үзгәртергә мөмкин.

*«Туг яңадан мәгърифәтле анадан!*
*Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә,*
*Хата ул өмид Алладан!»*

*«Таң вакыты» шигыре – Сагыйть Рәмиев иҗатының таҗы.*

## Таң вакыты – символ

**ЧЫНБАРЛЫКТА:**

Табигатьнең, тормышның уяну, хәрәкәткә килү вакыты. Таңнан торып эшкә керешү – татарда тырышлык, яшәеш билгесе.

**ШИГЫРЬДӘ:**

- 1905 елгы уяну, үзгәрү вакыты;
- татар халкының торгынлыктан чыга башлау вакыты;
- милләтнең киләчәге турында уйлана башлау вакыты;
- татар җәмгыятенең яшәешенә бәя бирә.

Әсәрдә мәгърифәтчелек карашлары үзәккә куела, аң-белем, мәгърифәт ярдәмендә татар җәмгыятен үстерү күздә тотыла.

**Шигырьдә лирик геройның ике төрле халәте, каршылыклы хисләре чагыла.**

Ерак тарихлардан килгән курку, сабыр итү, тыелып тору тойгысы бар.

*«Мөселман булсаң, уйлама юкны!»*

Туып килгән «таң» аның күңелен шашындыра, күккә ашыра, азатлыкка өнди.

*«Юк, юк! Мин шашам! Яталмыйм урнымда, күккә ашам!»*

**Лирик герой** борчыла, күзенә йокы керми. Халыкның ваемсызлыгын күреп яна, көя, татарны уяныргa, мөстәкыйльлеккә чакыра. Шушы сыйфатлары белән ул башка татарлардан аерылып тора.

*«...атадан калган хатам»*

*«...хатам тирән, тамыры ерак»*

**Сәбәбе:** хәлиткеч вакытта бердәмлек булмау, курку

# Талант иясе



## Гали Рәхим

1892–1943

**XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле вәкиле, татар әдәбиятында яңа юл салган прозаик, галим, фикер иясе, тәнкыйтьче**

*Гали Рәхим – татар халкының иң затлы укымышлысы, милләтебезнең йөзек кашы.*
***М. Мәһдиев**, язучы*

Мөхәммәтгали Габдерәхимов **1892 елның 4 ноябрендә** Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Башта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, аннары Казандагы коммерция училищесында белем ала. Шуннан соң Мәскәү сәүдә институтын тәмамлый.
**1919–1930 елларда** фәнни-педагогик хезмәт белән шөгыльләнә. Педагогика буенча оештырылган төрле курсларда, Көнчыгыш академиясендә һәм педагогика институтында укыта. **1936–1938 елларда** Дәүләт банкында эшли.
Г. Рәхимнең **1909 елда** «Җир йөзе» дип язылган фәнни-популяр жанрдагы беренче китабы дөнья күрә. **1913 елдан** башлап «Ак юл» журналында аның байтак әкият-хикәяләре басыла.
Ул фәнни эш белән дә шөгыльләнә: татар әдәбияты тарихы буенча хезмәтләр яза. Казан университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә әгъза булып тора, **1926–1930 елларда** Академүзәк каршындагы Татарстан һәм татар белеме җәмгыятенең гыйльми сәркатибе булып эшли.
**1927 елда** галим Сталин исеменә иске татар имлясын яклап язылган хатка кул куя.
**1930 нчы елларда** Г. Рәхим ике тапкыр хөкем ителә: Беломорканал төзелешендә катнаша. Азат ителгәч, Казан университетының иске кульязмалар бүлегенә эшкә керә. Аннан китәргә мәҗбүр булгач, гади банк хезмәткәре булып эшли.
**1937 елның июлендә** кабат кулга алына, сәламәтлеге какшау сәбәпле, **1943 ел** башында ул вакытыннан алда ирекккә чыга. Казанда вафат була.

### Проза әсәрләре

**«Яз әкиятләре»**
**«Серле-серле әкият»**
**«Хан мәчетендә»**
**«Эч пошканда»**
**«Бер шагыйрьнең өйләнүе»**
**«Идел»** һ. б.

### Фәнни хезмәтләре

**«Халык әдәбиятыбызга бер караш»**
**«Татар әдәбияты тарихы»** (Г. Газиз белән бергә язылган),
**«Утыз еллык хезмәт»**,
**«Тукаев – халык шагыйре»** һ. б.

*...Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, М. Хәнәфи салган сукмакларны күзалламый торып, татар әдәбиятының үсеш юнәлешләрен барлау-җыю да мөмкин түгел. Нәкъ менә талантлы кешеләр күпләп әдәбият мәйданына атылганга, мәдәниятә хезмәтне милләткә хезмәт дип санаганга гына, гасыр башы алтын чорына аяк баса, тизләтелгән үсеш чоры кичерә ала. Булганнары, иҗат иткәннәре, милләтне ярату белән сугарылган рухларын әсәрләрендә күрсәтә алганнары өчен рәхмәт аларга!*
***Д. Заһидуллина**, әдәбият галиме*

## Моны белү кызыклы...

1) Әтисе Мөхәммәтшакир II гильдия сәүдәгәре була, улын да үз эзеннән җибәрергә тели, ләкин Гали Рәхим иҗат өлкәсен сайлый.
2) Галимнең 1931 елга кадәр җыелган кульязмалары һәм археографик табылдыклары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.
3) Композитор Солтан Габәши белән «Кәккүк» җырын иҗат итә.
4) Барлыгы 50гә якын фәнни хезмәте басыла.
5) Хатыны Гайшә – күренекле сәүдәгәр Габдулла Апанаев кызы, табибә. Сталин репрессияләре корбаны. 1967 елда Бакуда вафат була.
6)17 яшендә рус телендәге «Вокруг света» китабына нигезләнеп, мәдрәсәләр өчен «Җир йөзе» дип аталган география дәреслеге бастыра.
7) Гарәп, фарсы, төрек, татар, рус телләрен белә.
8) Гомәр Хәйям, Хафиз, Ширази, Руми, Рабиндранат Тагор әсәрләрен, Шекспирның «Гамлет»ын татарчага тәрҗемә итә.

И туган тел, и матур тел...

# «Яз әкиятләре» (1913)

**Жанры:** хикәя

**Темасы:** башкалардан файдаланып яшәү

**Төп образлар:** канәфер агачы, эт эчәгесе (аллегорик образлар)

**Пейзаж образлары:** йолдызлар, кояш, йомшак җил, салкын чык, сандугач, караңгы төн

## Эт эчәгесе

- **үрмәләп үсә торган үлән;**
- **куркак** (*«куркынып тишелеп чыкты»*);
- **югарыга үрмәләргә омтыла;**
- **көчсез** (*«сыны калтырый иде»*);
- **зәгыйфь;**
- **кеше кебек тоя, уйлый, сөйләшә, тирә-юнь-дәгеләргә эндәшә** (*«кара елан шикелле» үрмәли*);
- **мәкерле, ялганчы, мәрхәмәтсез;**
- **мәхәббәте мәкерле, хәйлә белән эш итә.**

*Табигый яктан ныклы «үзәге» булмавы, җиргә ятып, үрмәләп үсүе белән көчсез, әмма мәкерле ялганы белән көчле.*

Бу сыйфатлар кешедән файдаланып яшәүчеләр, мәкерле кешеләр турында сөйли.

## Канәфер чәчәге

- **зифа буйлы, тиз үсүчән куак;**
- **йомшак холыклы, тыныч, буйсынучан;**
- **беркатлы, һәр әйткән сүзгә ышанучан;**
- **кеше кебек тәэсирләнә** (*«дерелдәде», «бөтен тәне ут белән тулды», «актык сулышын җыйды», «үлде»*);
- **үз гомерен саклап калу өчен тырышмый, көрәшми.**

*Куак булып югарыга таба үсүе белән көчле, әмма беркатлы булуы, көрәшә алмавы белән көчсез.*

Үз тирәсендәге һәркемгә ышанып яшәүчеләр, йомшак характерлы кешеләр турында сөйли.

## Сюжет элементлары:

**Экспозиция** – эт эчәгесе, канәфер белән танышу

**Төенләнеш** – эт эчәгесенең канәфер агачына үрмәләп китүе

**Вакыйгалар үстерелеше** – эт эчәгесенең мәхәббәт аңлатуы, канәфер агачына уралып, кояшка үрмәләве

**Кульминацион нокта** – канәфер агачы яфракларының күләгәдә калып, кояшка чыга алмавы

**Чишелеш** – канәфер агачының үлеме

**Конфликт**: Мәкер ↔ Мәхәббәткә ышану

## ИДЕЯСЕ:

Кояш астындагы урын өчен көрәшү, башкалардан файдаланып, үз максатыңа ирешү омтылышы – кешелек яшәешенә хас мәңгелек канун.

ӘДӘБИ НУРЛАР



# Һади Такташ

1901–1931

# Мәхәббәт җырчысы

## Беренче чор иҗаты (1916–1922)

- Романтик сурәтләү, бунтарьлык рухының өстенлек итүе;
- дини-мифологик, символик образларның үзәктә торуы;
- мәхәббәттә янучы лирик герой;
- фәлсәфи эчтәлекле әсәрләр;
- гомумкешелек кыйммәтләрен яклавы һ. б.

## Икенче чор иҗаты (1923–1931)

- Реалистик алымнарга борылыш;
- гыйсъянчы лирик герой;
- чынбарлыкка, яңа җәмгыятькә бәя;
- яшьлек, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләренә мөрәҗәгать итү;
- халыкчанлык, юмор;
- романтизм белән реализмның үрелеп баруы һ. б.

## Шагыйрь

«Ак чәчәкләр»
«Таң кызы»
«Урман кызы»
«Газраилләр»
«Күктән сөрелгәннәр»
«Алсу»
«Мокамай» һ. б.

## Прозаик

«Караборынның дусты»

## Драматург

«Җир уллары трагедиясе»
«Камил» һ. б.

## Татар әдәбиятының күренекле шагыйре

Мөхәммәтһади Такташев **1901 елның 1 гыйнварында** Тамбов губернасының Сыркыды авылында туа. Кечкенәдән үк укырга, җырлар, такмаклар чыгарырга һәвәс булып үсә. Беренче дәресләрне әти-әнисеннән ала, соңрак Пешлә мәдрәсәсендә укый. Беренче Бөтендөнья сугышы елларында Урта Азия якларында сәүдәгәрнең өендә хезмәтче, мануфактура кибетендә приказчик өйрәнчеге булып эшли. Буш вакытларында төрле мәдәни эшләргә, һәвәскәрләр оештырган спектакль, концертларга йөри, матбугатта беренче язмалары күренә.


**1918 елның** көзендә Такташ туган авылы Сыркыдыга кайта. Авыл мәктәбендә укытучы булып эшли. **1919 елның** көзендә Оренбургка китә. Монда ул «Юксыллар сүзе» газетасында эшли. **1921 елның** язында Ташкент шәһәренә күчә, «Белем йорты» журналының сәркатибе булып эшли. Шул вакытта тагын Кызылармиячеләр мәктәбендә тел-әдәбият укыта. **1922 елның** җәендә Мәскәүгә күченә. Анда берничә ай яши һәм көзен Казанга килә. Башта ул театрда, аннан «Чаян», «Яңалиф», «Авыл яшьләре», «Азат хатын» редакцияләрендә эшли, тулысынча иҗат дөньясына чума.

**1931 елның декабрендә** Казанда вафат була.

> ***Такташ – көчле талант, шигърият чишмәсе.***
> ***Ә. Еники,*** *язучы*

## Моны белү кызыклы...

- *Шагыйрьгә, тугач, Мөхәммәтҗан дип исем кушалар, әмма, авырып китү сәбәпле, Мөхәммәтһадигә үзгәртәләр.*
- *Һ. Такташ сукбай эт-мәчеләрне ашатырга, сыендырырга яраткан.*
- *Шагыйрь ике тапкыр гаилә кора, хатыннарының икесе дә Гөлчирә исемле була: Гөлчирә Хәмзина һәм Гөлчирә Мансурова.*
- *Казанда аның исемен йөрткән урам бар.*



Шагыйрьнең туган ягындагы музее

# «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927)

**Жанры:** поэма

**Темасы:** яшьлек, мәхәббәт, ярату хисләре, җаваплылык

## Сюжет элементлары:

**Экспозиция** – егет белән кызның танышуы һәм бер-берсен яратуы

**Төенләнеш** – яшьләр арасындагы якынлыктан соң Мәхмүтнең Зөбәйдәне ташлап китүе

**Вакыйгалар үстерелеше** – Зөбәйдәнең Мәхмүткә хат язуы, сөйгәнен көтүе; егетнең кызга битарафлыгы

**Кульминацион нокта** – Зөбәйдәнең бала табуы, Мәхмүтнең баланы күрергә килүе

**Чишелеш** – яшьләрнең үзара аңлашып, гаилә тормышын башлап җибәрүләре

## Проблемалар:

- «мәхәббәт» төшенчәсен аңлау, ярату хисенең зурлыгы, матурлыгы;
- «ирекле сөю»гә караш;
- бәхетле гаиләнең нигезе;
- шәхес иреге һәм бер-берең алдында җаваплылык;
- ана булу хокукы һәм вазифасы h. б.

**Кереш өлеше** (яшьлек, мәхәббәт турындагы фикерләр бирелеше)

Яшьлек хисе һәм картлык акылы каршылыгында бирелә.

**Төп өлеш** (Зөбәйдәнең гыйшкы, аның сәбәпләре)

**Йомгак өлеше** (ялгыз ай хәсрәтен тасвирлау)

Зөбәйдәнең хәсрәтен уртаклашу, аның белән охшашлыкны күрсәтү өчен автор ялгыз ай, җил, песи образларын кертә.

**Зөбәйдә** – комсомолка кыз, чибәр. Карт әнисе белән яши. Мәхмүткә гашыйк була, сөюнең җавапсыз икәнен тойса да, ярату хисенә бирелеп алдана. Туачак баласы алдында җаваплылыкны аңлый. Ихтыяр көче, сабырлык хас.

**Мәхмүт** – «наборщик», ягъни хәреф җыючы булып эшли. Җыелышларда доклад сөйли, театрга йөри. Сәясәттән, сәнгатьтән читтә тормый торган кеше. Шул ук вакытта ул яңа тормышта әхлакның нигезе «ирекле сөю» булырга тиеш дип уйлый. Бу – аның ялгышы. Йомшак характерлы. Эчке каршылыгын җиңеп, ата буларак җаваплылыгын аңлый.

**Лирик герой** – бай тормыш тәҗрибәсе туплаган, әмма яшьлек дәртен җуймаган, акылын йөрәгенә башлык иткән шәхес. Ул тормыштан тәм һәм ямь табып яши.

**Тел-сурәтләү чаралары:**
**чагыштыру** (*«кара болыт кебек», «мәхәббәт тә нәфис чәчәк кебек»*); **эпитет** (*«сандугачлы таңнар», «азгын күңел»*); **метафора** (*«тәңкә карлар»*), **сынландыру** (*«ә ай күктә һаман сүгенеп йөри»*)

**Идеясе:** яшьлек ялгышларыннан сакланып, үзара ышанычка, хисләр сафлыгына, җаваплылыкка нигезләнгәндә генә, бәхетле гаилә корырга була.

# Театр яктылыкка, нурга илтә...



## Кәрим Тинчурин

1887–1938

### Татар драматургиясе классигы, күренекле артист һәм режиссёр

**1887 елның 15 сентябрендә** Пенза өлкәсе Аккүл авылында туа. Күрше авыл мәдрәсәсендә башлангыч белем ала. Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. **1910 елда** Г. Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасына артист булып урнаша. Беренче пьесаларын яза һәм тиз арада драматург буларак таныла. Оренбург, Ташкент шәһәрләрендә театр бүлегендә эшли. «Сәйяр» труппасын җитәкли. **1922 елда** Казанда Татар дәүләт театрын оештыра. Спектакльләрдә үзе дә артист буларак катнаша. **1926 елда** «Татарстанның атказанган артисты» дигән исем бирелә. Язучылар берлегенә кабул ителә.

К. Тинчурин – шәхес культы корбаны. 50 яше тулган көннәрдә – **1937 елның 17 сентябрендә** «халык дошманы» дип нахакка гаепләнеп, кулга алына һәм **1938 елның 14 ноябрендә** атып үтерелә.

**1956 елда** әдип тулысынча аклана, әсәрләре басыла, сәхнәләрдә уйнала башлый.

### Жанр төрлелеге


**12** комедия,
**5** драма,
**3** трагедия,
**5** музыкаль драма,
**4** әсәре башка авторлар белән берлектә язылды.

### Прозаик

К. Тинчуринның утыз хикәясе бар, шулар арасында – новеллалар тезмәсеннән торган **«Мәрҗәннәр»** дә.

### Драматург

**«Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Американ», «Казан сөлгесе», «Сакла, шартламасын!», «Назлы кияү», «Җилкәнсезләр», «Кандыр буе»** һ. б.




*«Зәңгәр шәл»не халык үзенеке итеп саный. Үзенеке итеп санаганга, беркайчан да онытмый.*
*Т. Миңнуллин, драматург*

**Хәтер сандыгыннан**

- К. Тинчурин пьесаларында кайбер рольләрне аерым артистларга атап язган. Мәсәлән: «Җилкәнсезләр» драмасында Дилбәрне – артистка Фатыйма Ильская, Оркыяны – Нәфыйга Арапова, «Зәңгәр шәл»дә ишан ролен Зәйни Солтанов өчен.
- Иң күп куелган спектакле – «Зәңгәр шәл». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәр сезонын К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасы белән ачып җибәрә.
- Галия Кайбицкаяга җырчы булып китәргә этәргечне К. Тинчурин бирә.
- К. Тинчурин антиквар кибетләренә, комиссион кибетләргә кереп, борынгы савыт-саба сатып алырга яраткан. Аларны хатыны кадерләп саклаган.
- Бөек композитор Салих Сәйдәшев белән якын дуслар булганнар.

- Музыкаль драма жанрына нигез сала.
- Сатирик комедия юнәлешен югары баскычка күтәрә.
- Чорның үзенчәлекле типларын тудыра: Надир мәхдүм, Исмәгыйль, Муса, Габдуллаҗан һ.б.
- Образлар тудыруда халыкның бай һәм җор теленнән, үзенчәлекле сурәтләү алымнарыннан иркен файдалана.



1988 елда Татар дәүләт драма һәм комедия театрына К. Тинчурин исеме бирелә

# «Сүнгән йолдызлар» (1922)

**Жанры:** драма
**Жанр формасы:** фаҗигале драма
**Темасы:** кеше бәхете, тормыш гаделсезлеге

## Проблемалары:

- мәхәббәт хисенең зурлыгы;
- кеше хокукы, аның язмышы;
- сугыш афәте;
- кеше кадере булмау;
- тормыш гаделсезлеге;
- иске гадәт-күренешләрне кире кагу.

## Идеясе:

Матур хыяллар белән яшәүче, бәхеткә тулы хокуклы геройларның үлеменә сәбәпче булган сугышка, аны башлаучыларга нәфрәт, ләгънәт һәм тормыш гаделсезлегенә ачыну аша автор мәхәббәтнең иң бөек хис булуы турында сөйли, җәмгыять кануннары кеше бәхетен җимерә, дип кабатлый.

## Драманың сюжет-композициясе:

вакыйгалар «мәхәббәт өчпочмагы»на корылган.

- **Экспозиция** → Хәзрәттә хезмәт итүче ятим егет Исмәгыйль Сәрвәрне ярата. Әбисе белән генә яшәүче кыз аның мәхәббәтенә җавап бирә. Надир мәхдүм дә, хат язып, Сәрвәрне яратуын белдерә.
- **Төенләнеш** → Сугыш башлана.
- **Хәрәкәт үстерелеше** → Егетләрнең бер өлеше төрле юллар белән солдат хезмәтеннән котылып кала, бер төркемен сугышка алып китәләр. Сөйгәне белән аерылуны уйлап, Сәрвәр хәсрәт эчендә яши башлый.
- **Кульминацион нокта** → Сәрвәр үз куллары белән Исмәгыйльнең колагына «дару» сала. Егет үлә.
- **Чишелеш** → Сәрвәр акылдан яза, соңрак сөйгәне кабере өстендә җан бирә. «Соңгы өмете», «актык йолдызы» булган Сәрвәр үлеменнән соң Надир да үз-үзенә кул сала.

## Сәнгатьчә эшләнеше:

- сюжет-композициясенең төзеклеге;
- образ-характерларның сәнгатьчә эшләнеше камил;
- музыкаль жанр булуы;
- халык иҗатыннан оста файдалану;
- лиризм белән трагизмның үрелеп баруы;
- геройларның рухи дөньясын ачуда психологизм алымнарына мөрәҗәгать итү.

# И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

ӘДӘБИ НУРЛАР. МЕНТАЛЬ КАРТАЛАР



## Габдулла Тукай
1886–1913

Әтисе Мөхәммәтгариф Әнисе Бибимәмдүдә Шәрифә карчык



**Кушлавыч**
(1886–1887; 1894; 1907)

Әнисе Бибимәмдүдә Үги әти



**Сасна Пучинкәсе**
(1889–1890)

Зиннәтулла карт



**Өчиле**
(1887–1889; 1890–1891; 1892; 1907; 1911–1912)

Мөхәммәтвәли абзый Газизә апа



**Казан**
(1891–1892)

Сәгъди абзый Зөһрә апа



**Кырлай**
(1892–1894; 1907)

Газизә апасы, җизнәсе Галиәсгар Госманов



**Җаек (Уральск)**
(1894–1907)

## Шагыйрь эзләреннән

- *Түбән Новгородта Мәкәрҗә ярминкәсе*
- *Сембердә Гурьевка фабрикасы*
- *Әстерханда С. Рәмиевтә кунакта*
- *Уфада «Сабах» көтепханәсе*
- *Петербургта табибка күренергә бару (1912)*
- *Троицкида кымыз далаларында дәвалану*

## Моны белү кызыклы...

- Габдулла Тукай 4 яшеннән тулы ятим кала.
- Балачакта кушаматы «мулла баласы» була.
- Әтисе ягыннан фамилиясе – Гарифов.
- Татар, гарәп, фарсы, төрек һәм рус телләрендә иркен аралаша һәм яза.
- Әсәрләре дөньяның 40 ка якын теленә тәрҗемә ителә.
- Кыска гына иҗат гомерендә шагыйрь 9 поэма, 400 дән артык шигырь, 350 ләп эпик әсәр, истәлекләр, мәсәлләр яза.
- Балалар өчен 150 дән артык әсәр иҗат итә.
- Якын дуслары – Габдулла Кариев, Галиәсгар Камал һәм Фатих Әмирхан.
- Тукайны җирләгән көн, матәм көне булып, Казанда кибетләр, завод-фабрикалар эшләми, мәктәп-мәдрәсәләрдә укулар туктатыла.
- Шагыйрь моңлы җырлар башкарырга ярата.



## Балачак (1886–1895)

**Күренекле әсәрләре:**

• «Туган тел» • «Туган авыл» • «Шүрәле» • «Су анасы» • «Театр» • «Милли моңнар» • «Өзелгән өмид» • «Исемдә калганнар» һ. б.

## Җаек чоры (1894–1907)

- Җизнәсе Галиәсгар Госманов йортында яши (1895–1906).
- Әхмәтша Сиразетдинов укыткан рус классында белем ала.
- «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укый.
- Беренче шигырьләрен яза башлый.

### Тәхәллүсләре (псевдонимнары)

Галимнәр Тукайның үз мәкаләләрен имзалаганда 70 кә якын тәхәллүсе булуын дәлиллиләр. Алар арасында «Кырмыска», «Шүрәле», «Тәртә башы», «Догачы», «Каз», «Бер фикерче», «Биик усал», «Болгар», «Имзасыз да Ярәретдинов», «Милләтче», «Мин язмадым», «Мылтык», «Мәҗнүн», «Мөсафир», «Салам Торхан», «Счет төймәсе», «Сөңге», «Уральск кешесе», «Хәйләсез», «Чапансыз», «Шәкерт угы», «Җен» һ. б. тәхәллүсләр бар.

## Казан чоры (1907–1913)



«Болгар» (1907–1912) һәм «Амур» (1912–1913) кунакханәләрендә яши.

# «Исемдә калганнар»

**Язылу вакыты:** 1909 ел
**Жанры:** автобиографик повесть




## Кушлавыч

1. Авыл кешеләреннән ишеткәннәргә таянып язу: әтисе Мөхәммәтгарифның үлеме, әнисенең кабат кияүгә чыгуы.
2. Вакытлыча Шәрифә карчыкка калдырылуы.

*Кадалмас әле килмешәк!*

## Сасна

1. Саснага бару шатлыгы, үги әтисенең яратуы.
2. Әнисенең үлеме.

*“Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!”*

## Өчиле

1. Бабасы Зиннәтулла карт йортында яшәве.
2. Саҗидә апасының яратуын тоюы.
3. Ямщикка утыртып Казанга озатылуы.

*“Үги әбинең алты күгәрчене эчендә мин бер чәукә!”*

## Казан

1. Яңа Бистәдә Мөхәммәтвәли абзый һәм Газизә апаларда яшәве.
2. Печән базары, Ташаяк базарына бару хатирәләре.
3. Яңа әти-әнисенең авырый башлавы сәбәпле, Габдулланың авылга озатылуы.

*Асрамага бала бирәм, кем ала?*


## Кырлай

1. Сәгъди абзый һәм Зөһрә апа гаиләсендә яши башлавы.
2. Күңелле чаклар.
3. Авыл мәдрәсәсенә укырга керүе.
4. Җаекка алып китүләре.

*“Бу Кырлай авылы – минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным...”*

ӘДӘБИ НУРЛАР. МЕНТАЛЬ КАРТАЛАР

# *Иҗат — гүзәл гамь ул...*



## Хәсән Туфан

1900–1981

Танылган шагыйрь, XX йөз әдәбият мәйданында үз мәктәбен булдырган сүз остасы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

Хисбулла Гөлзизин **1900 елның 9 декабрендә** Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында туа. Башлангыч белемне туган ягында ала. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый, беренче шигырьләренә Г. Ибраһимов зур бәя бирә, шигъриятькә өнди. Соңрак Х. Туфан Лысьва, Чита, Верхнеудинскида балалар укыта. Казанда Көнчыгыш педагогика институтында белем ала, радиокомитетта эшли. **1928–1930 елларда** Кавказ, Урта Азия якларында җәяүле сәяхәттә була. **1940 нчы елларда** халык дошманы дип кулга алына. 16 ел гомерен төрмәдә, сөргенлектә үткәрә. **1956 елда,** тулысынча акланганнан соң, Казанга кайта. Гомере буе шигърияткә тугры кала.

### Кыска гына әйткәндә...

- Х. Туфан буш вакытларында сәгать төзәтергә яраткан.
- Мандолинада, скрипкада уйный белгән.
- Шигырьләрен яшел төстәге ручка белән генә язган.
- Аккош күлендәге бакчасында чәчәкләр үстергән. Кыр чәчәкләрен, аеруча ромашкаларны яраткан.
- Дачасында дүрт аяклы дусты – Сарбай кушаматлы этне ияртеп йөргән.
- Ел саен беренче сентябрь иртәсендә Г. Тукай һәйкәленә үзе үстергән чәчәк бәйләмнәрен сала торган булган.





Х. Туфанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында музей-йорты.

Хәсән Туфан исемендәге планета бар. Планета 1995 елда Казан университеты станциясе тарафыннан ачыла. 2010 елда Халыкара астрономия союзы тарафыннан кабул ителә. Карар турындагы таныклык Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана.

> *...Туфанны – шигърияттән, шигырьне Туфаннан башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Шигырьнең теләсә нинди киртәләрне җимерерлек тылсымлы көче барлыгына Туфан кебек чын күңелдән инанган башка кешене мин белмим...*
>
> ***Г. Бәширов**, язучы*

### 1920–1930 нчы еллар иҗаты (1924–1940)

- **«Урал эскизлары»**
- **«Ак каен»**
- **«Ә үткәнгә хатлар бармыйлар»** һ. б.

### Тоткынлык чоры иҗаты (1940–1956)

- **«Гөлләр инде яфрак яралар»**
- **«Иртәләрем-кичләрем»**
- **«Киек казлар»**
- **«Иртәләр җитте исә»**
- **«Кайсыгызның кулы җылы?»**
- **«Каеннар сары иде»**
- **«Агыла да болыт агыла»** һ. б.

### 1960–1980 нче еллар иҗаты (1956–1981)

- **«Әйткән идең»**
- **«Ромашкалар»**
- **«Сөйли торган материя»** һ. б.

Шагыйрьгә, тугач, Хизбулла дип исем кушыла, фамилиясен әнисе исеменнән алалар: Гөлзизин. 1905 елдан фамилиясен әтисенең шөгыле буенча Хәзрәтовка үзгәртә.

Соңрак Хәсән Кусенов исем-фамилиясендә йөри башлый. Аннан соң үзенә гомерлеккә Хәсән Туфан тәхәллүсен ала.

# «Кайсыгызның кулы җылы?» (1956)

**Әдәби төре:** лирика

**Жанры:** күңел лирикасы

*Шигырь Х. Туфанның күңел фаҗигасен бербөтен итеп ачып бирә, лирик герой **хәсрәте мотивы** үзәккә куела.*

**ХИС** → **Сагыш хисе** → **Әрну хисе**

**ХИСНЕҢ СӘБӘБЕ** → Лирик геройның даими хәсрәте (тоткынлыкта үткәргән еллары) | Яңа хәсрәте – хатынының үлеме

Еламаска өйрәну гыйбарәсе; күлмәк җиңе, йөрәк ярасы, сугыш һәм дала образлары.

Хат, юл, алка, кабер образлары; «вулканнарга керү» гыйбарәсе.

*«Бирде дөнья кирәкне...»* – лирик геройның күпме хәсрәт-михнәт күрүе

***Сурәтләнгән чор** – шагыйрьнең сөрген вакыты («...ята идем далада»).*

*«Сугышлардан замана*
*Тынып торган арада» –*

***сүз «җепшеклек чоры» башлану турында бара.***

**Шигырь эзоп теле (читләтеп, яшерен әйтү) алымын кулланып язылган**

**Шартлы образ-символлар (эзоп теле)**

- **Күлмәк җиңе**
  - *«Күлмәк җиңен ертасымы?!»*
  - **Лирик геройның чарасыз булуы, ялгызлыгы**
- **Сугыш, дала**
  - **Лирик геройның тоткынлык чоры**
- **Кабер, алка**
  - **Үлем һәм мәхәббәт билгесе символы**

Йөрәк ярасы, яраны бәйләү – **метафоралар**

**ХИС ДӘРӘҖӘСЕ**
- *«Еламаска өйрәтте»* ← Лирик геройның чыдамлыгы, бик күп хәсрәт чигүе. **Шигырьнең ФОКУСЫ**
- *«Вулканнарга керер идем...»* ← **Хәсрәтнең иң югары ноктасы**

**ЮАНУ** → *«Кайсыгызның кулы җылы? – Бәйлисе бар йөрәкне...»* ← *Якыннарның җылы мөнәсәбәте, мәхәббәте*



И туган тел, и матур тел...

# *Музыкаль драмаларга нигез салучы*



И туган тел, и матур тел...



## Мирхәйдәр Фәйзи

1891–1928

### Татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь

Мирхәйдәр Фәйзуллин **1891 елның 31 октябрендә** Оренбург губернасы Орск өязе Күкшел авылында туа. Булачак драматург укымышлы һәм житеш тормышлы гаиләдә тәрбияләнә. Бераздан гаилә Орск шәһәренә күченә. Кечкенә Мирхәйдәр авылда чакта ук абыстайлардан сабак ала. Ике ел Орск мәдрәсәсендә укый. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Кечкенәдән сәламәтлеккә туймаган Мирхәйдәр ике елдан укуын ташларга мәҗбүр була һәм авылына кайтып китә. Кулына кергән китапларны укып белемен күтәрә, шигырьләр яза. Әдип гомеренең соңгы көненә кадәр иҗат итә.

Кече яшьтән үк килгән йөрәк авыруы, соңрак башланган үпкә туберкулёзы язучының сәламәтлеген тәмам какшата һәм гомерен чикли – Мирхәйдәр Фәйзи **1928 елның 9 июлендә** Башкортстанның Баймак шәһәрендә вафат була һәм шунда җирләнә. Анда драматургның музее эшли, бюсты куелган.

***Мирхәйдәр Фәйзи үзенең кыска гына иҗат дәверендә 18 сәхнә әсәре яза, 7 пьеса тәрҗемә итә, халык җырлары җыентыгын төзи, 200 дән артык шигырь, дистәләгән хикәя яза, 70 көндәлек дәфтәре калдыра.***

*«Галиябану» драмасы бөтен татар драматургиясендә иң камил, иң халыкчан әсәрләрдән санала. Ул – театр сәхнәсендә иң күп куелган драмаларның берсе. Әлеге әсәр М. Фәйзигә дан китерә. Ул драматург буларак таныла.*

*«Галиябану» үрнәгендә татар сәхнәсендә күпсанлы музыкаль әсәрләр һәм ахырда бу жанрның тагын да катлаулырак, югарырак төре булган опера драматургиясе барлыкка килә.*

### Драмалары

«Галиябану» (1916)
«Асылъяр» (1920)
«Ак калфак» (1922)
«Адашкан күңел» (1923)
«Яшьләр алдатмыйлар» (1912)
«Кызганыч» (1913)
«Тәкъдир шаяруы» (1913) һ. б.

### Хәтер сандыгыннан

- М. Фәйзинең әнисе атаклы Камай морза нәселеннән була.
- Язучы гармунда, думбрада уйнарга яраткан, матур җырлаган. Хикәяләр, шигырьләр язган, тәрҗемәче дә булган. Аның төрек теленнән тәрҗемәләре бар.
- Беренче пьесасын 14 яшьтә язган.
- Әдип нечкә күңелле, төгәл кеше булган. Үзенең һәрбер эш-гамәлләрен көндәлек дәфтәренә терки барган.
- Казан университетының сирәк кульязмалар бүлегендә М. Фәйзинең туу турында таныклыгыннан алып, үлгән көнне үзе кул куйган ышаныч кәгазенә кадәр саклана.
- «Галиябану» драмасында Хәлилнең прототибы язучының дусты Вафа була. Вафаның сөйгән кызы икенче берәүгә кияүгә чыгып китә. Драматург әсәренә нигезне шуннан алган.
- Спектакльдә Мирхәйдәр Фәйзи үзе кыз булып киенеп уйнаган.




Оренбург дәүләт татар драма театрына Мирхәйдәр Фәйзи исеме бирелә



Мирхәйдәр Фәйзинең музей-утары Татарстанның Балтач районы Шода авылында урнашкан

Әдәби нурлар

**Әдәби төре:** драма

**Жанр формасы:** музыкаль драма

Мәхәббәт «өчпочмагы»на корылган.

# «Галиябану» (1916)

**Темасы:** ике яшь йөрәкнең саф мәхәббәте һәм бу сөюнең фаҗигале язмышы

## Проблемалары:

1) гаделсезлек;
2) хатын-кыз азатлыгы;
3) шәхес иреге;
4) тәрбиялелек, әхлаклылык;
5) бәхетсез мәхәббәт һ. б.

## Сюжет-композиция үзенчәлекләре:

- **Экспозиция** → Хәлил, Галиябану белән танышу
- **Төенләнеш** → Хәлилнең «Исмәгыйль арага керә бит» дигән сүзләре
- **Вакыйгалар үстерелеше** → Яучы Бәдига килгәч, егетнең исемен әйтмичә сөйләшүе; су буенда Исмәгыйльнең Галиябануга бәйләнүе, Хәлилгә янавы; аның Бәдри белән Галимәбануны «сатып алуы»; Галиябануның, әти-әнисе ризалык бирмәгән очракта, Хәлил белән качып китеп, никахлашырга план коруы
- **Кульминацион нокта** → Исмәгыйльнең Галиябану белән Хәлил каршына чыгып басуы, кулына корал алуы
- **Чишелеш** → Исмәгыйльнең Хәлилне атып үтерүе

**Трагик пафос / романтик рух**

## Образлар системасы

- **Төп геройлар:** Галиябану, Хәлил, Исмәгыйль (әсәр барышында геройларның өчесенә дә аллегорик чагыштырулар китерелә: Галиябану – сандугач, Исмәгыйль – козгын, Хәлил сыерчыкны козгыннан коткарган карчыга белән тиңләштерелә)
- **Ярдәмче образлар:** Галиябануның әти-әнисе Галимәбану белән Бәдри, Садретдин
- **Эпизодик образлар:** Бәдига, старшина, авыл кешеләре, Сибгать, Хәмзә
- **Ясалма образлар:** *вагъдә, кульяулык, хат, җыр* – мәхәббәт символлары, *шәл* – сафлык символы, *револьвер* – явызлык символы

## Конфликт

Байлык, акча һәм дәрәҗә хатын-кызны бәхетле итә дигән караш ⟷ Кешедәге иң самими, керсез мәхәббәт хисе

**Идеясе:** мәхәббәт, кешеләр, туганнар арасындагы матур мөнәсәбәтләр яклауга һәм саклауга мохтаҗ дигән фикер үткәрелә, саф мәхәббәткә дан җырлана.

> **...Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең уен-көлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крестьян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр...**
>
> Г. Ибраһимов, язучы



# *Мәңгелек илчесе*

## Равил Фәйзуллин (1943)

**Татарстанның халык шагыйре (1999), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1978), М. Җәлил исемендәге премия лауреаты (1970)**

> ***Р. Фәйзуллин – татар шигъриятендә беркемнекенә дә охшамаган үз дөньясын тудырган, тудыра алган бәхетле шагыйрь.***
> ***Н. Гамбәр**, шагыйрь, тәнкыйтьче*

**1943 елның 4 августында** Татарстанның Балык Бистәсе районы Балтач авылында туа. Шул төбәкнең Котлы Бөкәш урта мәктәбен, Казан дәүләт университетын тәмамлый. Армия сафларында хезмәт итә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантураны тәмамлый. Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасы җитәкчесе булып эшли. **1973–1977 елларда** – Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе, **1989 елдан 2013 елга кадәр** «Казан утлары» әдәби журналының баш мөхәррире була.
Хәзерге көндә – «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры киңәшчесе.

### Татар әдәбиятында тоткан урыны:

- татар поэзиясендә кыю фикерле, фикер ныклыгы белән «Р. Фәйзуллиннар буыны»ның лидеры буларак билгеле;
- фәлсәфи-лирик шагыйрь;
- иҗатында метафора, символ, шартлы образ, алымнар өстенлек итә;
- 1960 нчы елларда поэзиягә хөр фикерле лирик геройны алып килә;
- поэзиядә үзгә шигырь формасын тудыра;
- кыскалыкка, аз сүзлелеккә омтыла, әлеге формага тирән киеренкелекне, фикер тыгызлыгын сала;
- шигырь-афоризм, шигырь-метафоралар иҗат итә;
- күләмле поэмаларында заманның җитди проблемаларын яктырта;
- шигырьләрендә гражданлык пафосы көчле;
- иҗатына ассоциатив фикерләү хас.





Шагыйрьнең туган ягында музее бар

### Балалар өчен басылган китаплары

«Рәсем ясыйм»
«Сәгать белән Сәгыйть»
«Газиз китабы»
«Чәчәкләр үстердем»
«Паласны кем кагар?»
«Якты моң» һ. б.

### Җырлар авторы

«Аккошлар»
«Мин сиңа йомшак таң җиле...»
«Кабат сагынма икән...»
«Кичер кайта алмавымны...»
«Иясез шатлык»
«Менә без дә үсеп җиттек, әни» һ. б.

### Поэмалар авторы

«Сәйдәш»
«Көрәшчеләр»
«Гадиләргә гимн» һ. б.

И туган тел, и матур тел...

# «...Җыя кеше» (1977)

Шигырь кеше гомеренең чиклелегенә бәйле туган сагыш хисе белән язылган.

## Кеше бу дөньяда җыя:

Символик образлар

- **мал** → *Гомер буе туплаган байлыгы*
- **дан** → *Бу дөньяда ирешкән дәрәҗәсе*
- **җыерчыклар** → *Кешенең хис-кичерешләре сәбәп була ала*
- **дошман** → *Яшәр өчен этәргеч бирә торган көч*

**Нәтиҗә:** адәм баласы берсен дә фани дөньядан алып китә алмый.

## Кешедән бу дөньяда кала:

Символик образлар

- **«Тирәкләргә сеңгән тавышы»** → *Яшьлек сере*
- **«Коймаларга сеңеп күләгәсе...»** → *Картлык истәлеге*
- **эше** → *«Бар яхшысы, бар яманы...»*
- **баласы** → *«Күзләренә кереп бата Кояш»*

**Нәтиҗә:** һәркем үзе китергән файда, кылган гамәлләре белән кеше хәтерендә кала

**Нәтиҗә:** автор, ике сүздән торган исем белән бәйләп, кеше гомеренең яшәү мәгънәсе, нәтиҗәсе турында сөйли

**Жанры:** фәлсәфи лирика

Шигырьнең эчтәлеге символлар тирәсенә туплана

**Инверсия күренеше:**
«Җыя кеше», «алып китә дошман җанын», «кала барысы», «кереп бата Кояш» һ. б.

Әйтеп бетерелмәгән фикер күп нокталар ярдәмендә җиткерелә.

**Темасы:**
кешенең бу дөньядагы яшәеше, тормыш мәгънәсе турында


**Идеясе:**
кеше, бу дөньяда яхшы гамәлләр, күркәм эшләр кылып, шуны дәвам итүче нәсел дәвамчысын калдырырга тиеш

**Кеше гомерен, нәселне дәвам итүче**

**Кояш – кеше үзе**

Әдәби нурлар

# ЕРАК ТАРИХЫБЫЗ ИЛЧЕСЕ



## Нурихан Фәттах

1928–2004

Татарстанның халык язучысы (1998), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1994)

*«Сызгыра торган уклар» – язучының иң зур табышы. Бу әсәрне мин, һич шикләнмичә, әдипнең ярты гасыр дәвамындагы иҗатының иң бөек ноктасы, төп китабы дип саныйм. Н. Фәттах – тынгысыз рухлы, кабул ителгән рәсми догмалар белән килешмичә, алар белән бәхәсләшеп, көрәшеп яшәүче әдип.*

***Н. Юзиев**, әдәбият галиме*

### Әсәрләре

- **«Итил суы ака торур»**
- **«Сызгыра торган уклар»**
- **«Кол Гали»**
- **«Шәҗәрә»**
- **«Кырык дүртнең май аенда»**
- **«Кичү»**
- **«Мөдир Сәҗидә»**
- **«Фест дисбесенең сере»** һ. б.

*Халыкара биографик үзәк (Кембридж, Англия) язучыны дөньяның күренекле шәхесләре исемлегенә кертә, «1992 ел кешесе» дигән диплом белән бүләкли.*

***Үземнең барлык иҗатым белән, тормышым белән мин халкымның бөеклеген исбат итәчәкмен...***

***Н. Фәттах***

Нурихан Фәттахов **1928 елның 25 октябрендә** Башкортстанның Яңавыл районы Күчтәвыл авылында туа. Бала чагы Яңа Уртавылда уза. Яңавыл урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетында белем ала. Матбугатта беренче язмалары күренә башлый. Татарстан китап нәшриятында, Чистай шәһәрендә «Сталин байрагы» газетасы редакциясендә эшли. **1953 елда** Казанга кайтып, профессиональ язучылык хезмәтенә күчә. **1955 елда** «Сезнеңчә ничек?» дигән беренче романы дөнья күрә. Казах далаларында чирәм җир күтәрү кампаниясендә катнаша: ике ел рәттән берничә ай Павлодар өлкәсендәге «Казан» совхозында эшли. «Бала күңеле далада» дип аталган икенче романы языла. Озак елларга сузылган эзләнүләре нәтиҗәсендә «Итил суы ака торур» (1970) тарихи романы белән «Кол Гали» (1973) трагедиясе иҗат ителә. **1977–1985 елларда** «Сызгыра торган уклар» – икенче тарихи роман-дилогиясе языла.
Балалар өчен «Тегермәндә», «Өч туган», «Ирек, Алмас һәм Җәлил», «Энҗеле үрдәк» әсәрләрен яза. В. Гюго, О. Бальзак, И. Гончаров әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

### Кыска гына әйткәндә...

- Н. Фәттах – төрки телләрнең борынгыдан дөнья-күләм таралышын, башкаларга йогынтысын өйрәнгән галим-язучы. Бу хакта «Фест дисбесенең сере», «Ерак гасырлар авазы» китапларында яза.
- Татар әдәбиятында беренчеләрдән булып борынгы төркиләр турында күләмле әсәр иҗат итә.
- Н. Фәттах – драматург. Театр сәхнәсендә «Кол Гали» трагедиясе уңышлы куела.
- Табиблар турында язылган «Мөдир Сәҗидә» әсәрен хатыны Руфинага багышлый.
- Н. Фәттахның балалар өчен язган хикәяләре дә бар.
- Н. Фәттах бик пөхтә кеше була.
- Эшләпә кияргә һәм галстук тагарга ярата.
- «Итил суы ака торур» романы өчен «азык, чимал» эзләп, Н. Фәттах 1960 нчы елларда ук Болгар каласы хәрабәләрендәге археологик казу эшләрендә катнаша.

*Итил суы ака торур,*
*Кыя суы ака торур,*
*Балык тәлим бака торур,*
*Күлең тәкый күшәрер.*
Борынгы заман халык җыры

# «Итил суы ака торур» (1970)

**Жанры:** роман

**Жанр формасы:** тарихи роман

**Темасы:** Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү

**Каршылыклар:**

ыру эчендә, ыру белән дәүләт, дәүләт белән дәүләт, тәңречелек белән ислам дине арасында

**Тышкы конфликтлар:**
- иҗтимагый
- әхлакый
- дини каршылыклар һ.б.

**Эчке конфликтлар:**
- Тотыш
- Койтым бикә
- Күрән би

## Сюжет сызыгы:

**Болгар дәүләте оешу һәм ислам дине кабул ителү белән бәйле вакыйгалар** | **Тотыш язмышы белән бәйле вакыйгалар**

**Экспозиция**
- Болгарлар күпсанлы ыруларга бүленеп яшиләр. Аларның яшәү рәвеше Акбүре ыруына бәйле тасвирлана.
- Акбүре ыруы башлыгы Күрән би улы Тотыш кыю, батыр, әмма үзсүзле егет булып үсә. Кыерсытуларны да күп күрә.

**Төенләнеш**
- Болгарларны берләштерү максатыннан Алмыш хан Казаяклар ыруы белән Акбүре ыруына сугыш игълан итә.
- Кабиләнең яшәү тәртипләренә каршы чыга: ыру өчен изге дип табылган бүреләрне, изге наратны мәсхәрәли.

**Вакыйгалар үстерелеше**
- Алмыш хан кечерәк ыруларны үзенә буйсындыра. Багдадтан илчеләр чакыра. Сәүдә эшен, төзелешне үстерә.
- Тотыш Алмыш хан батырлары белән сугышып яралана, тоткын итеп алына. Ханның кызы Аппакка гашыйк була. Ирек алып, иленә кайта. Алмыш ханга яучы җибәрә, әмма Аппакны Хәзәр ханы алып китә.

**Кульминацион нокта**
- Болгарга Багдадтан илче килә.
- Тотыш сабырсызлык күрсәтә, Алмыш хан биргән ярлыкны атып бәрә.

**Чишелеш**
- Тәңрегә табынган болгар кабиләләре берләшәләр, ислам динен кабул итәләр. Бердәм, көчле Болгар дәүләте төзелә башлый.
- Тотыш үз иленнән качып китә. Аппакны эзләп, Хәзәр иленә килә һәм шунда хәбәрсез югала.

## Проблемалар:
- кеше язмышы;
- шәхеснең тарихтагы урыны;
- бердәм дәүләт төзү, анда диннең роле;
- туган ил, халык алдында җаваплылык;
- әхлакый мәсьәләләр;
- социаль тигезсезлек;
- тарих аша заман вазгыятен, яшәешне аңларга тырышу.

## Идеясе:
автор, данлы һәм шанлы тарихны сурәтләп, татар халкының олпат һәм бөек милләт булуын раслый.

## Идел символик образы:
1) вак елгаларны үзенә җыйган елга буларак, Идел – бердәм дәүләт символы;
2) сулар агып, гасырлар үтсә дә, халыкның азатлыкка омтылышы дәвамлы;
3) елга суы кебек заманнар үтә, әһәмиятле вакыйгалар тарихта кала;
4) Идел – борынгы бабалар яшәгән җир, ул туган ил образын символлаштыра;
5) Идел елгасының агуы, табигый күренеш буларак, геройларның күңел дөньясын, рухи халәтен аңлата.

# Фикер шигърияте вәкиле



## Ренат Харис

1941

Татарстанның халык шагыйре (2004), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1997), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1972)

Ренат Харисов **1941 елның 6 маенда** Ульяновск өлкәсенең Цильна (Чынлы, элек – Богдашкино) районы Кәшә (Зирекле Күл) авылында туа. Балалык һәм мәктәп еллары Татарстанның Буа төбәгендәге авылларда уза. **1958 елны** Буа шәһәрендә А. Луначарский исемендәге урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп, 2 нче төзү-монтаж идарәсендә слесарь-сантехник булып эшли. **1959–1963 елларда** Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетында укый. Институтны тәмамлаганнан соң, Арча педагогика училищесында – рус теле һәм әдәбияты укытучысы (**1963–1964**), Татарстан өлкә комитетында пропаганда буенча инструктор (**1964–1965**) булып эшли. «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр, «Яшь ленинчы»да (хәзерге «Сабантуй») җаваплы сәркатип (**1965–1971**) һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе (**1971–1973**) вазифаларын башкара. **1973–1982 елларда** ул – Татарстанның мәдәният министры урынбасары, ә **1982–1989 елларда** – «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, **1989–1991 елларда** КПССның Татарстан өлкә комитетында идеология бүлеге мөдире булып эшли. **1991 елда** «Татарстан хәбәрләре» газетасын оештыруга турыдан-туры җитәкчелек итә һәм **1995 елга кадәр** бу газетаның баш мөхәррире була (соңыннан бу басма җирлегендә «Мәдәни җомга» газетасы оеша).
**1990 елдан** башлап өч чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты. **1995–1999 елларда** ул Дәүләт Советы Рәисе урынбасары вазифаларын башкара.

***Шигырьләре фәлсәфи эчтәлекле, тәэсирле, Җир шары кебек йомры, карлыгач канаты кебек сыгылмалы...***
***Т. Галиуллин**, әдәбият галиме*

### Лирик шигырьләре

«Өянке», «Диңгез янында уйлар олылана…», «Чигешем, тегешем», «Кеше кайчан матур?», «Чиксез кодрәт», «Ак шом», «Зәңгәр моң», «Ак теләк» һ. б.

### Сәхнә өчен иҗат ителгән әсәрләре

«Кеше», «Мулланур» **ораторияләре**; «Йосыф кыйссасы», «Шагыйрь мәхәббәте», «Алтын Казан» һ. б. **либреттолары**; «Умырзая», «Күзләреңне үбеп…», «Илдус һәм Windows», «Серле алан», «Абай-бабай аланы», «Кәкрүшкә» һ. б. **драмалары**

### Җырлары

«Әйтмә миңа», «Мәңгелек язым», «Гашыйк бул син миңа», «Зәңгәр томан», «Ак кәгазь», «Җылы буран», «Кәгазь көймә», «Бер генә сүз», «Ак теләкләр» һ. б.

### Поэмалары

«Рәссам», «Җәлилчеләр», «Ат иярләү», «Ант суы», «Бүре күзе», «Һарут белән Марут», «Чехов базары», «Мулланур», «Сабантуй» һ. б.

### Кыска гына әйткәндә...

1) Г. Державин, А. Пушкин, М. Лермонтов, Ф. Тютчев, С. Есенин, И. Северянин, М. Цветаева, А. Ахматова, Н. Хикмәт, Г. Лорка, Р. Гамзатов, П. Хузангай, О. Сөләйманов, Ю. Семендер әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.
2) Бик оста рәсем ясый.
3) Рәсемнәрне төссез карандаш белән үзе ясаган альбомнарга гына төшерә.
4) А. М. Горький исемендәге әдәби-мемориаль музейда узган графика әсәрләре күргәзмәсе (Казан, 1996) нәтиҗәләре буенча «Шигырь язган каләм белән...» китап-альбомы иҗат ителә.
5) Үзлегеннән гармун уйнарга өйрәнә, музыка ярата.
6) Кырыктан артык китабы басылган.

***Образлылык ягыннан Шәрыктан килгән алымнарны тергезү омтылышы көчле. Образлылык ягыннан Ренат Харис лирикасы – рәссам шигърияте.***
***Д. Заһидуллина**, әдәбият галиме*

# «Кеше кайчан матур?»

**Әдәби төре:** ЛИРИКА

**Жанры:** ГРАЖДАНЛЫК ЛИРИКАСЫ

**Мотивы:** матурлык

**Матурлык** → **Эчке матурлык**

**«Матурлык»** төшенчәсе шагыйрьгә рухи матурлык, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, ил каршындагы җаваплылык кебек **проблемаларны** күтәрергә ярдәм итә.

- кешеләргә күңел җылысы өләшү;
- кече күңелле, мәрхәмәтле, шәфкатьле була белү;
- дусларны онытмау, башкалар хәленә керә алу;
- зур дәрәҗәләргә ирешеп тә, гади булып калу;
- ил һәм халык өчен тырышу;
- ил каршында җаваплылык;
- башкаларга игелекле була белү һ. б.

### Тел-сурәтләү чаралары:

**Рефрен** – *«Кеше кайчан матур була?» һ. б.*
**Инверсия** – *«...Кеше матур шул чакта...» һ. б.*
**Метафора** – *«...күзләре җылынганда...», «бәхет белән сөйләшкәндә / бәхетнең үз телендә» һ. б.*
**Антоним** – *«...олы данга ирешеп тә, / кече булып калганда» һ. б.*

Шигырь композицион яктан **ике өлештән** тора. **Беренче өлеш** «Кеше кайчан матур?» соравы белән билгеләнә. Бу сорау шигырьнең автор үзе бүлеп куйган һәр бүлегендә кабатлана. **Икенче өлеш** кеше матурлыгын аңлата торган өлеш булып төгәлләнә. Лирик герой матурлыкның нидә булуын күрсәтә, кеше күңеленең матурлыгын билгели торган сыйфатларны аңлата.


**Идеясе:** **Кешене эчке бөтенлеге, күңел байлыгы, ил каршында бурычын аңлау һәм җаваплылык тойгысы матур итә.**

# Туган як җырчысы

**Татарстанның халык шагыйре (1986), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1960), РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1970)**

> *Сибгат Хәким – бөтен табигате белән лирик шагыйрь.*
> ***Х. Хәйри**, әдәбият галиме*

> *Татар күңелендә Тукаена мәхәббәтен яңартып торган, тугрылыклы шагыйрь ул.*
> ***Ш. Галиев**, шагыйрь*



## Сибгат Хәким
1911–1986

Сибгат Хәкимов **1911 елның 4 декабрендә** Әтнә районы Күлле Киме авылында туа. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, шунда ук пионерлар җитәкчесе булып эшли. **1931 елда** Казанда татрабфакта укый. Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый. Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар секторында – мөхәррир, соңрак «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр була. Бөек Ватан сугышында катнаша, укчы взвод, соңыннан рота командиры сыйфатында Ржев, Курск тирәсендә сугыша. Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Молдавиядәге чик буе гаскәрләренең округ хәрби газетасында инструктор булып хезмәт итә. **1945–1950 елларда** «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли. **1950 елдан** – профессиональ язучы хезмәтендә. **1986 елда** Казанда вафат була.

### Поэмалары

• «Кырыгынчы бүлмә» • «Пар ат» • «Үрләр аша» • «Эзлиләр Европа буйлап» • «Язгыбыз, Җир уллары» • «Дәверләр капкасы» • «Дуга» һ. б.

### Җырлары


• «Юксыну» • «Фазыл чишмәсе» • «Таң атканда» • «Башка берни дә кирәкми» • «Өзелгәнсең сиреньнән» • «Бер тауда ун чишмә» • «Кайда да йөрәктә» • «Сусау» һ. б.

### Танылган шигырьләре

• «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» • «Башка берни дә кирәкми» • «Күңелем Ленин белән сөйләшә» • «Вәгъдә» • «Әнкәй» • «Клиндерләр эзлим» һ. б.




Шагыйрьнең туган авылы – Әтнә районы Күлле Кимедә музее оештырылган

### Моны белү кызыклы...

1) С. Хәким Аккош күле буендагы дачасында җәмәгате үстергән ак пионнарны ярата, «Ак пионнар» шигыре дә шуңа атап языла.
2) Шагыйрь урманны үз иткән, агач төбенә утырып, иҗат итәргә ярата, һәр җәйне туган авылында үткәрә.
3) Ел саен Сабан туенда ат чабышында иң соңгы килгән атка олы бүләк әзерли торган була.
4) Сибгат Хәкимнең улы Рафаэль Хәкимов – күренекле җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Президенты киңәшчесе (1991–2008), Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры (1996–2020).

# «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» (1953)

**Әдәби төре:** ЛИРИКА

**Жанры:** КҮҢЕЛ ЛИРИКАСЫ

**Темасы:** ТУГАН ЯККА МӘХӘББӘТ

**Лирик герой** – авылда туып-үскән кеше. Шигырьдә аның туган ягына булган уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан. Туган ягын яратучы, аны сагынып яшәүче **шагыйрьнең үзе буларак күзаллана.** Шагыйрь белән лирик геройны бер үк дип кабул итәргә мөмкин. Ул туган ягыннан илһам алып яши, кичерешләре көчле, тәэсирле. Шигырьдә хиснең үсү-үзгәрүе сурәтләнә. Строфадан строфага аның көче тирәнәя, арта бара.

- **Сагыну хисе** → *Сагыну хисенең сәбәбе: туган яктан читтә булу*
- **Соклану хисе** → *Соклану хисенең сәбәбе: туган якның матурлыгы*

**Туган як тасвиры:**
- Таллар образы (*нәфислек*) → Табигать матурлыгы тудыралар; лирик геройны тәэсирләндерәләр
- Таулар образы (*горурлык*) → Табигать матурлыгы тудыралар; лирик геройны тәэсирләндерәләр
- Юллар образы → Киләчәктә матур эшләр тудырырга ашкындыра
- Жыр образы → Күңел һәм иҗат матурлыгы
- Серкә очырган арыш кырлары → Хезмәт һәм табигать матурлыгы

**«Бу кырлар, бу үзәннәрдә» лирик геройның:**
- **Яшьлеге узган:** *«мәхәббәтем яшьләй кабынган»*
- **Күңел халәтенең баюы:** *«күңелем… туймаган», «хисләрем… уйнаган»*
- **Бала чагы үткән** → **Эз образы**
  - тәүге атлап киткән җир;
  - тормыш арбасына иртә җигелү мәгънәсендә
- **Юл образы**
  - туган җир белән очраштыра торган;
  - зур тормышка, иҗатка алып кергән олы юл
- **Җыр образы**
  - туган җирендә үткән тормышына бәйле хатирәләре бар

**Төп сәнгати чаралар:**
- кабатлау
- анафора
- эндәш сүз

**Идеясе:**

туган як – кеше өчен иң кадерле, газиз җир, илһам һәм яшәү чыганагы.

**Композитор Җәүдәт Фәйзи шигырьне көйгә салган.**

# Татар әдәбиятының йөзек кашы

**Татарстанның халык язучысы (1993), әдәби тәнкыйтьче, публицист һәм драматург, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1972)**



## Фатих Хөсни

1908–1996

> ***Язучы художник.***
> ***Х. Камалов,*** *язучы*

> ***Фатих Хөсни – проза остасы.***
> ***Р. Сверигин,*** *әдәбият галиме*

> ***Әгәр Фатих Хөсни иҗаты булмаса, безнең әдәбиятыбыз ничектер тулы ук булып җитмәс, аның иң матур бизәкләренең берсе ким булыр иде.***
> ***Г. Бәширов,*** *язучы*

### Проза әсәрләре

«Йөзек кашы», «Җәй башы», «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы еллар», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» һ. б.

### Драмалары

«Еллар һәм юллар», «Бертуган Таһировлар»

**1908 елның 3 февралендә** Татарстанның хәзерге Саба районы Олы Мәтәскә авылында туа. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә һәм мәктәбендә ала. **1924–1929 елларда** Казандагы М. Вахитов исемендәге ун сыйныфлы күргәзмә-тәҗрибә мәктәбендә укый. Шунда укыганда каләм тибрәтә башлый: романтик рухтагы дистәләгән лирик шигыре дөнья күрә, очерклар, репортажлар бастыра. Беренче поэмалары, драмалары языла.
**1929–1933 елларда** Казан финанс-икътисад институтында укый. Хәрби хезмәттә дә иҗаттан аерылмый: укчы дивизия газетасы редакциясендә хәрби корреспондент була. Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә беренче драмасы куела.
Ватан сугышы чорында совет кешеләренең фронттагы һәм тылдагы фидакяр батырлыклары күп кенә әсәрләрендә чагыла. Алар арасында «Йөзек кашы» повесте (**1942**) аеруча игътибарга лаек.
Ватан сугышыннан соңгы елларда Ф. Хөсни үзен проза остасы буларак таныта: иҗади йөзен билгели торган күләмле әсәрләр яза. Язучының иҗат мирасында әдәби жанрлардан драматургия, әдәби тәнкыйть, публицистика, мемуар үрнәкләр дә күренекле урын тота. «Бертуган Таһировлар» (**1965**) драмасы үз вакытында, Татар дәүләт академия театрында куелып, тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә.
«Гыйльмениса һәм аның күршеләре» дигән повесте һәм шул исемдәге китапка кергән бер төркем сайланма хикәяләре өчен Ф. Хөсни Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. **1996 елда** Казанда вафат була.

### Моны белү кызыклы...

1. *«Йөзек кашы» исемле повесте рус, үзбәк, казах һ.б. телләргә тәрҗемә ителә, сәхнәдә уйнала.*
2. *Ф. Хөсни – туган ягын яратучы әдип. Бу хакта болай ди: «Күпме генә шәһәр шөлдерләре ассалар да, мин синеке, авыл...»*
3. *Ф. Хөснинең «Кошлар тынды» җырына композитор Хөснул Вәлиуллин көй яза.*
4. *1965 елда язган «Минем тәрәзәләрем» повесте автобиографик характерда.*
5. *Татарстан Язучылар берлегендә елның иң яхшы проза әсәре өчен бирелә торган премия Фатих Хөсни исемен йөртә.*
6. *Туган авылындагы мәктәпкә әдип исеме бирелә, музее эшли.*





# «Йөзек кашы» (1942)

**Жанры:** повесть

**Темасы:** мәхәббәт

## Проблемалары:
- кешелексезлек;
- әхлаксызлык;
- сугыш афәте;
- бәхет;
- мәхәббәт;
- тугрылык.

## Әсәрдә вакыйгалар бирелеше

| Айдарга хас сыйфатлар | Әсәрдә вакыйгалар бирелеше | Госманга хас сыйфатлар |
|---|---|---|
| Матурлыкны күрә белә, бәяли, уйлаганың эшли, **чабып китә** | Авылга алма сатучы килүе | Көнчел, Айдарның каефен боза. (1 нче каршылык) |
| Тәвәккәл, атны ярата, үзсүзле, тиз кызып китә, ярсу, **шахтага акча эшләргә китә** | Ат чабышы | Кешенең өстенлеген күрә алмый, үчлеген күрсәтә. (2 нче каршылык) |
| Эшчән, тырыш, сүзендә торучан, максат куя белә, үчле, дөреслекне ярата, сакчыл | Шахтада эшләү | |
| Чын күңелдән ярата белә, сүзендә тора, дуамал, кыю, **туйдан качып китә** | Кыз урлау | Ялагай, ялганчы, кеше бәхетсезлегенә куана (3 нче каршылык) |
| Батыр, вәгъдәсендә торучы, эшен җиренә җиткереп башкаручы, тәвәккәл, үч алучы | Сугыш | Куркак, сатлыкҗан, илгә хыянәт итәргә сәләтле. (4 нче каршылык) |

**Айдар** – тырыш, эш сөючән булса да, үрнәк образ түгел. Горур, тиз кызып китүчән, каршылыклы образ. Үзен дә, сөйгәнен дә бәхетсез итә. Кискен хәлләрдә гел дуамаллык белән җавап бирә.

**Вәсилә** – бик матур авыл кызы, гаять тыйнак, сабыр. Чын күңелдән ярата белә.

**Госман** – ышанычсыз, үчле, мәкерле кеше. Дусны да, илне дә сатарга әзер. Кеше бәхетсезлегеннән тәм таба.

**Идеясе:** йөзек кашы булырдай мәхәббәтне саклау, бәхетле булу үзебездән тора; ашыгыч карарлар кабул итмәскә кирәк; һәр кеше үзендә бәхетсезлекләрне ерып чыгарлык ихтыяр көче тәрбияләргә тиеш.

## Конфликт төрләре

**Эчке конфликт:**
- Айдар күңелендә
- Вәсилә күңелендә

**Тышкы конфликт:**
- Шәяхмәт – авыл кешеләре
- Айдар – Мамалай егетләре
- Айдар – техник
- Айдар – староста малае
- Айдар – Госман (төп каршылык)

## Символ

«Йөзек кашы» образы, символга әйләнеп, көчле позициягә чыгарыла. Йөзек – хатын-кызларның бизәнү әйбере, зиннәте. Ул кадерле һәм бәһале булырга тиеш. Госман шул зиннәтне, Вәсилә сизмәгәндә, кулыннан салдырып ала. Яшь парларның тормышын боза. Йөзек кыз балага хас булган сафлыкны гәүдәләндерә, мәхәббәт билгесе.

# Мәхәббәт һәм яшьлек җырчысы



## Илдар Юзеев

1933–2004

**Татарстанның халык шагыйре (1993), драматург, ТАССР комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе (1968), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1980), Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе**

Илдар Юзеев **1933 елның 3 гыйнварында** Башкортстан Республикасы Яңавыл районы Ямады авылында укытучы гаиләсендә туа. Үз авылында урта мәктәп тәмамлый, **1950–1954 елларда** Казан педагогика институтында югары белем ала. «Ялкын» һәм «Чаян» журналларында, Татарстан Язучылар берлегендә эшли. Мәскәүдә Югары әдәби курслар тәмамлый. «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге мөдире, Татарстан Язучылар берлегендә консультант була.

Аның беренче шигыре **1943 елда** – автор өченче сыйныфта укыганда ук басылып чыга. Ә инде унынчы сыйныфта чакта аның әсәрләре Башкортстан Республикасы матбугатында күренә башлый. Шагыйрь **1950 нче еллардан** үзенең төп иҗади көчен поэмалар, шигъри трагедияләр һәм поэтик сәхнә әсәрләре язуга багышлый. Җырлар иҗат итү өлкәсендә дә актив эшли.

**2004 елда** 71 яшендә Казанда вафат була.

> ***Моң эчендәге асылташ.***
> ***С. Поварисов**, әдәбият галиме*

## Моны белү кызыклы...

1) Абыйсы Нил Юзиев – әдәбият галиме. Бала чакта, абыйсы белән узышып, шигырь яза торган булган.
2) Шагыйрь гармунда уйнарга яраткан.
3) 1960 нчы елларда татар гаиләләрендә Резидә, Зөфәр исемнәрен кушу күбәя. Моңа И. Юзеев поэмасындагы әдәби геройлар сәбәпче була.
4) Шагыйрь дуслыкка гомер буе тугрылык саклый. Каләмдәше Ш. Галиев белән җан дуслар булалар. Әдәби очрашуларга һәрчак бергә йөриләр.
5) 2005 елда «Мәйдан» журналы Илдар Юзеев премиясен гамәлгә куя.

> ***И. Юзеев – милли байлыгыбыз, туган телебез хәзинәсе. Шагыйрь үзе илһамланып янган чәчәк.***
> ***Ш. Галиев**, шагыйрь*

## Поэмалары

● «Таныш моңнар» ● «Әнкәй» ● «Фәрит-Фәридә» ● «Өчәү чыктык ерак юлга» ● «Язылмаган поэма» ● «Тынлык белән сөйләшү» ● «Соңгы сынау» ● «Таш диварлар авазы» ● «Мәхәббәт китабы» һ. б.

## Драмалары

● «Резидәкәй» ● «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» ● «Кыр казлары артыннан» ● «Гашыйклар тавы» ● «Мәкәрҗәдә булган идек» ● «Ак калфагым төшердем кулдан» һ. б.

## Җырлары

● «Яшь наратлар» ● «Кайтам инде» ● «Бөркет турында баллада» ● «Мәтрүшкәләр» ● «Серле чәчәк» ● «Туган ягым каеннары» ● «Чит илләргә чыксаң» ● «Бәрәңге чәчәге» ● «Кыр казлары артыннан» һ. б.



2008 елда Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында шагыйрьнең музее ачыла

И туган тел, и матур тел...

# «Гашыйклар тавы» (1985–1986)

**Жанры:** повесть-поэма, драма

**Темасы:** риваятьләргә тиң мәхәббәт тарихы

**Кеше образлары:** Сәет Зилаеров, Мөнирә Идрисова, Өмет, Сәет (II), Алсу, хикәяләүче шагыйрь, Хәнәфи ага

**Җыелма образлар:** авыл яшьләре

**Абстракт һәм матди образлар:** көндәлек, җыр, риваять, төш

## Проблемалары:

- мәхәббәткә тугрылык;
- туган җир кадере;
- табигатьнең пычрануы һәм сакчыл карашның бетүе;
- гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы;
- әхлаксызлык;
- сугыш афәте;
- авылларны эреләндерү һ. б.

## Символик образ-детальләр:

**күл образы** – яшәеш, тормыш символы;
**Гашыйклар тавы** – мәхәббәт, тугрылык, бәхет, сөюнең бөеклеге символы. Мәхәббәтне кеше күңелендәге иң саф, тугры хис итеп биеклектә калдыру зарур;
**урман** – серлелек, авырлык, билгесезлек символы;
**серле үрдәк** – Мөнирәнең саф мәхәббәт хакында могҗиза дәрәҗәсендәге хыялы, сере.
**Кыр үрдәге образы берничә тапкыр кабатлана:** риваятьтә серле үрдәк; яралы кош (җырда); Үрдәк – Мөнирәнең нәсел кушаматы; үрдәк – Мөнирә белән Сәетнең төшләрендә; әсәр ахырында шагыйрь күргән чын үрдәкнең күлгә төшүе. Мөнирә дә, Сәет тә – канатлары каерылган яралы кошка тиң образлар.
**Өмет** – Мөнирәнең, Сәетнең, Өметнең, авторның өмете. Әсәрдә әнисенең өметен улы Өмет бик соң аңлый, акылына килә, ә калганнарның өмете акланмый кала. Өмет – кешене яшәтә торган матур хыял.

Сәетнең үрдәкне үтерүе укучыны бер фикергә алып килә: үрдәкне аткан Сәет, сугышка китеп, мәхәббәтеннән аерыла, гомер буе күңелендәге сөюне, саф мәхәббәт турындагы хыялын «үтереп яшәргә» мәҗбүр була.

**Төп вакыйгалар**

Эпиграфта бирелгән серле үрдәкнең 7 көн казанда кайнап та, 7 нче көндә казаннан күтәрелеп, зәңгәр күккә очуы турындагы сюжет әсәр вакыйгаларына **метафора** булып килә.

**Идеясе:** саф мәхәббәтне югалту, керсез сөю турындагы хыялдан баш тарту гомерлек бәхетсезлеккә дучар итә.

## Сюжет элементлары:


- **Пролог** → эпиграф итеп Гашыйклар тавы турында борынгы риваять бирелү;
- **Экспозиция** → хикәяләүченең Себердә Юрга шәһәрендә командировкада булуы;
- **Төенләнеш** → концертта «Яралы кош» җырын ишетүе;
- **Вакыйгалар үстерелеше** →
  - Гашыйклар күленнән җир мае эзләү;
  - үрдәкләр килмәү;
  - хикәяләүченең җыр авторы Сәет Зилаеров белән очрашуы; Сәетнең соңгы әманәте;
  - Сәет белән Мөнирәнең мәхәббәт тарихы;
  - Таллыкүлгә баруы һәм Өмет белән очрашуы.
- **Кульминацион нокта** → Мөнирәнең үлгән булуын белү.
- **Чишелеш** → Себердә Сәет (I) Зилаеровның үлемен белү; Өметнең Гашыйклар күлен торгызырга омтылуы; Өметнең улы Сәетнең (II) сөйгәне Алсу белән Гашыйклар тавында вәгъдәләшүе; күлгә кыр үрдәкләренең төшүе.

# Батырлык һәм матурлык җырчысы

## Фәнис Яруллин

1938–2011

**Татарстанның халык шагыйре (1997), язучы, драматург, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2007), Халыклар дуслыгы ордены кавалеры (1988)**



**1938 елның 9 февралендә** Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында туа. Кызылъяр җидееллык мәктәбен тәмамлый, аннары бер ел район үзәге Баулыдагы урта мәктәпнең сигезенче сыйныфында укый. **1954 елда** ул «Татнефть» берләшмәсенең Баулы элемтә конторасына монтёр булып урнаша. **1957 елда** аны хәрби хезмәткә алалар. Фәнис армиядә һава укчы-радистлары мәктәбендә укый, шунда спорт белән мавыга. Ләкин бервакыт спорт белән шөгыльләнгәндә, турниктан егылып төшеп, умыртка сөяген имгәтә һәм гомергә йөри алмас хәлдә кала.

Озак еллар өендә, хастаханәләрдә дәваланып ятуына карамастан, Ф. Яруллин бөтен тырышлыгын, рухи көчен үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат эшенең серләрен үзләштерүгә юнәлтә: **1963 елда** урта мәктәп программасы буенча экстерн тәртибендә имтихан тота, **1970 елда** исә читтән торып Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый.

Аның беренче иҗат тәҗрибәләре **1960 елда** Баулы район газетасында, аннан соң республика газета-журналларында басылалар. **2011 елның 8 декабрендә** вафат була.

Ф. Яруллин – күпсанлы китаплар авторы.

### Без моны беләбезме...

1. Паспорт буенча шагыйрьнең чын исеме – Фаниз. Тик беренче язмаларын бастырганда, хата китә. Шуннан бирле ул Фәнискә әйләнә.
2. Фәнис Яруллинның иң зур терәге хатыны Нурсөя ханым була.
3. Төшендә песи баласын күрсә, аларга кунакка кызлар килә торган була.
4. Фәнис Яруллинның иң яраткан ризыгы – ит белән бәрәңге бәлеше.
5. Журналистларга интервью бирергә һәм фотога төшәргә яратмаган.

> *Фәнис Яруллин гади яза, халыкчан яза. Аның күп кенә шигырьләре халык җырларыннан үсеп чыккандыр шикелле.*
> ***М. Шабаев**, шагыйрь*

> *Фәнис Яруллин – чын мәгънәсендә сизгер шагыйрь. Аның шигырьләрендә гап-гади көндәлек күренешләр балкып, яктырып китә.*
> ***Гәрәй Рәхим**, шагыйрь*



Баулыда Фәнис Яруллин һәм аның хатыны Нурсөя ханымга куелган һәйкәл

### Прозаик

«Яралы язмышлар» (2000)
«Җилкәннәр җилдә сынала» (1971)
«Чәчәкләр моңы» (1990)
«Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» (1986)
«Һәркемнең үз сукмагы» (1982) һ. б.

### Балалар өчен язган әсәрләре

«Алмалар пешкән чакта» (1971)
«Яшел утрау хуҗалары» (1976)
«Зәңгәр күлдә Ай коена» (1990)
«Биюче бака» (1996) һ. б.

### Җырлар авторы

«Сез иң гүзәл кеше икәнсез»
«Бар ул син эзләгән кеше»
«Сөялдем сөяннәргә»
«Кара миләш»
«Җыр калдырыйк» һ. б.

### Драматург

«Әнә килә автомобиль»
«Таң вакыты»
«Сөембикә егет сайлый»
«Койрыксыз сандугач»
«Бер күрешү – үзе бер гомер» һ. б.

ӘДӘБИ НУРЛАР. **МЕНТАЛЬ КАРТАЛАР**

И туган тел, и матур тел...

# «Җилкәннәр җилдә сынала» (1971)

> *Бәхет өчен, шатлык өчен,*
> *Көрәшеп яшим.*
> *Көрәшеп тапкан бәхетне*
> *Өләшеп яшим.*
>
> ***Ф. Яруллин***

**Жанры:** повесть

**Жанр формасы:** автобиографик повесть

- Повесть 14 ел дәвамында иҗат ителә.
- Әсәр язучының үз тормышыннан алып язылган.

**Образлар**

- **Прототиплар:**
  **Фәнияр** – автор үзе;
  **Илдус Гаделшин** – Марс Шабаев;
  **Илсөя** – Нурсөя.
- **Кеше образлары:** Фәүрия, Гөлсәйдә апа, Нәсимә, Илсөя, Ризван, врачлар Николай Сергеевич, Галина Измайловна.
- **Җыелма образлар:** авыл кешеләре, укчы-радистлар мәктәбе курсантлары – гимнастлар, палатада дәваланучы авырулар.

**Символик образлар:** җилкән һәм җил образлары

*Төп герой Фәнияр – ныклы рухы һәм ихтыяр көче аша яшәү мәгънәсен таба алучы, яшәүнең матурлыгын үзе генә күреп калмыйча, аны башкаларга да күрсәтә белүче кеше.*

**Темасы:**
яшәү өчен, тормышта үз урынын раслар өчен көрәшкән кеше язмышы

**Символик образлар**

**Җил** – тормыш сынавы, каршылыклар символы
**Җилкән** – кешенең омтылышы, хыяллары

*Фәнияр – әдәби образ, ул – язучының фантазиясе белән баетылган, үстерелгән, гомумиләштерелгән образ. Фәнияр, бәхетсезлеккә очрап, яшьли гарип кала, шул очраклы хәл аркасында гомер буе урын өстендә ятарга мәҗбүр була. Бу – аның физик хәле. Әмма образның рухи халәте, эчке хасияте тирән һәм кискен каршылыкларда бирелә, ягъни гомумиләштерелә. Мин моны тән һәм җан көрәше дип атар идем.*

***М. Галиев**, язучы*

**Сюжет элементлары:**

**Экспозиция** – авылда әрәмәдә печән өстен тасвирлау өлеше

**Төенләнеш** – Фәниярның авыр хәлдә ятуы турында телеграмма килү

**Вакыйгалар үстерелеше** – Фәүрия белән Гөлсәйдә апаның Красноярскига Фәнияр янына чыгып китүләре; Фәниярның авыр хәлдә больницада ятуы; Фәүриянең поездда егетне ташлап калдыруы; кулларының хәрәкәтләнә башлавы; шигырьләр язуы; егетнең кичке мәктәп тәмамлавы, университетта укуы; Илсөя белән танышу

**Кульминацион нокта** – Илдус Гаделшинның Фәниярны «күреп алуы»

**Чишелеш** – шигъри җанлы Фәниярның сөйгәне Илсөя белән бәхетле тормыш коруы

**Идеясе:** Көчле рухлы, түзем кешеләр генә максатларына ирешә, бәхетле була ала.

Әдәби нурлар

Белем бирү системасындагы үзгәрешләр, яңарыш, әдәбият укытуда үзгә педагогик технологияләр системасы барлыкка килү яңа төр кулланмалар эшләү, татар әдәбиятын өйрәнүнең кызыклы юлларын, яңа мөмкинлекләрен эзләү ихтыяҗын көн тәртибенә куйды. Шушы юлда татар әдәбиятыннан бер тәҗрибә буларак тәкъдим ителә торган әлеге проект гомуми урта һәм төп белем бирү мәктәпләре укучыларына, укытучыларга йөз тотып эшләнде. Гамәли юнәлешле әлеге кулланманың төп максаты – укучыларның әдәби белемнәрен системага салырга ярдәм итү, теге яки бу әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты хакындагы мәгълүматларны тулыландыру, теоретик белемнәрне гамәлдә кулланырга булышу.

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО